Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 37 (1402) 23 сентябрь 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



6

Башкортстанда гомер итүче чын милләтпәрвәр Нурмөхәммәт Хөсәеновның китабы татар тарихын тагын да киңрәк күзалларга булыша.

12

Төньяк башкала янында яшәп иҗат итүче Надия Миңнәхмәтова Казанда милли бизәкле диван куярга тели.

14

Кара алтын төбәге булган Азнакай үзәнең талантлы шәхесләре, Чатыр тау җыены, уенчылары, алдынгы технологияләр кулланууы белән дан тота.

Идел-йортка куәт өстәп торсын Туган җирнең нигъмәт-сыйлары!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Бүген Казанның А.С.Пушкин исемендәге мәдәни үзәгендә «Укыйбызмы?» проекты кысаларында «Китап көне» дип исемләнгән фестиваль башлана.
- Абдулла Алишның туган көне уңаеннан, Казанда аның исемен йөрткән 20 нче гимназиядә Алиш бюсты янында тантаналы митинг узды.
- Германиянең халыкара нәшриятында «Урал-батыр» башкорт эпосының русчага тәрҗемәсе басылып чыкты.
- Алабуганың Пушкин исемендәге Үзәк китапханәсендә драматург һәм режиссер Кәрим Тинчуринның 135 еллыгы уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды.
- Ростов өлкәсендә «Якташлар» татар-башкорт мәдәни үзәге ачылды.
- Әлмәт драма театрында Татарстан киносы көннәре узачак.
- Түбән Камада «Сүз көче» дигән гаилә әдәби фестивале үтте.
- Яшел Үзән районында Татарстаннан, шулай ук Чувашия һәм Мари Иленнән фольклор төркемнәр катнашында «Катык» этнобәйрәме үткәрелде.
- Шагыйрь, күп популяр җырлар авторы, эшмәкәр, Дәүләт Советы экс-депутаты Илсур Хөснетдинов вафат булды.
- Казахстан Республикасы Президенты Касым-Жомарт Токаев тәкъдиме белән, ил Конституциясенә төзәтмәләр кертелеп, Нур-Солтан шәһәре рәсми рәвештә Астана дип үзгәртелде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ, тарихчы галим:

«Бәя үзгәртү – ул сугыш нәтиҗәсе түгел, ә кешенең үзгәрүе нәтиҗәсе. Һәрбер җәмгыять тарихны үзгәртә, һәрбер шәхес тарихны үзенчә аңлата. Конкрет тарихи вакыйгалар бар, аларны без берничек тә үзгәртә алмыйбыз. Без аларга бәяне генә үзгәртә алабыз. Һәм бәя үзгәрә! Үзгәрәчәк тә. Ләкин бәя инде ул – субъектив нәрсә, ул объектив нәрсә түгел. Тарих ул – объектив, булган хәл, ә бәя бирү кешедән, аның субъективлыгыннан, карашыннан, идеологиясеннән тора».

СЫНАМЫШЛАР

23 сентябрьдә гөмбә күп икән, кышын кар аз булыр ● 25 сентябрь – җәйдән инде бит сыпыр; бу көнне җил тынмыйча һәм юнәлешен үзгәртеп иссә, һава торышы бозыла ● 28 сентябрьдә чикмән төшә, тун менә ● Мәче башлы ябалак кычкырса, суыклар башланыр ● Торна кышларга иртә китсә, кыш суык һәм озак булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 30 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 40 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **12 сәгать 10 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **30 сентябрьдә 11 сәгать 37 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

26 сентябрь – тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмовның тууына 100 ел (1922–1993).

28 сентябрь – язучы, журналист, Россиянең атказанган мәдәният эшлеклесе Рәшит Кәрип улы Зәкиевкә 85 яшь (1937).

29 сентябрь – актриса, Татарстанның халык, Россиянең атказанган Гәүһәр Габдулла кызы Камалованың тууына 100 ел (1922–1990);

– тел галиме, текстолог, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әнисә Хәниф кызы Алиевага 70 яшь (1952).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 26 сентябрь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(26 сентябрь-3 октябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

**Бүген сәфәр аеның
27 нче көне**

ҖАН АВАЗЫ

Иршад ГАФАРОВ,
Татарстанның атказанган укытучысы

МӘШҺҮР уку йорты

Соңгы вакытта гаммәви мәгълүмат чараларында Казанда педагогик уку йорты булмау турында борчылып, яңадан аны булдыру турындагы тәкъдимнәр еш күренә башлады. Дөрестән дә, халкы миллионнан ким булган калаларда да мондый уку йортлары яшәвен дәвам итә.

Билгеле, федераль университет булу республиканың абруен күтәрде, әмма бу хәл милли мәгарифкә, туган телебезгә тискәре йогынты ясады. Чөнки университет федераль уку планнары буенча гына эшли. Ә аларда милли һәм төбәк компонентлары юк, укудан тыш чаралар да рус телендә алып барыла. Безнең карашка, университет бары тик заманында аннан аерылып чыккан югары уку йортларын берләштерү нәтиҗәсендә генә оешырга тиеш иде.

Педагогика университеты беркайчан да аның эчендә булмады. Ул 1876 елның 24 октябрендә император Александр II нең махсус фәрманы нигезендә, Санкт-Петербург һәм Мәскәүдән соң өченче булып "Укытучылар институты" исемендә педагоглар әзерләү өчен ачылды. Ул - Россиядә сигез тапкыр үзенең атамасын үзгәрткән бердәнбер уку йорты. Аеруча аның исеме эчендәге "татар" сүзе мәскәүлеләр өчен "кызыл чүпрәк" ролен үтәде.

Ул Союзда иң мәшһүр педагогик уку йортларыннан саналды һәм үзенең атаклы педагоглары, галимнәре белән горурлана ала. Аларның кайберләре – институтның фәнни нигезен салучы галим-мөгаллимнәр: Е.И.Парамонов, А.И.Анастасиев, В.П. Брюханов, В.А.Богородицкий һ.б. СССР Фәннәр академиясенең хокукый әгъзалары В.М.Хвостов, А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар, К.А.Вәлиев, Д.Б.Греков, Е.В.Тарле, А.М.Корбангалиев һ.б.

Әлеге уку йортын тәмамлаучылар арасында СССРның халык артисты Г. Шамуков, СССРның халык укытучысы А.Сәлахов, язучылар һәм шагыйрьләр Ә.Еники, А.Алиш, Г.Кутуй, Һ.Такташ, С.Хәким, Ш.Маннур, И.Юзеев, Г.Гобәй, Р.Харис, Ф. Галимуллин, барлыгы 40 тан артык исем. Әгәр аны тәмамлаучылар арасында дөнья һәм Европа чемпионнары Н.Гыйләҗева, В.Никонова, Р.Бакиев, Н.Фәсахов, А.Хамматов, О.Данилова, шулай ук Социалистик Хезмәт Геройлары С. Габдрахманова, Г.Гыйматдинов. Заманында аның коридорлары буйлап М.Җәлил үткән.

Юбилей елында 16 факультетта 15 меңнән артык студент шөгыльләнде. Алар арасында 13 чит илдән килгән егетләр һәм кызлар да шактый иде. Шул ук чорда докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советлары аша 507 кеше кандидатлык һәм 63 докторлык дәрәҗәсенә лаек булды (мәгълүматлар 2006 елга).

Педагогика институты Вятка, Казан, Сембер, Самара, Әстерхан губерналары өчен укытучылар әзерләргә тиеш иде. Алдан институтның матди базасы яхшы булмаса да, 1897 елдан хәзерге К.Маркс урамы 43 санындагы иркен бинага күчкәч, эшләр җайга салына. Әлеге уку йортында белем алырга теләүчеләр күп: көнчыгыштагы – Енисей округы, көнбатышта – Новгород, төньякта – Кострома һәм көньякта Әстерхан якларыннан килеп укучылар була. Шуны да искәртик – институтка бары тик православие динендәгеләр генә кабул ителә.

Беренче директор булып хокукый статский киңәшче (хәрбиләрдә – генерал-майор) Е.И.Парамонов билгеләнә. Аның исеме Межлаук урамындагы бинага беркетелгән истәлек тактасы белән мәңгеләштерелде.

Институт 42 ел эшләү дәверендә 900 гә якын укытучы әзерләп чыгара. Алар Россиянең төрле почмакларында балаларга белем бирә, хәтта ике кеше Палестина җәмгыяте соравы буенча Назарет пансионатына елга 2250 франк хезмәт хакы белән чакыру ала.

Революциядән соң укытучылар институтлары дүртьеллык югары махсус педагогик уку йортлары итеп үзгәртелә. Педагогларның төп өлеше булып элек уку йортында эшләгән тәҗрибәле укытучылар кала. Алар яңа уку планнары, уку йортының матди базасын ныгыту проектын әзерли, чакырылачак профессорларның кандидатураларын раслый. Шулай ук классик университеттан тәҗрибәле галимнәр чакырыла.

Көнчыгыш педагогика институтында (1922-1930) дүрт: тел-тарих, физика-математика, биология-география һәм көнчыгыш бүлекләре оеша. Институтның матди хәле аның карамагына Родионова институтының (хәзерге Суворов училищесы) бинасын бирү ярдәм итә. Бу укучыларның санын арттыруга да мөмкинлек бирә. Мәсәлән, 1927 елда институтта 568 рус, 115 татар, 143 чуаш, 19 удмурт, 26 мари, 13 мордва, 46 яһүди һәм бүтән милләт вәкилләре укый.

Институтта 1929 елда Эшчеләр факультеты ачылу зур әһәмияткә ия. Ул педагогик һәм Идел буеның бүтән югары уку йортлары өчен татар һәм башка милләт яшьләрен студент булырга әзерләргә тиеш иде. Карар буенча 1930 елда укучыларның 50% эшчеләр, 20% батраклар, 30% крәстияннәр һәм ярлы колхозчылар, 60% татар һәм башкортлар, 25% бүтән милләтләр, 15% руслар булу таләбе куела. Кичке бүлеккә кабул ителүчеләрнең 90% эшчеләр сафыннан алына.

1930-1931 елларда Чабаксарда, Йошкар-Олада, Ижевскида мөстәкыйль педагогика институтлары ачыла. Шулай итеп Көнчыгыш педагогика институты әлеге уку йортлары өчен нигез була, ә үзе Татар педагогика институты атамасын ала.

1930-1931 уку елында институтта читтән торып уку, бер үк вакытта кичке бүлекләр ачыла. Читтән торып уку бүлегенә беренче елда 257 кеше кабул ителә. 1932 елның 1 гыйнварына уку йортының көндезге бүлегендә 864, эшчеләр факультетында 483 укучы була. 1933 елның 23 февраленнән педагогика институтларының яңа уку планнары раслана, уку вакыты яңадан дүрт еллыкка әйләнә. Институт татар мәктәпләре генә түгел, арта барган рус мәктәпләре өчен дә кадрлар әзерли, шуңа да аның исемен 1934-1935 уку елында яңадан Казан дәүләт педагогика институты дип үзгәртәләр. Әлеге уку елында анда тарих, тел һәм әдәбият (рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты бүлекләре белән), физика-математика (физика һәм математика бүлекләре белән), табигать (биология һәм химия бүлекләре белән), география, педагогика (мәктәпкәчә һәм мәктәп бүлекләре белән) факультетлары була.

КГПИ структурасында, укытучылар институтыннан башка, читтән торып уку һәм кичке бүлек, көндезге һәм читтән торып институтка керү өчен әзерлек курслары була. 1935 елга ул фәнни хезмәткәрләр һәм халык мәгарифенә кадрлар әзерләүче зур комплекска әйләнә.

Студентларның дәрес уку-язу белүләрен яхшырту өчен, шактый эш башкарыла, чөнки аларның 30%ка якыны рус телендә дөрес яза, укый һәм сөйләшә белми. Шуңа да 1938-1939 елдан рус теле уку планына мәҗбүри фән булып кертелә. Ә математика, физика фәннәренең күп бүлекләре, филология өлкәсе фәннәре татар телендә укытыла башлый.

Финнар белән сугыш вакытында уку планнарына топография, санитар белгечлеге, стройда йөрү, ату, химия буенча белем бирү өчен махсус хәрби кафедра оештырыла. Аның карамагына станоклы һәм кул пулеметлары, винтовкалар, противогазлар һәм бүтән кирәк-яраклар бирелә.

Халкыбызның тыныч тормышы фашистларның илебезгә мәкерле рәвештә бәреп керүе белән өзелә. Сугыш игълан ителеп, берничә сәгать вакыт үтеп өлгерми, студентлар, укытучылар, хезмәткәрләр үзләре теләп фронтка китәргә язылып башлый. 80 гә якын студент Ватаны саклаучылар сафына баса.

Укытуны дөрес оештыру өчен катлаулы мәсьәләләр хәл итәргә туры килә. Сугышның беренче елында 1 сентябрьдән 1942 елның 9 февраленә кадәр бары 9 көн генә дәресләр була, калган вакытта институт коллективы авыл хуҗалыгы һәм оборона эшләренә тартыла. Мәсәлән, әлеге чорда 500 студент, фәнни хезмәткәрләрдән торган ике төркем Кайбыч районында дот, дзот, танкка каршы чокыр, окоплар казуда катнаша. Шул ук вакытта институтның төп бинасын бушатырга карар кабул ителә. Анда 1300 урынлык 1658 санындагы госпиталь ачыла. 1942 елның июль аена уку бинасында һәм тулай торакта урыннар саны 1800 гә җиткерелә. Бу Татарстандагы иң зур госпиталь була.

Дәресләр төрле югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә өч сменада, иртәнге 8 дән кичке 11 гә кадәр дәвам итә. Сугыш чорында дүрт чыгарылыш ясала. Чыгарылучылар ТАССР мәктәпләренә, ә 1943 елдан соң бер өлеше фашистлардан азат ителгән Краснодар краена һәм Кабарда-Балкар республикаларына җибәрелә. Мәктәпкәчә тәрбия бүлеген тәмамлаучылар Хабаровск, Иркутск, Чита, Чиләбе, Архангельск үзәкләренә өлкә методистлары яки кабинет җитәкчеләре сыйфатында юллама ала.

(Дәвамы 5 нче биттә).

ДӨНЬЯКҮЛӘМ ФОРУМ НИ ӘЙТЕР?

Узган атнада Нью-Йоркта БМО Генераль Ассамблеясенең (ГА) 77 нче сессиясе ачылды. Аның көн тәртибендә - глобаль яшәешкә караган проблемалар: дөньяда 2030 елга кадәр тотрыклы үсешнең максатларын билгеләү; мәгарифне трансформацияләүгә багышланган саммит; милли, этник, дини һәм тел буенча азчылыклар хокукларын яклауны максат иткән чаралар («Азчылыклар хокуклары турында БМО декларациясе» кабул ителүнең 30 еллыгына багышлана) һ.б. Гадәт буенча, сентябрьнең өченче сишәмбесеннән (ягъни 20-26 сентябрь көннәрендә) анда «югары дәрәҗә атналыгы» да үткәрелә. Бу чорда сессиядә, халыкара хәлләр буенча һәм үз проблемаларын да үзәккә куеп, оешмада әгъза илләрдән, гадәттә, дәүләт җитәкчеләре һәм тышкы эшләр министрлары чыгыш ясый. Инсаниятнең бүген глобаль дәрәҗәдә рухи, әхлакый, икътисади вә геосәяси кризис кичерүен дә истә тотсак, халыкара мөнәсәбәтләрнең иң югары мөнбәреннән ясалган чыгышлар зур әһәмияткә ия булыр кебек. Насыйп итсә, аларның иң кызыклыларына киләсе язмабызда тукталырбыз. Әлегә исә игътибарны бериш даирәләрнең дөньякүләм форум алдыннан корган интрига вә астыртын эш-гамәлләренә, шикле уй-ниятләре тирәсендә ни дәрәҗәдә әвәрә килүләренә юнәлтү белән генә чикләнербез.

БМО ГА сессиясенә Россия делегациясен тышкы эшләр министры С.Лавров җитәкли. Анда җыенган ишле төркемнең (төп командада гына да 56 кеше) башта виза алу белән бәйле проблемалары булган, чөнки күпләр (хәтта С.Лавров үзе дә) санкция чикләүләренә дучар ителгән. Визаларны сессия алдыннан гына алганнар. Ә форумга әзерлек хәстәрен Мәскәү төрле яктан күрде кебек. Россия президенты В.Путин телефоннан хәтта БМО Генераль секретаре А.Гутерриш белән сөйләшү җаен да тапты. Югары дәрәҗә атналыгына туры китереп, 22 сентябрьгә БМО КШның Украина буенча тышкы эшләр министрлары дәрәҗәсендәге утырышы да билгеләнде. Сентябрьдә БМОда Франция рәислек итә. Бу илнең БМОдагы даими вәкиле Николя де Ривьер сүзләренә караганда, министрлар очрашуында Украина буенча вәзгыятьнең барлык параметрлары да каралачак (анда, әлбәттә, С.Лавров белән бергә, Украина тышкы эшләр министры Д.Кулеба да чакырылу). Башка мәсьәләләр белән бергә, анда 29 июльдә Еленовкада тикшерү изоляторына ясалган һөҗүмне (ә ул чакта анда Украинаның әсирлектәге сугышчылары күпләп юк ителде) тикшерү өчен БМО миссиясен оештыру хакында да сүз булачак. Соңгы вакытта Изюмда ачылган хәлләр дә игътибардан читтә калмас кебек.

Хәлбуки, 15-16 сентябрьдә Сәмәркандта үткән Хезмәттәшлекнең Шанхай оешмасы (ШОС) саммитын да «югары дәрәҗә атналыгы» алдыннан сәяси фон ясау чарасы дип карарга кирәктер. Әлбәттә, асылы белән ШОС әлегә сәяси максатлы декларатив оешманы хәтерләтә. Ә Россия мәгълүмат чараларында лейтмотив булып, ил бүген бернинди дә изоляциядә түгел, дөньяның 3,5 миллиард кеше яшәгән өлеше безнең белән аралаша, дигән фикер яңгырады. Бу – чын «большевик»ларча караш. Кытай белән Һиндстанны күздә тотып әйткәндә дә, аларда 100% халык бүгенге хәтәр хәлләрне хуплыймы икән соң? Менә шундый пропаганда. Мәскәүнең саммитта катнашкан илләр белән ябык ишекләр артында аерым-аерым үткәргән сөйләшүләре дә нигъдер астыртын эш йөртүне хәтерләтте. Игътибарны бигрәк тә Кытай-Россия сөйләшүләре җәлеп итте. В.Путин бу турыда, Россия һәм Кытай халыкара хокук нормаларына корылган күп полярлы дөньяви тәртип өчен тырыша, дип аңлатты.

Фоат УРАЗАЙ.

Кавыштыру кушымтасы

Бөтендөнья татар яшьләре форумы татар егет-кызлары өчен «Таптым» кушымтасын әзерли башлаган.

Мобиль кушымта ясау идеясе 2021 елның башында туды. Без Бөтендөнья татар конгрессы аша чит илләрдә, төбәкләрдә яшәүче яшьләрдән «сезгә нинди it-проект кирәк?» дигән сораштыру үткәрдек. Яшьләрнең күбесен танышу мәсьәләсе борчый булып чыкты», – диде «Таптым» кушымтасын гамәлгә куючы Райнур Хәсәни.

Аның әйтүенчә, «Таптым» аша ике максатка ирешеп була: гаилә кору (егет-кызларны таныштыру) һәм дуслар, танышлар табу.

«Мәсәлән, төбәктә яшәүче бер татар егетенең татар, мөселман кызына өйләнәсе килә, әмма ул таныша алмый, чөнки татарлар аз. Ул татар яшьләрен кайдан табарга, ничек танышырга белми. Шунлыктан, татар яшьләренә танышу агрегаторы кирәк булды. Әлбәттә, «Анаем» һ.б. проектлар бар. Әмма алар елдан-ел искерә бара, аңа ихтыяҗ кими. Шуңа күрә безнең «Тиндер» кебек популяр кушымтага охшашны эшләү теләге туды», – диде ул.

Райнур Хәсәни хәзерге вакытта кушымтаның дизайны эшләнүен, техник мәсьәләләре хәл ителүен әйтте.

«Быел грант оттык һәм «Таптым» кушымтасын гамәлгә ашыра башладык. Кушымтада үзеңнең кайдан икәнлегеңне күрсәтергә кирәк, шул рәвешле, кешеләр исемлеге килеп чыга. Алар сиңа шәһәрне күрсәтә яки башкача ярдәм күрсәтә алачак. Кушымта киләсе елның башында эшли башлар дип ниятлибез. Аны һәркем бушлай куллана алачак», – диде ул.

Әстерханга сәфәр

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев эшлекле сәфәр белән Әстерхан өлкәсенә килде. Монда 2023 елда XIII Бөтенроссия авыл Сабан туен әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты утырышы узды. Утырышта В.Шәйхразиев, Әстерхан өлкәсе губернаторы Игорь Бабушкин, министрлыклар вәкилләре, шәһәр җитәкчеләре һ. б. катнашты.

Төбәктә Федераль Сабан туен инде ике тапкыр – 2008 елда һәм 2017 елда билгеләп үттеләр. Шулай ук бирелә этно-авыл төзү проекты да старт ала. Ул Бөтенроссия Сабан туенда төбәктәге этнотуристик маршрутның бер өлеше буларак тәкъдим ителәчәк.

Эшлекле сәфәр кысаларында Милли шура рәисе өлкәнең Канга авылы һәм Әстерханның Тукай исемен йөрткән 74 нче мәктәбендә булды. Канга мәктәбендә 1156 бала белем ала. Былтыр биредә татар теле төп дәресләрнең берсе буларак укытыла башлады. Бөтендөнья татар конгрессы уку йортына татар теле дәреслекләре дә алып килде. Тиздән Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы да мәктәпкә әсбаплар китерәчәк. Тукай исемендәге мәктәптә В. Шәйхразиев укытучылар һәм укучылар белән аралашты, мәктәп тормышы белән танышты, шагыйрь истәлегенә куелган бюстка чәчәкләр салды.

«Тукай премиясе белән бәрабәр булырга тиеш»

«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе һәм «Татар моңы» конкурсына багышланган матбугат очрашуы узды. Анда Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин премиянең таләпләре белән таныштырды. Быел И.Шакиров исемендәге республика премиясенә гаризалар кабул итү 2022 елның 1 августында башланды. Бу эш 15 ноябрьгә хәтле барачак.

Премиянең приз фонды 600 мең сум тәшкил итә. 200 мең сумлык өч премия ике вокалистка (ир-атка һәм хатын-кызга) һәм «Халык җырларын башкаручы» номинациясендә җиңүчегә тапшырылачак.

«Гаризалар премиягә кандидатны тәкъдим иткән карары һәм иҗади портфолио нигезендә кабул ителә. «Вокал» номинациясендә җырчының башкару осталыгының югары дәрәҗәсе һәм югары яки урта һөнәри вокал белеме булуы белән бәяләнә», – диде Д.Натфуллин.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров премиягә гаризаларның чит илләрдән дә килүен билгеләп үтте: «Татар дөньясы Татарстан белән генә чикләнми. Республика премиясе дип аталса да, катнашучылар саны да, географиясе дә бик киң. Нигезләмәне без Бөтендөнья татар конгрессының төбәктәге оешмаларына юллыйбыз. Үзбәкстан, Казахстан, Таҗикстан, Төркмәнстаннан, илебезнең җитмеш төбәгеннән катнашучылар бар».

Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган артисты Салават Фәтхетдинов И.Шакиров исемендәге республика премиясенең приз фонды аз булуына ризасызлык белдерде. «Илһам Шакиров кебек кеше соңгы йөз елда тумаячак. Шуңа күрә ул премия кимендә Тукай премиясе белән бәрабәр булырга тиеш. Аннан да югары була алмаса да, ким булмасын. Тукайның үз чоры, Илһам Шакировның үз чоры бар. Шулчаклы зур кешенең исеме белән бигрәк вакланабыз», – диде С.Фәтхетдинов. Җырчы фикеренчә, Казан Кирмәне янында Илһам Шакировка һәм Әлфия Авзаловага һәйкәл куярга кирәк. «Кремль астында Әсгать абыйга (хәйрияче Әсгать Галимҗанов) һәйкәл бар. Нәкъ шунда Илһам абый белән Әлфия апаның икесенә һәйкәл куяр идем. Бернична ел элек үк туган иде бу ният, аннан соң ул фикеремнән нигъдер суындым. Тагын бер тапкыр шул мәсьәләне күтәреп чыгасы иде», – дип сөйләде ул.

Быел «Татар моңы» фестивале беренче тапкыр Илһам Шакиров исеме белән үткәрелә. Фестивальнең гала-концерты Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә үтәчәк. Филармония директоры Кадим Нуруллин «Татар моңы»н И.Шакиров исеме белән бәйләүне бишләтә җаваплылык дип атады. «Илһам Шакиров исеме белән узуы планканы тагын да ныграк күтәрә. Бик күп кенә популяр җырчылар «Татар моңы»ннан чыккан. «Бөтен юллар да Римга илтә» дигән кебек, сәхнәгә менүчеләрне дә бөтен юллар «Татар моңы»на алып килә», – диде ул. «Татар моңы»ның дүрт номинация буенча җиңүчеләре билгеле. «Халык җыры» номинациясендә – Алинә Гыйльметдинова, «Инструменталь башкаручы»да – Алмаз Ахунов, «Эстрада вокалы» номинациясендә Вилнур Әдилов белән Гөлназ Муллаәхмәтова, «Академик вокал» номинациясендә Диләрә Төхвәтуллина белән Илгиз Мөхетдинов җиңүчеләр дип табылган. 19 октябрьдә узачак гала-концертта җиңүчеләр жюри әгъзалары белән берлектә чыгыш ясаячак.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА.

1 нче биттә – Арча районында «Ат көне» фестивале уңаеннан әзерләнгән экспозициядән бер күренеш. Фото: president.tatarstan.ru

Ат бәйрәме

Арча районында «Ат көне» ат спорты фестивале узды. Бәйрәмдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Саха (Якутия) Республикасы башлыгы Айсен Николаев та кунак булды.

«Ат көне» фестивале театральләштерелгән пролог белән ачылды. Сәламләү сүзендә Р. Миңнеханов ата-бабаларыбызның атсыз тормышны күз алдына да китермәвен искә алды һәм бүген дә ат үрчетүгә зур игътибар бирелүен ассызыклады. Чабышларны карарга килгән тамашачыларның күп булуы мөһим икәнен телгә алды.

«Безнең өчен – дөньядагы иң төньяк төрки халык өчен ат – изге хайван. Без атларны яратабыз, аларны үстерәбез. Безнең өчен ат дустан да якынрак, бу ниндидер бер илаһи көч. Алар ярдәмендә без бик ерак араларны үтә алабыз. Быел төркиләрнең Евразиянең гаять зур далалары буйлап ничек барганын күрсәтү өчен, безнең яшь егетләр Оймяконнан (планетада салкынлык полюсларының берсе) алып Мәскәүгә кадәр атта бардылар. Алар бу юлны 1 ел һәм 4 ай эчендә уздылар, 11 мең километр юл үттеләр, шул исәптән Татарстан аша да. Аларны монда бик зур кабул итүегез өчен рәхмәт. Егетләр шуның белән төрки халыкларның рухын һәм ат белән бердәмлегебезне күрсәттеләр. Мин ышанам ки, мондый ат чабышлары һәм мондый ярышлар – болар барысы да безнең халыкларга бик кирәк булган традицияләрне торгызуга ярдәм итәчәк», – диде Саха Республикасы башлыгы А. Николаев үз чыгышында.

Ат спорты фестивалендә Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев, Арча районы башлыгы Илшат Нуриев һ.б. катнашты.

«Ат көне» бәйрәмендә Аударыш уены узды. Көрәшне Фәрит Нәбиуллин алып барды. Ул аударышта катнашучылар саны ел саен арта баруына, аларның тәҗрибәсе дә артуына сөенечен уртаклашты.

Аударыш уенында 80 килограммга кадәр авырлыкта Кукмара районыннан Илнур Гобәйдуллин, һәм 80 килограммнан авыррак үлчәүдә Әлмәт районы вәкиле Динар Хәйбриев җиңү яулады.

«Ат көне» фестивале кысаларында 160 км, 120 км, 100 км, 80 км һәм 40 километрга чабышлар оештырылды.

Хәйриячеләр бинасы

Татарстан башкаласында «Игелекле Казан» коворкингы (бергә эшләү урыны) ачылды. Бина 100дән артык хәйрия җәмгыяте вәкилләрен берләштерә. «Игелекле Казан» оешмасына Сеченов урамындагы торак йортның 1 нче катында 500 кв метрдан артык мәйданлы иркен бүлмә бирү турындагы карар 2021 елның октябрендә кабул ителгән. Биредә капиталь ремонт ясалган. Берләшмәнең Профсоюзлар урамында урнашкан элекке бүлмәсендә семинарлар һәм башка хәйрия оешмалары вәкилләре белән очрашулар үткәрү мөмкинлеге юк иде. Бүген «Игелекле Казан» коворкинг базасында осталык дәресләре уздырырга, волонтерларны укытырга һәм башка чаралар оештырырга мөмкин. Шулай ук монда мөмкинлекләре чикле балаларның әниләре эшли алачак. Инде хәзер үк биредә анимация дәресләре, ишарәләр теле буенча курслар, нейрокоррекция дәресләре үткәрелә.

Коворкингның ачылышына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Президент администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров, республиканың хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова, Казан мэры Илсур Метшин килде. Алар кабинетларның, холлның уңайлылыгын һәм җиһазланышын бәяләде. Кунакларга «Игелекле Казан» оешмасы турында сөйләделәр.

Холлда Татарстан Президенты Казанның хәйрия фондлары вәкилләре белән аралашты. «Игелекле Казан» коворкингында «Архидети», DonorSearch хәрәкәте, «Ангел Вера» проекты (паллиатив ярдәм), психологик ярдәм кабинеты, диабет белән авыручыларга ярдәм фонды һәм башкалар урнашкан.

Р.Миңнеханов «Игелекле Казан» КАБО директоры Татьяна Мерзлякова коляскадагы инвалидларны йөртү өчен Lada Largus автомобиленә сертификат тапшырды.

Равил Бохараев истәлекләре – музейда

Язучы, шагыйрь, драматург һәм тәрҗемәче, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Равил Бохараев халкыбыз хәтерендә, әдәби әсәрләре белән бергә, рус, инглиз, венгр телләрендә татар әдәбияты, Татарстан турында сөйләп һәм язып торган, күп мәсьәләләр белән кызыксынган, киң эрудицияле шәхес буларак та кереп калды. Аның шулай ук тарих, сәяси икътисад һәм ислам мәсьәләләренә багышланган әсәрләре дә зур кызыксыну уята.

Быел Равил Бохараевның арабыздан китүенә дә 10 ел булды. Күптән түгел Мәскәү актрисасы Ольга Калашникова шагыйрьнең хәзерге вакытта Мәскәүдә яшәүче җәмгатьтә Лидия Григорьева үтенече белән Татарстан Милли музеена Равил Бохараев архивыннан кадерле истәлекләр тапшырды. О.Калашникова Казанга М.Волошин исемендәге XX халыкара әдәби фестиваль кысаларында Равил Бохараев пьесасы буенча куелган моноспектакльдә уйнарга килгән иде.

Татарстан Милли музее матбугат хезмәте хәбәренчә, бүләк ителгән ядкәрләр кулъязмалардан, фоторәсемнәрдән тора. Кульязмалар арасында Равил Бохараевның Казан дәүләт университетының механика-математика факультетында укыган елларында иҗат иткән «Тень Тамерлана» поэмасы, шулай ук шәһәрнең 1000 еллык тарихына үз карашларын белдереп язган «Сказ о Казани» дигән фундаменталь тарихи-әдәби хезмәте игътибарны җәлеп итә. Моннан тыш шагыйрьнең шигырьләре һәм пьесалары (алар арасында басылып чыкмаганнары да бар), Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев турындагы «Бабай» телесериалының синопсисы – кадерле истәлекләрдән.

Фоторәсемнәр Бохараевларның 100 ел дәвамында тупланган гаилә фотоальбомы сурәтләреннән тора. Хәзер аларның кайберләрендәге шәхесләрне, фотоларның кем тарафыннан, нинди уңайдан һәм кайда төшерелүен ачыклау сорала.

Татарстан Милли музее генераль директоры Алиса Вяткина Лидия Григорьевага рәхмәтләрен белдерде һәм, Равил Бохараев иҗатын тагын да популярлаштырачакларын искәртеп, Татар китабы йортында драматургның пьесасы буенча куелган моноспектакль күрсәтеләчәген, мәдәни-мәгърифәти цикл булдырылачагын, анда Р.Бохараев мирасы төрле иҗади даирәдә дәвам итәчәген әйтте. Лидия Григорьевага "Музей меценаты" билгесе дә тапшырылачак.

Сөембикә КАШАПОВА.

● «Җәмгатьчелек фикере» фонды тикшеренүеннән күренгәнчә, россиялеләрнең 69 проценты беркайчан да чит илдә булмаган. Сораштырылганнарның 35 проценты ел саен Сочида һәм Краснодар краенда ял итә икән.

● Америка биологлары үлгәннән соң бер сәгать үткәч дуңгызны терелткән. Тәҗрибә вакытында галимнәр наркоз астында дуңгызларның йөрәген туктаткан һәм бер сәгатьтән соң йөрәк һәм үпкә эшен алыштыра торган аппаратка тоташтырган. Аннары хайваннарга әкренләп махсус сыеклык керткәннәр, ул тукымаларның бөтенлеген саклап калган, күзәнәкләрнең үлемен туктаткан һәм төп әгъзаларны яңадан эшләтеп җибәргән.

● Венеция 400 күпер белән тоташтырылган 118 утраудан тора.

МӘШҺҮР уку йорты

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Сугышны тәмамлап кайткан мөгаллимнәр үз хезмәтләренә тотына, тик яу кырында калган 28 енә бу насыйп булмый. КГПИ Казанда элеккеге төп бинасын алмаган бердәнбер уку йорты була, чөнки анда Суворов училищесын ачалар. Аның урынына элек госпиталь урнашкан реаль училище бинасын (Межлаук урамы) бирәләр.

1945 елда ректор итеп Ю.Туишев билгеләнә һәм 22 ел буена институтны җитәкли. Ул РСФСР мәгариф министрлыгы рөхсәтеннән башка, үзәктән ягып җылытуны оештыра. Төп бинаның бөтен мичләре сүттерелә. Шуның өчен аны Мәскәүгә чакыралар, әмма министр урынбасары булып эшләгән сабакташы: "Җиңүчеләрне хөкем итмиләр!" - дип аңа ярдәм итә.

Сугыштан соң беренче уку елында 7 факультет, алар эчендә булган 21 кафедра эшли. Төрле сәбәпләр аркасында кадрлар кытлыгы килеп чыга. Уку йортына яшь педагоглар - институт яки университетны, шулай ук Казан, Мәскәү уку йортларында аспирантура тәмамлаган белгечләр килә.

Институтның эшчәнлегендә студентларның педагогик тәҗрибәсенә игътибар ителә башлый. Моның өчен алдан 15 мәктәп билгеләнә (1946), ә 1958 елга алар саны ике тапкырга арта. Студентларга махсус педагогика һәм психология фәннәреннән белем бирелә. Алар мәктәпләрдә тәҗрибәле укытучылар һәм методистлар җитәкчелегендә булачак һөнәрләрендә беренче адымнар ясарга өйрәнә. Бу хәл классик университетта юк дәрәҗәсендә иде, шуңа да аннан мәктәпләргә берничәшәр генә кеше җибәрелде, әле анда да министрлыкка юллама гына килә иде.

Студентларның физик тәрбиясенең матди нигезе ныгытыла. Шуның өчен 1958 елда ректор Ю.Туишев Мари АССРдагы Яльчик күле янәшәсендә җир алуга ирешә. Анда 1959 елда "Яльчик" исемендә спорт-тернәкләндерү үзәге, 1970 елда физик тәрбия факультеты өчен 4 залы булган махсус спорт комплексы ачыла. Бу үз чиратында институтка югары уку йортлары арасында үткәрелә торган 1 Май һәм Ленин эстафеталарында дистә еллап беренчелекне алырга мөмкинлек бирә.

1962 елда институт 400 урынлык тулай торакны сафка бастыра. 1967-1968 елларда һәр факультетның деканы җитәкчелегендә гыйльми советлар төзелә. Бу үз чиратында алда торган мәсьәләләрне тиз һәм сыйфатлы итеп хәл итәргә мөмкинлек бирде. Казан һәм Буа шәһәрләрендә консультация пунктлары эшли. Анда институт педагоглары килеп лекцияләр укый, экзаменнар һәм зачетлар ала иде. Бу читтән торып укучылар өчен зур ярдәм булды.

Урыннардагы мәктәпләргә һәм халык мәгарифе бүлекләренә даими ярдәм итү дә институт алдында торган җитди бурычларның берсе иде. Әлеге юнәлештә "Учительская газета"ның уңай бәясен алган укытучыларның иҗтимагый лекторие ачылды. Институт шулай укытучыларның һөнәрен камилләштерү буенча да шактый эш башкара. 1971-1975 елларда Татарстан укытучылар белемен күтәрү институты белән берлектә 2500 кешене махсус курслар аркылы үткәрүдә катнаша. Шулай ук урыннарда 3200 укытучыны эченә алган 47 семинар үткәрә.

Яшь укытучыларның һөнәри әзерлеген үстерүдә 1962-63 уку елында оешкан иҗтимагый һөнәр факультеты зур урын ала. Аның составында "Хоровое дирижирование", режиссерлык, журналистика, физкультура һәм спорт бүлекләре эшләде. 20 ел эчендә әлеге факультет аркылы 7 меңгә якын студент үтте.

1967 елның май аенда ректор булып әлегә кадәр проректор булып эшләгән иң яшь профессорларның берсе М.Зәкиев

сайлана. Ул институтны алдынгылар сафына чыгара. 1976 елда институтның 100 еллыгы уңаеннан аңа хөкүмәтебезнең югары бүләге – Хезмәт Кызыл Байрагы ордены тапшырылды. 1977 елда институт Россия педагогика уку йортлары арасында җиңүче дип танылa һәм аңа РСФСР Министрлар Советының Күчмә Кызыл Байрагы тапшырыла. 1978 елда институт СССРның 250 педагогика институтлары арасында җиңүче дип игълан ителә һәм Татарстан уку йортлары арасында беренче булып КПСС ҮК, Министрлар Советының Күчмә Кызыл Байрагын яулый. КДПИ тәҗрибәсе укытучылар әзерләү мәсьәләләре буенча махсус үткәрелгән бөтенсоюз һәм бөтенроссия киңәшмәләрендә өйрәнелә.

1986 елда ректор булып филология фәннәре докторы Р.Юсупов эшли башлый. Моңа ул 17 ел гомерен багышлый. Әлеге илебез өчен гади булмаган авыр елларда да институт яңа үрләргә омтылды. Анда докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау буенча советлар барлыкка килде. Укытучылар арасында фән докторлары саны артты. Яңа белгечләр әзерләнә башлады. Авыл мәктәпләрендә чит тел сәгатьләре аз булганлыктан, анда укытучылар җибәрү мөмкинлеге чикләнгән иде. Шуңа да тел, тарих факультетларында уку вакытын биш елга әйләндереп, чит телләр буенча да белем бирә башладылар. Кайсыбер гуманитар белгечлекләр уку планына "Музыкаль тәрбия нигезләре" исемле курс кертелде. Бу студентларны үзешчән сәнгатькә тартырга мөмкинлек бирде. Факультетара "Студентлар язы" дигән фестиваль үткәрелә башлады. Республика ярышында да институт алдынгы урыннарга, шул исәптән "Гран-при"гә дә лаек булды.

1992 елдан КДПИ ның тарихында яңа бит ачыла. Институт мөстәкыйльлек ала һәм чит ил югары уку йортлары белән бәйләнешләр урнаштыра башлый. Инде 1993 елдан ук Төркия, Көнчыгыш Гарәп илләре, Кытай, Англия, Германия, Франция, Америка уку йортлары белән шундый бәйләнешләр барлыкка килә. Шул ук вакытта чит телләр факультетында әлеге илләрдән укытучылар эшли башлый. Бер үк вакытта университетта укытучылар әзерләү белән булачак педагогларны фәнни эзләнүләргә кушу эшләре дә алып барыла. Шул максат белән фәнни түгәрәкләр, фәнни-иҗат төркемнәре, фәнни җәмгыятьләр оешa. Студентлар шәһәр, республика, бөтенроссия, халыкара фәнни конференцияләрдә, олимпиада-конкурсларда катнашып чыгышлар да ясый. Мәсәлән, 2005 елда гына да аларның 250дән артык хезмәтләре нәшер ителде.

2005 елның 22 июнендә университет Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты атамасын ала. Шул ук елда Татарстан урамында аның яңа мәһабәт бинасы кулланышка тапшырыла. Аннан алдарак "Татэнерго"ның дүрт катлы бинасы да уку йортына бирелә. Соңрак Межлаук урамында дүрт катлы берничә факультет өчен яңа бина, аның янәшәсендә зур спорткомплекс та ачылды.

Үзенең юбилеен университет Россиядәге иң зур уку йортларының берсе булып каршылый. Аның 16 факультетында һәм Чаллыдагы филиалында 14 меңнән артык студент, 66 кафедрасында 984 укытучы, шулардан 73 фән докторы һәм профессор хезмәт куя. Университетта төрле юнәлештә 195 аспирант укый. Укытучылар арасында 19 Россиянең, 119 Татарстанның атказанган хезмәткәре, 40 тан артык Россия югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре эшли.

Юбилей уңаеннан Татарстанның беренче Президенты М.Шәймиев болай дип язды: "Сезнең уку йорты – ул киләчәккә йөз тотучы университет. Ул яңа сыйфатында югары белемле белгечләр әзерләү урыны гына түгел, ә безнең милли элитаны рухи яктан формалаштыручы үзәк тә булырга тиеш. Шуны уңышлы үти алуыгыздан милләтебезнең булачагы хәл ителә. Моның өчен нык матди база, көчле укытучылар коллективы бар".

Ни кызганыч, бары берничә елдан бу фараз сабын куыгы кебек шартлап бушка чыкты. Университетны саклап калып була идеме? – дигән сорау күпләрне борчый. Мисаллар нигезендә моңа уңай җавап биреп була. Моның өчен бары коллектив белән әйбәтләп сөйләшергә, киңәшергә кирәк иде. Тик кайберәүләр буш вәгъдәләргә ышанды, икенчеләре бабаларыбызның "бер казанга ике тәкә башы сыймый" дигән мәкален онытқан булып чыкты.

Ә педагогик уку йорты бик кирәк! Инде ничә еллар республика мәктәпләрендә математика, физика, рус теле, башлангыч класслар һәм башка кайбер фән укытучыларына кытлык хөкем сөрә.

Атнаның сәяси мизгелләре

ТЕРСӘКНЕ ТЕШЛӘП БУЛМЫЙ

15-16 сентябрьдә Сәмәркандта үткән ШОС (Хезмәттәшлекнең Шанхай оешмасы, анда әгъза булып Казахстан, Кыргызстан, Кытай, Пакыстан, Россия, Таҗикстан, Үзбәкстан һәм Һиндстан тора, бу саммитта аларга Беларусь һәм Иран да өстәлде кебек, Әзәрбайҗан, Әрмәнстан, Кампучия, Непал, Төркия һәм Шри-Ланка – оешма белән диалог партнерлары, ә Монголия һәм Әфганстан күзәтүчеләр санала) саммиты, кайбер сәяси күзәтүчеләр аны сүлпән бәяләсә дә, күп кенә нәрсәләргә ачыклык кертте. Әйтик, Россия президенты В.Путин Украинадагы хәлләр турында: "Мы сделаем все для того, чтобы это все прекратилось как можно быстрее. Только, к сожалению, противная сторона, руководство Украины заявило об отказе от переговорного процесса, заявило о том, что хочет добиться своих целей военным путем, как они говорят, на поле боя", - дип белдерде. Ә махсус хәрби операция максатын ул Донбассны азат итү һәм Россия иминлеген гарантияли торган шартлар тудыру дип билгели. Күрүебезчә, вакыт максатларны да үзгәртә.

Ә ШОС саммитында Сәмәрканд декларациясе һәм 20 дән артык башка документлар (шул исәптән 2023-2027 елларга исәпләнгән дуслык вә хезмәттәшлек турында килешүне гамәлгә ашыруның бишьеллык планы h.б.) кабул ителгән. Әлбәттә, планнар зурдан. Тик реаль хәлләр генә оптимизмга урын калдырмый. ОДКБ, ШОС кебек оешма әгъзаларының (әйтик, Әзәрбайҗан белән Әрмәнстанның, яисә Таҗикстан һәм Кыргызстанның) хәтта саммит чорында да үзара сугышуы күп нәрсә турында сөйли. Беришләрен инде океан артыннан килеп тә үгетлиләр. Шуңа саммитта ШОСны реформалау турындагы сүзләр юкка гына әйтелмәгәндер.

Башка хәбәрләрдән игътибарны, Украинадагы кораллы каршы тору тиз генә тәмамланмаячагы, шуңа күрә ул Көнбатыш илләренең хәрби һәм финанс ярдәменә алга таба да мохтаҗ булачагы турында НАТО генераль секретаре Й.Столтенберг әйткән сүзләр, шулай ук Пентагонның Украинага хәрби ярдәменең 600 миллион долларлык яңа пакеты турында белдерүе дә җәлеп итә. АКШның Россиядә яңа илчесе итеп хатын-кыз билгеләнәчәге турындагы хәбәр дә кызыклы. Игътибарны исә күренекле җырчы Алла Пугачеваның бер кыю адымы да җәлеп итә. Социаль челтәрдә ул Юстиция министрлыгына үзен чит ил агентлары исемлегенә кертүне сораган язма урнаштырган.

Фоат УРАЗАЙ.

Чиксез татар чикләре



Тормышы шулай корылганмы, беркем дә зур җитәкчеләр янында, аеруча барча халык алдында, чын дөреслекне ярып салырга тырышмый. Ул чагында Башкортстанның Бәләбәй шәһәрендәге татар гимназиясе директоры булган педагог-мәгърифәтче Нурмөхәммәт Хөсәенов исә Татарстан, Башкортстан президентлары М.Шәймиев, М.Рәхимовның Россия Президенты Владимир Путин белән Казанда узган очрашуында: «Башкортстанда татар булу авыр», – дип дөреслекне ачыктан-ачык ярып, барысын да хәйран итте. Бу инде ут-күрше республиканың татарлар яшәгән районнарында башкортлаштыру, татарларны кысу кебек сәясәт алып барылуы уңаеннан әйтелгән сүз иде. Нәтиҗәдә зур мөнбәрдән күрше республикада яшәүче милләттәшләребезнең теле, мәгарифе турындагы мәсьәлә дә күтәрелде.

Татар мәкале «Турысын әйткән туганына да ярамый», – ди. Аңлашыла ки, Нурмөхәммәт Хөсәеновның Казандагы очрашуда әйткән сүзен онытмадылар, үчләшүләр башланды, ул бар иткән һәм җитәкләгән уку йортын ябу өчен гаеп эзләүләр, бер-бер артлы административ эш буенча мәхкәмә утырышлары узды. Хәтта директорның берьюлы ике дистәләп административ эш буенча мәхкәмә каршында да җавап тотарга туры килгән чаклары да булган. Әмма Бәләбәй гимназиясе директоры барысыннан да үҗәт булып чыкты, һәрберсен җиңеп барды.

Шул ук вакытта 30 елга якын тарих фәнен укыткан Н.Хөсәенов татар тарихын өйрәнә, китаплар чыгара башлады. Хәзер инде аның татар халкы тарихын өйрәнүдә эшчәнлеге дә өч дистә елга якын. 640 биттән торган «Словарь тюркских основ русского языка» («Рус теленең төрки нигезләре сүзлеге») дигән хезмәте белән ул тагын бер тапкыр барысын да шаккатырды. Анда биш мең сүз схемага куелып урнаштырылган. Ул лингвистика фәненең фоносемантика юнәлеше буенча славян телләренең нигезендә төрки тамырлар ятуын күрсәтә һәм рус теленең төрки тел сүзләре нигезендә барлыкка килүен дәлилли. Н.Хисамов бу китабыннан соң роман-герман телләренең төрки нигезләрен тикшерү эшен башлап җибәрде һәм «Словарь тюркских основ романо-германских языков» («Роман-герман телләренең төрки нигезләре сүзлеге») дигән тагын бер саллы китапны укучылар кулына тапшырды. Тарихчы Нурмөхәммәт әфәнде улы Илдар белән сүзләр ясалышын гына тикшермичә, теге яки бу сүзнең ни сәбәпле килеп чыгуын һәм нинди механизмнар ярдәмендә кулланылышка кергәнен дә өйрәнә.

Быел исә Бөтендөнья татар конгрессының VIII корылтаена Н.Хөсәенов тагын бер зур яңалык белән килде. Аның кулында Бөек Татария державасы турында рус телендә язылган «Контуры Великой Татарии» дигән зур форматта нәшер ителгән һәм 600 гә якын биттән торган китап иде. Ул – дүрттомлык итеп эшләргә ниятләнгән хезмәтнең беренче китабы. Нурмөхәммәт әфәнде аны да үзе кебек үк тарих белән «җенләнгән» улы Илдар белән бергәләп язган.

Әлбәттә, мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләрендә Бөек Татария державасы турында бернәрсә дә язылмаган. Рәсми тарих фәне дә бу турыда бер җөмлә дә дәшми. Билгеле ки, бер яктан караганда, бик сәер дә. Чөнки «Контуры Великой Татарии» хезмәтендә язылганча, ул супердержава булган, әмма аның турында мәгълүмат бик аз сакланган, билгесез, аңлаешсыз сәбәпләр белән Бөек Татария тулысынча диярлек дөнья тарихыннан сызылган. «Әмма фактлар бик үҗәт. XV йөз ахыры-XVI йөз башы карталары Көнчыгышта – Океания, Япония утрауларыннан алып, Азия, Африканың бер өлеше, Австралия киңлекләрендә һәм Көнбатышта Европаның әһәмиятле өлешендә Бөек Татария кебек гаять зур дәүләт булуын күрсәтә. Аның яшәү вакыты 1500 елдан да ким түгел. Бөек Татариянең соңгы өлешләрен күрсәткән географик җирләр карта төшерүчеләр ясаган сызымнардан XIX гасыр ахырында гына юкка чыккан. Бөек Татария ничектер Бөтендөнья тарих дәреслегеннән дә төшеп калган» – дип яза Н.Хөсәенов. Һәм шул ук вакытта Татариянең бәхәсләргә урын калдырмый торган бик күп дәлилле эзләре Үзәк һәм Көнбатыш Европада, Африкада һәм Көньяк Америкада, шулай ук Тын океан утрауларында сакланып калган. Бөек Татария державасының шундый зур биләмәләргә ия булуы исә скифлар һәм татарларның гасырлар дәвамында үзләренең батырлыклары, бик тиз яулап алулары белән аерылып торуыннан килә. Автор китабында бу уңайдан француз халкының бөек мәгърифәтчесе һәм фәлсәфәчесе Шарль Монтескьеның XVIII гасырда язып калдырган сүзләрен китерә. «Из всех народов мира ...ни один не превзошел татар славою и величием завоеваний. Этот народ – настоящий повелитель вселенной...; во все времена являл он миру свое могущество... Под именем тюрок они произвели огромные завоевания в Европе, Азии и Африке и господствуют над тремя частями света».

XX гасыр ахырында җәмгатьчелеккә архив ишекләре ачылып, шактый яшерен мәгълүматлар билгеле булды. Шул вакытта дөньяга Бөек Татария чикләре төшерелгән XIV-XIX йөз карталары белән дә танышырга мөмкинлек туды. Хәзерге вакытта шундый 330 карта булуы мәгълүм. «Аларда күрсәтелгәнчә, чынында бу дәүләтнең дүрт кыйтганы биләп торганлыгы аермачык күренә», – дип яза Нурмөхәммәт әфәнде. Россия тарихчылары бу хакта сүз кузгатмаса да, Татарияне һәм татарларны гасырлар буе теркәгән меңгә якын миниатюра, документлар сакланып калганлыгы ачыкланган. Шул ук вакытта Монгол империясенең кеше ышанмаслык карталары (аның белән Бөек Тартарияне алыштыру гадәткә кергән) XIX гасыр башларында беркем тарафыннан да ясалмаган булган. Ә инде 1837 елдан, соңарып булса да «Бөек Монгол картасы»н нәшер итәргә алыну факты да аның уйлап чыгарылган булуын күрсәтә. «Бүгенгә кадәр кайбер тарихчыларның Монголияне татарларның ата-бабалары ватаны итеп бәйләргә тырышуы исә милләтебезне килмешәк халык итеп танытырга тырышуыннан килә», – дип яза Н.Хөсәенов. Ватикан сәясәтчеләре татарларны хәтта җир асты патшалыгы белән бәйли торган «ТАРТАР» этнонимын уйлап тапкан.

«Монгол-татар изүе» («монголо-татарское иго»), Россиядә кулланыла торган һәм Русь белән хакимлек итүне аңлата торган «Алтын Урда» терминнары да ельязмаларда бөтенләй дә очрамый икән. «Изү» дигән сүз беренче тапкыр XVI гасырдан XVII гә күчкән елларда католик поляк әдәбиятында күренгән, аны поляк хронисты Ян Длугош беркемгә дә адресламыйча кулланган. Термин әкренләп галимнәр, илчеләр теленә кереп китә һәм тора-бара «тарихны язучылар» аны Московия турындагы тарихи әсәрләрендә сак кына әйләндерә башлый. Әмма хәзер заманның тарихчы галимнәре – профессор А.Пыжиков, М.Делягин, Н.Смирнов, Ю.Пензов, А.Гордеев һ.б. тарихчылар «татар-монгол изүе»нең тарихи миф һәм ялган икәнлеген язып чыккан.

Сүзебез Бөек Татария турында иде. «Шунысы гаҗәп, «татар» сүзе белән аталган һәм бу зур дәүләтнең турыдан-туры дәлилләре булган һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән эзләрен күрергә генә кирәк икән», – ди Н.Хөсәенов. Ул биш кыйтгада татарга бәйле 1325 топоним булуын ачыклаган. «Татар» сүзе кергән топонимнар дөньяның 76 дәүләтендә сакланып калган», –ди Н.Хөсәенов. Океаннар, мәгърур таулар, авыл-бистәләр, утраулар, елга, инеш, ерымнар татар исемен йөртә, димәк ки, алар бу җирләктә татарлар булуы турында сөйли. Ә инде «татар» сүзе белән бәйле термин һәм предмет исемнәре, тирә-юньдәге күренешләр, төрле халыкларда «татар» сүзе кергән фамилия йөрткән миллионнарча кешеләр булуы мәгълүм. «Татар» сүзенең шулай күп кулланылышы очраклы гына була алмый», – ди тарихчы. Шул ук вакытта, ул дәверләр аша узып безгә килеп ирешкән һәм бу дәүләтнең архивларда һәм археологик эзләнүләр вакытында табылган флаг, герб сурәтләре, Татария дигән ил һәм татарлар турында сурәтләгән документларның өземтәләрен бик күпләп китерә. Кызганыч ки, бүген инде Бөек Татария дәүләте турында Казан, Әстерхан, Кырым, Себер татарлары гына хәтерли.

«Контуры Великой Татарии» китабы – Нурмөхәммәт Хөсәеновның күпьеллык хезмәте. Ул озак еллар дәвамында Бөек Татария турында бик җентекләп өйрәнгән, мәгълүматларны, сурәтләрне туплый барган. Автор китапта да, үз фикерләрен куәтләп, бик күп дәлилләр китерә, язганнарын борынгы карталар, миниатюралар, археологик табылдыклар, артефактлар, документаль фактлар һ.б. мисаллар, фотосурәтләр, иллюстрацияләр, топонимнар, аларның координаталарын күрсәтеп, бәйләп алып бара. Әйтик, Евразия һәм Төньяк Африкада «татар» сүзе кергән 600 топоним әле бүгенгәчә сакланып калган. Америкада - 15, Германиядә 8 татар топонимы, хәтта татар ипие дә бар.

«Контуры Великой Татарии» китабы белән танышканда, Нурмөхәммәт әфәнденең гаять зур, титаник хезмәт куюына хәйран каласың. Әлбәттә, авторның күп фикерләре укучылар өчен яңалык та булыр. Әмма Н.Хөсәенов әйтергә теләгән сүзен кире кагып булмаслык фактлар, саннар, борынгы фәйләсуфларның фикерләре белән ныгытып бара. Аңлашыла ки, тарихчы галимнәр арасында, Н.Хөсәенов саллы дәлилләрне җитәрлек китерсә дә, Бөек Татария державасының яшәве турындагы фикерләрне җөпләп торучылар аз булыр. Алар, китапта язылганнар белән килешкән очракта да, авторны хупларга ашыкмас. Чөнки Россия табигый фәннәр академиясе академигы, тарихчы галим Лев Гумилев кебек без – татарларны яклаучылар бик сирәк.

Сөембикә КАШАПОВА.

АТЛАНТИДА

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң ишетелә.

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтга,
Тау дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар.

Океан упкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир упкан:
Дәшти Кыпчак, Болгар, Алтын Урда...
Бер-берсенең тамрын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан...
Калдыгын да көлгә дөндерергә
Миссионерлар күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без менә, без - бар, булганбыз!

Фал ачабыз ләкин, баш ватабыз:
Әллә кыпчак, әллә болгар без?

Кем булгандыр бабам? Кыпчакмы ул,
Болгармы ул? Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без –
Татар каны ага тамырда!

Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без менә, без – бар, эз бар җирдә –
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә,
Оныкларның ачык бабасы:
– Нәселең кем? – дип сорасалар әгәр,
Әйтерләр: – Без – татар баласы!

Татарстан дигән ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем.
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын.

СӘЙФ САРАИНЫ УКЫГАЧ

Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,
Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли.
Сәйф Сараи

Гөлдерсеннең Сөһәйл тирәсендә
Әйләнүен тиңләп Җиргә, ул
«Җир әйләнә Кояш тирәсендә!»
Дигән серне әйтеп биргән ул
Коперниктан йөз илле ел элек.

Шәрыкта бу, димәк, күптәннән
Ачык булган. Сараи тик аны
Шигъри чара итеп үткәргән.

Мөмкинме шик тоту Коперникка, –
Тел тидерү аның кебеккә!
Тик гыйбрәтле шунысы: кайчак серләр
Соң ачыла, элек белеп тә...

БОРЧУЫМ КАЛА

Тудым казах илендә,
Үстем йортым Иделдә.
Шушы ике өемдә
Әкиятем, чыным кала.

Дала җырга өйрәтте,
Идел җанны көйрәтте:
Бер уй телә йөрәкне –
Китсәм, борчуым кала...

Мирасым юк алтыннан –
Гауга купмас артымнан,
Тик йөрәктән саркылган
Җырым моңсуым кала.

Көмештәй кар суларым,
Язлардай ярсуларым,
Өмет-ымсынуларым,
Туган җир-суым кала.

Кырмыска иле сыман
Мыжылдап, кайнап торган,
Тырыш, тынгысыз, чыдам
Йортым – чыр-чуым кала.

Килгәннәр китә җирдә...
Зыян юк аннан бер дә.
Илем кайгысы миндә:
Китсәм, борчуым кала...



Нури АРСЛАНОВ

Узганнардан түгел, мин халкыма Киләчәктән урын барлыймын...

(Күренекле шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Нури Арслановның тууына 110 ел)

ХАЛЫК

Әгәр дә син булсаң алтын балык,
Сиңа хәят биргән дәрья – халык.

Мәйданнарда җиңсәң батыр калып,
Таянычың-табышың, шиксез, халык.

Күтәрелсәң зур дәрәҗә алып,
Баскыч булып баскан ла шул халык.

Бәйгеләргә чыксаң ат атланып,
Иярләгән, томар таккан халык.

Бәхет килсә бусаганы табып,
Юл күрсәткән аңа да шул халык.

Халкым диеп яшәүчегә янып
Үзе ялкын бирә изге халык.

Сөеп баккан әнкәң-әткәң дә шул,
Телең ачкан, кеше иткән дә шул.

Шушы телдә горур исем алып,
Милләтеңне аныклаган халык.

Һич онытма, кардәш, шул телеңне,
Исеңдә тот һәрдәм кемлегеңне!

СИН ГЕНӘ

Чәчәкнең кызылы син,
Дөньяның кызыгы син,
Бер сыйфатың меңгә күчә:
Җанга ыгы-зыгы син.

Сәбәпсез турсаясың,
Аяусызсың, чаясың, –
Белмәгәнгә шулайдыр шул
Иркәлекнең чамасын.

Тылсымчым, күрәзәчем;
Кызудан куләгәсең;
Күңел багларымда җиләс
Канәферсең, лаләсең.

Тал булып бөгеләсең,
Җам булып түгеләсең,
Зәңгәр төннәремдә тулган
Ай булып күренәсең.

Йөзләрең балкып тора,
Түшләрең калкып тора,
Чәчләреңнән күк күгәрчен
Исләре аңкып тора.

Атлыйсың вак-вак кына –
Йөгермисең чак кына...
Озын телләр дә чарасыз:
Сөйлиләр мактап кына.

Канатлы күбәләгем,
Шат җанлы көлгәләгем,
И минем сабыр-салмагым,
Тынгысыз көйгәләгем...

Үзәкләрем өзелә,
Җитәрме түзем генә:
Күбәләк тә, көйгәләк тә –
Барсы да үзең генә...

Син генә, тик син генә
Тынгы бирмисең генә!
Тынгылар бирмәсәң бирмә,
Миннән башканы сөймә.

УТЫРАМ КӨЗГЕ БАКЧАДА

Җил каен-талларга куна,
Җирдән яфраклар куа.
Сүзләр хәрефләрдән тора,
Мәгънә сүзләрдән туа.

Хәрефләр тамчылар булып
Кәгазьгә тамып тора;
Утырам бакчада туңып,
Яфраклар явып тора.

Телгә килә алар менә, –
Тыңласаң, мәгънәсе бар:
Яфракларның да, җилнең дә
Шагыйрьгә дәгъвасы бар.

Беравыздан икесе дә:
– Күр,ниләр тезгән! – диләр,
Хәрефләр, җөмләләр – сиңнән,
Ә мәгънә – бездән! – диләр.

Җил гел пышылдый, яфраклар
Туктаусыз кыштырдыйлар:
– Җитмәсә дә туңар чаклар,
Туңгакка – кыштыр, – диләр.

Сүзен бүлдермим боларның,
Язам да язам гына,
Булсын иде туңуларым
Хәерле казам гына.

ЯРДАГЫ УЧАК ЯНЫНДА

Гәрәбә йолдызлар күкләрне бизи,
Ай сылу зәп-зәңгәр яулыгын изи,
Җилләрнең сулышын яфрак та сизми...
Нинди тын тантана иркәли җанны!

Ярдагы учакның ялкыны үчте,
Күмере яктырды, нәкъ алтын төсле,
Аның да көл белән капланды өсте...
Тик җанда ялтырап бер чаткы калды.

Менә ул терелде, ялкынга күчте,
Җәелде... Узганнар исемә төште:
Киң Идел суларын кайната төсле,
Давыллы дулкыннар тетрәтә ярны!

Сискәнеп мин кинәт бастым аякка:
Кораллы атлылар чаба як-якка,
Калканнар күкрәктә, уклар садакта,
Байраклар җилферди, байраклар канлы.

Гасырлар артына чыкканмын барып.
Хыялдан арындым... Җир нурга гарык,
Төн ята көрсенеп, тынлыкка талып,
Ай үрти елмаеп тынгысыз җанны...

ЮКСЫНАМ

Йолдыз булып күктән бакмый икән,
Бер атылса гомер ук сыман:
Китек күңел урын тапмый икән, –
Мин бит сине, Сибгат, юксынам...

Бер-беребезгә авыр сүз әйтмәдек,
Табигатьләр төрле булса да.
Дуслыкны да, хәер, көчәйтмәдек,
Булсак та бик уйдаш, дустанә.

«Талантлылар белә, – дия идең, –
Үзләрендә талант барлыгын!»
Белә идең, киң булса да илең,
Хисләр өчен дөнья тарлыгын.

Тар дөньяда киң күңелле булып
Яши алса кеше – үлемсез!
Синең белән торган икән тулып
Безнең оя! Синсез күңелсез...

Кайда син, әй, замандашым минем!
Кочакларга әзер колачлар:
Кордаш булган өчен дияр идем,
Күп китте бит инде кордашлар.

Ятимлектә булмый күңелләр хуш,
Сагышлардан чара юк сыман:
Арабыздан киттең, урының буш,
Шагыйрь, сине мин бик юксынам.

Сөембикә манарасы

Сөембикә манарасы – Казанның гына түгел, бөтен татар халкы символларының берсе. «Казан Кирмәне» музей-тыюлыгының баш архитекторы Рөстәм Зәбиров, манара Казан ханлыгы чорында төзелмәгән, аны татарлар төземәгән, дигәч, каршы фикер язучылар шактый булды.

Сөембикә манарасын кемнәр һәм кайчан төзегән соң? Археолог Рөстәм Зәбиров: «Бина XVIII гасыр башында каравыл манарасы буларак төзелгән, дигән фараз бар. Төгәл даталарны тарихчылар да әлегә кадәр әйтә алмый», – дип белдергән иде.

Бу мәкалә чыккач, безгә Габдулла Шамуковның 1968 елда «Казан утлары»нда басылып чыккан мәкаләсенә игътибар итәргә куштылар. Шамуков әйтүенчә, бинаны татарлар төзегән, һәм ул татар архитектурасына карый. Габдулла Шамуков – актер, нәфис сүз остасы, педагог һәм язучы. Тарихчылар аның тарихчы да, археолог та, архитектор да булмавын әйтер, билгеле, әмма дәлилләрнең күп китерелүе (алар ни дәрәҗәдә фәнни – анысын белгечләр әйтсен) бу версиягә ышанырга мәҗбүр итә.

Шулай да, Сөембикә манарасы мәсьәләсен, иң элек, Казан Кирмәнен өйрәнгән археологлар, тарихчылардан сорашу урынлы. Археологларга Сөембикә манарасын кем һәм кайчан төзегәнлеге, аның татар яки рус архитектурасы булу-булмавы турында сорау бирелде.

Татарстандагы А.Халиков исемендәге Археология институтының директор урынбасары, археолог Фаяз Хуҗин. Белгәнебезчә, ул – Болгар, Казан ханлыгы чорын өйрәнгән, Казанның меңьеллыгын исбатлаган шәхесләрнең берсе. Ул тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдиновның «Сөембикә һәм Сөембикә манарасы» дигән мәкаләсе белән танышып чыгарга киңәш итте. Мәкаләдән галимнең кайбер фикерләрен китерик.

«Сөембикә манарасын урыслар салган, дигән фикер тарафдарлары түбәндәгеләр: Ф.Эрдман, В.Суслов, И.Грабарь – болар XIX йөз авторлары, безнең гасырда исә – П.Дульский, Н.Калинин, ә иң соңгы чор вәкилләреннән – С.Айдаров, А.Халиков.

Манараның татар архитектурасы истәлеге булуы турындагы фикерне революциягә кадәр Н.Баженов, К.Невоструев, С.Шпилевский, М.Пинегин, Н.Загоскин, П.Заринский, П.Невзоров кебек Мәскәү һәм Казанның рус галимнәре яклады, ә татар тарихчы-галимнәреннән шушы ук фикердә торучылар Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәров, Һ.Атласи, З.Вәлиди, Г.Батталлар булды.

Совет чорында бу карашны В.Егерев, Г.Шамуков, Ф.Вәлиев, Ә.Мөхәммәдиев, Ф.Салихова куәтләп һәм яңа материаллар белән баетып чыкты. Без фәкыйрегезне дә шушы фикердә дип белерсез.

Сөембикә манарасының 1552 елда Казанны яулап алганнан соң төзелүе турында фәндә бер генә документ, бер генә тарихи чыганак та юк. Әгәр ул XVI йөзнең икенче яртысы – XVIII йөзләрдә салынган булса, һичшиксез, шул заманның рәсми документларында яки башка төрле язмаларында теркәлгән булыр иде, чөнки Казанның урыслар төзегән күп кенә архитектура истәлекләренең даталары билгеле. Мәсәлән, Кремльдәге Благовещение соборы, Спас һәм Никольская башнялары (1556–1560 еллар), алардан ерак түгел урнашкан Петропавел чиркәве (1720 еллар).

Әгәр дә манараны урыслар салган булса, ул шул урыс чорының иҗтимагый фикерендә чагылыш тапкан, урыс халкының тарихи хәтерендә сакланып калган булыр иде. Урыс халкы бервакытта да аны үзенең изге җире дип санамады, аның турында җырлар җырламады, аның янына килеп чукынмады, аңа икона һәм тәре куймады. Үзенең «святыня»ларына мәхәббәт саклаган урыс халкының үз башнясын Казан ханлыгы тарихында якты эз калдырган, аның бәйсезлеге өчен көрәшкән, татар халкының күңеленә мәңгегә кереп урнашкан мөселман динендәге кеше исеме белән атаву – гамәлгә сыймаслык эш.

Сөембикә манарасы – татар халкының иң кадерле, иң газиз тарихи истәлеге ул. Халкыбыз аның турында гасырлар буенча риваять-легендалар, җыр-бәетләр тудырган, гасырлар дәвамында аның янына гыйбадәт кылырга, Коръән укырга йөргән. Сөембикә манарасы татар халкының йөрәк түрендә, аның мәңгелек тарихи хәтерендә. Боларны инкарь итәргә тырышу, аларга каршы көрәшү халык тарафыннан кискен каршылыкка очрады һәм очраячак.

Үзенең архитектур чишелеше, стиль үзенчәлекләре, композицион алымнары, эшләнешендәге мөһим элементлары һәм бизәлеше ягыннан Сөембикә манарасы татар архитектура сәнгатенең ачык үрнәге булып тора. Ярусларының кискен-контраст булуы, күзгә бәрелеп торган баскычлылыгы белән манара урыс хәрби башняларыннан һәм чиркәү колокольняларыннан бик нык аерылып тора – боларына корылманың бер өлешеннән икенчесенә әкренләп, салмак күчү, гомумән, корылмаларның үзенә сыгылмалылык, пластика хас.

Октябрь революциясеннән соң ук Совет хөкүмәте органнары тарафыннан кабул ителгән «Казандагы Сөембикә манарасын мөселман хезмәт халкына бирергә» дигән карарны үтәү йөзеннән һәм халык үтенечен искә алып, элекке мәчет манарасы булган Сөембикә манарасына ай куелды, дөресрәге, 20 нче еллар азагындагы гаделсезлек нәтиҗәсендә алып ташланган айны торгыздылар».

Белешмә. Сөембикә манарасы хакында язылганнар Татарстан ССР Министрлар Советы каршындагы «Мирас» региональ үзәгенең Тарих һәм культура истәлекләрен саклау комиссиясенең 1990 елның 5 май көнне уздырылган махсус утырышында сөйләгән докладка нигезләнде (автор – әлеге комиссиянең рәисе). «Комиссия Сөембикә манарасы турында карар кабул итте, анда манара өстенә ай кую кирәклеге басым ясап әйтелде. Ниһаять, шушы карарга нигезләнеп, Татарстан ССР Министрлар Советы шул ук елның 24 августында (№ 317) Сөембикә манарасы буенча карар чыгарды һәм озакламый – 1990 елның 25 сентябрендә – манара өстенә алтынланган ай куелды. Шулай итеп, тарихи дөреслек торгызылды, татар халкының гасырлар буе теләп йөргән хыялы тормышка ашты».

Археолог Ф.Хуҗин Рөстәм Зәбиров версиясе белән килешә. Ягъни, манара Казан ханлыгы чорында төзелмәгән, аны татарлар төземәгән, ди ул.

– Мин – археолог, фактлар белән эш итәм. Тиздән «Җыен» фондының «Сөембикә» дигән яңа китабы чыгарга тиеш. Анда Габдулла Шамуковның да, Равил Фәхретдиновның да, минем дә мәкалә урын алган.

Мин археологик материалларга нигезләнәм, чөнки без, археологлар, 1994–2005 елларда Казан Кремлендә киң күләмле казу эшләре үткәрдек. Эшләребез ярыйсы гына нәтиҗәле булды: башкалабызның барлыкка килү вакытын ачыкладык; моңа кадәр начар өйрәнелгән ханлык чоры археологиясе буенча кызыклы ачышлар ясалды, мәсәлән, язма чыганакларда телгә алынган Кол Шәриф мәчетенең нигезләре табылды, 1977 елда ук ачылган Ханнар төрбәсен тулысынча казып чыгардык һ.б.

2001–2002 елларда безнең экспедиция Сөембикә манарасына якын гына җирдә – аның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш ягында казу эшләре үткәрде. Без биредә таштан салынган зур гына бина калдыкларына юлыктык.

Хәзерге Сөембикә манарасы урынында элек Хан мәчете торган. Ул мәчетнең эзләре ачылды. Хан мәчете Казан ханлыгы чорында төзелә. Явыз Иван Казанны алгач, мәчетне бөтенләй үк җимермиләр, склад итеп тоталар. Һәрхәлдә, ул мәчет XVII гасырның ахырында гына җимерелә. Археологик яктан ул исбатланган. Аннан соң шушы урынга Сөембикә манарасын төзеп куялар.

Манара җиде яруслы итеп кызыл кирпечтән салынган. Төрле биеклектәге яруслары баскычланып өскә күтәрелә һәм түбәсенә ярым ай утыртылган сигез кырлы шпиль белән тәмамлана. Манараның нигез мәйданы – 140 квадрат метр. Биеклеге 58 метрдан артып киткән әлеге корылма үзенең вертикаль күчәреннән ике метр чамасы көнчыгышка авышкан. Авып баручы манаралар дөньяда күп түгел һәм безнең Сөембикә – шуларның берсе. Шушы үзенчәлеге аңа тагын да серлелек өсти һәм бөтен кешенең, бигрәк тә чит илләрдән килгән туристларның игътибарын җәлеп итә.

Безнең алда озынлыгы-киңлеге 14 метрга җитә торган таш бина хәрабәләре иде. Аның төзелеш горизонты (юка гына чүп-чар катламы) калынлыгы бер метрдан артып киткән ханлык чоры катламының нигезендә диярлек ята. Димәк, аның төзелү вакытын якынча XV гасырның урталары (икенче яртысы?) белән билгеләргә була (табылдыклар бу датага бераз төгәллек кертә). Шул ук ханлык чорында тупланган катламның югарырак өлешендә тагын бер төзелеш горизонты – XVI гасырның беренче яртысында, әлеге таш бинага терәтеп, кирпечтән үлчәмнәре 9х9 метрлы тагын бер корылма өстәп куйганнар. Игътибар итегез: бина озын ягы белән көньяк-көнбатышка – нәкъ менә Мәккәгә, кыйблага каратып салынган. Хан мәчете булганмы? Бәлки, Нурали мәчетедер? Тәгаенләп әйтүе кыен, әлегә бары тик фаразлаулар гына. Шулай да, бу бина безгә Сөембикәне хәтерле кебек тоелды.

Хан мәчете өстенә төзелгән



●Казан кирмәне XVI гасырның беренче яртысында. Н.Ф. Калинин материаллары нигезендә реконструкция. Үзәктә Җәмигъ мәчете, арткы сул почмакта - Төньяк-көнчыгыш күзәтү манарасы.

Без казып чыгарган бина кайчан җимерелгән, дигән сорауга җавап табу өчен, стратиграфик күзәтүләребезне дәвам итәбез. Аның җимерелү вакытын күрсәтеп торучы горизонт XVII–XVIII йөзләр аралыгында тупланган рус чоры катламында урнашкан. Димәк, ханлык чорында салынган мәчет – һичшиксез, Хан мәчете! – кимендә XVII гасыр ахырларына кадәр яшәгән.

Безнең өчен бер як көтелмәгәнрәк булды: хәзерге Сөембикә манарасының төньяк-көнчыгыш нигезе без казып чыгарган һәм ханнар чорында салынган бина өстендә «утыра». Димәк, соңгысы Сөембикә манарасын төзегәндә (бәлки, бераз элегрәктәр) җимертелгән була инде. Мәчетнең җимертелгән вакыты XVII–XVIII йөзләр аралыгында, дибез икән, димәк, Сөембикә манарасы тагын да «яшьрәк» булып чыга. Сүз уңаеннан: манараның төньяк-көнчыгыш тарафка сизелерлек авышуы –аның шул як почмагы элеккеге мәчетнең нигез чокырына туры килүе белән аңлатыла, – ди Ф.Хуҗин.

Галимнең бу сүзләре «Җыен» фондының «Сөембикә» китабында урын алачак.

«Сөембикә манарасы – урыс чорына караган архитектура истәлеге, дип ялгышмыйбызмы икән? – ди Ф.Хуҗин үзенең мәкаләсендә. – Юктыр, чөнки Сөембикә-ханбикә заманында Сафагәрәй вафатыннан соң гаугалы ике ел эчендә әле бүген дә зурлыгы-биеклеге белән күпләрне шаккатырырлык мондый корылманы – мәчет манарасын төзү һич тә мөмкин булмаган. Әле бит бу, Равил Фәхретдинов һәм ул санап киткән тарихчы-галимнәр инануынча, манара гына, ә аның төп өлеше – мәчетнең бинасы – нинди зурлыкта булырга тиеш икән? Хәзерге заман мәчет манаралары да күпкә кечерәк.

Шуны да онытмыйк: Казан ханлыгы – Урта гасыр төрки-татар цивилизациясенең сүнеп бару чорында яшәп калган дәүләт. Ул чакта Болгар илендәге кебек мәшһүр калаларның эзе дә булмаган. Хәтта Казанны да зурлыгы ягыннан Болгар, Биләр, Суар, Җүкәтау ише болгар шәһәрләре белән чагыштырып булмый. Ыгы-зыгыдан башлары чыкмаган ханнар акча сугу эшен дә оештырып җибәрә алмаганнар ич. Зәгыйфьләнгән ил башлыгы – шундый авыр, каршылыклы шартларда көчхәл белән тырышып-тырмашып идарә кылучы Сөембикә, сөекле иремнең истәлеген мәңгеләштерәм дип, кулыннан килмәслек эшкә тотынмас та иде. Шуңа күрә манараның Казан рус дәүләте составында яшәгән чорда салынган булуы белән килешергә кирәктер.

Әйе, ул үзенең тышкы «кыяфәте» белән берьюлы һәм татар, һәм урыс архитектура корылмаларына охшаш. Аны төзегәндә, урыслар белән бергәттән татар осталары да катнашкан булуы ихтимал. Кремль уртасында Россия империясенең гербы урнаштырылачак «татар» манарасын торгызып куюу – ул инде Казанның Мәскәү хакимияте астында булуына ишарәләүче символ да.

Ничек кенә булмасын, татар халкы манараны үзенеке итеп кабул итә. Әле бүген дә өлкән яшьтәгеләр биргә килеп дога кылып китә, яуларда шәһит булганнарны искә төшерә, илгә иминлек тели. Чөнки ул бит Сөембикә заманнарыннан ук калган Хан мәчете өстенә салынган. Һаман да шул мәчет саклана халык хәтерендә», – ди Фаяз Хуҗин.

Казан археологы, А.Халиков исемендәге Археология институтының фәнни хезмәткәре Фәрит Әхмәтгалин, манара XVII гасырда төзелгән, дигән фикердә.

– Манара Хан мәчете урынында төзелгән, дип уйлыйм. Ул аның фундаменты өстендә басып тора. Бина Казан ханлыгында төзелмәгән, бу – йөз процент билгеле. Археологик тикшеренүләрдән, бинаның кирпеч формасыннан чыгып шундый нәтиҗә ясыйбыз. Бинаны кем төзеткәне, аның архитекторы билгеле түгел. Рус архитекторы булгандыр, дип уйлыйм, чөнки манара Мәскәү Кремленең бер манарасына охшаш, – диде галим.

Нияз Халит 2016 елгы әңгәмәсендә, Казан ханлыгы чорында Сөембикә манарасы астында хан некрополе һәм Хан мәчете урнашкан булган, алар өстендә манара һәм чиркәү төзелгән, дип сөйләгән. Галим бинаны «рус корылмасы» дип атый.

– XVIII гасырның 20 нче елларында төзелгән, дип әйтә алабыз. Документлар, ышанычлы чыганак булмаса да, моны раслый. Казанның планнары, панорамалары, сызымнары бар. Анда да манараның кайчан барлыкка килгәне күренә. Минем өчен архитектура – шулай ук үзенә күрә документ. Биолог үсемлекләрнең киселеше буенча нәрсәдер билгели ала, мин дә, архитектор буларак, корылма буенча мәгълүмат әйтә алам. Биредә XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башындагы Мәскәү оборона архитектурасы мәктәбе аермачык күренә.

Мәскәүнең Спас манарасы белән чагыштыручылар бар. Анысы инде – инглиз готикасы. Ә монда күбрәк Италия юнәлеше сизелә. Сөембикә манарасына охшаш шундый ук корылмаларны әйтеп була: Мәскәү Кремленең Кызыл мәйдандагы Иверск часовнясы, шуңа охшаш манаралар Коломенское, Измайловода бар. Охшашлыгы – түбән өлешләре буенча. Якынча пропорцияләр һәм сәнгать образы буенча Мәскәү Кремленең Боровицкий манарасын атый алабыз. Әмма абсолют охшашлык беркайда да юк. Мәсәлән, Василий Блаженный храмы – кабатланылмый торган уникаль корылма, ул башка беркайда да юк. Гәрчә бу XVI гасырның рус корылмасы булса да.

Монда да шул ук хәл. Бу манара – үзенең сәнгать образы буенча индивидуаль. Кайберәүләр аны татарныкы дип әйтеп ялгыша. Татар архитектурасы дип дәлилләр таба алмыйбыз, чөнки ул вакыттан берни дә сакланмаган.

Стиль композиция, сәнгать образы, декоратив деталь, төзелеш культурасы, конструкцияләре, планировкасы һ.б. сыйфатларның зур комплексын үз эченә ала. Бу билгеләр – XVII гасырның рус архитектурасыныкы, ләкин аның Казан Кремлендә төзелгәнен исәпкә алганнар. Манара төзелгәндә, территория Казан губернасы дип түгел, ә Казан Патшалыгы дип аталган. Ул әле яңа яулап алынган территория генә булган, – дип сөйләгән Нияз Халит.

P.S. Археолог, тарихчы Равил Фәхретдинов үз мәкаләсендә Сөембикәнең Казанда 18 ел яшәвен, һәм 32 яшендә, үзенең сабый баласын – яшь ханны кочаклаган килеш, Казан халкын зар елатып, кара кайгыга батырып, мәңгелеккә китеп баруы турында яза. Ул Сөембикәнең кабере табылуына ышаныч белдерә.

– Сөембикәнең улы Үтәмешгәрәйне чукындырып, аңа Александр исеме кушалар, тик ул 1566 елда 18 яшендә ниндидер сәбәптән үлеп китә (аның гәүдәсе Мәскәү Кремленең Архангельск соборындагы таш саркофагта, урыс патшаларының саркофаг-каберләре белән янәшә). Сөембикәне, әле улы үлгәнче үк, ул вакытта Касыйм ханы итеп куелган Шаһгалигә көчләп кияүгә бирәләр. Бердәнбер газиз баласыннан аерып, җаны сөймәгән бер әшәке адәмгә көчләп бирелгән Сөембикәнең соңгы көннәре билгеле түгел. Аның Шаһгали тарафыннан кыйнап үтерелгәнлеге хакында да кайбер, әлегә ачыкланып ук бетмәгән хәбәрләр бар. Һәрхәлдә атасы Йосыфның Иван Грозныйга үпкәләп, ачуланып язган хатында шул хакта әйтелә.

Кайда күмелгәнлеге дә ачык түгел – Касыйм шәһәрендәге Шаһгалинең гаилә мавзолеенда аңа куелган таш юк. Аның кабереңең кайчан да булса табылачагына мин, мәсәлән, археолог-тарихчы буларак ышанам. Ул чагында Сөембикәнең дә, Үтәмешгәрәйнең дә сөякләрен Казанга алып кайтып, Сөембикә манарасы янына – башка Казан ханнары белән янәшә күмү мәсьәләсен күтәрергә кирәк, – дигән галим.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

intertat.tatar.

Алма дисәң дә алалар... көрәкне!

Айдар ХӘЛИМ

Мин бу хикәямне моннан илле-алтмыш ел элек, җиңел генә, бер тыннан, «үтеп барышлый гына язып ыргыта» ала идем. Хәтта – язарга тиеш идем. Һич кенә дә арттырмыйча әйткәндә, үземне белә башлаганнан, бишектәге диярлек заманнардан билгеле булган бу җаныя сәхифәм гел генә языла алмыйча килде: мин аны ният иттем, ул миннән китте, мин аңардан киттем, ул миңа килә торган булды. Әмма... килсә дә, тагын онытылып торды. Яңадан искә төшкән очракларымда сере үземә генә билгеле булган «Лапаты не яблыкы» кәлимәсен эчтән генә кабатлый һәм авыз почмагым белән генә көлемсерәп, аны тагын да күпмедер вакытка оныта идем. Шулай да ул, кая барсам да, артымнан калмады: мин хәтта ат иярендә булсам, ул нәкъ шул атның камчысы кебек – иярнең кашына үрләп кунаклый иде.

Әйе, хикәя чынлап та моннан илле-алтмыш ел элек языла, хәтта ташка басылып чыга ала иде икән шул. Әле шул чакта ук мин – ундүрт-унбиш яшьтән район газетасында басыла башлаган үсмер, авылдашы һәм яраткан Биктимер абзасы тормышын ошбу «Лапаты не яблыкы» дигән өч кенә сүз, аларның да берсе сүз булып җитешмәгән «не» дигән инкяр кисәкчәсе булган, жиде генә ижек ишарәте белән серле яктыртып торган әйтемне авылыбыз җәмгыятенең генә түгел, үзенең һич көтелмәгән, самими үткерлеге белән барлык төрки-татар җәмгыятенең холык-фигылен, табышмактай кабатланмас хикмәтен ачып салган бу хикәятне матбугатта чыгара алган булыр идем! Моның өчен бөтен шартлар да бар иде. Беренчедән, Биктимер абзыкаебызны барлык авыл үз күрә, үлеп ярата, исем-шәрәфләрен ишетү белән теләсә-теләмәсә дә авызы ерыла башлый... Икенчедән, ул болай да ихтирамга лаек, тырыш зат. Колхозыбызның У-2 дигән бердәнбер «кәлүсни» трахтырының ике уңган трахтырчысының берсе – нәкъ шул Биктимер абзам иде. Аның турында беләселәре килеп, кем әйтмешли, газета битләре саргайган. Яз гына! Гади «трахтырчы» түгел, ә ахылдап өскә менеп килгән чын трахтырчы. Алар Сабир абзый белән тәүлекне урталай бүлеп эшлиләр һәм яшиләр. Кайчан эсминәгә чыгалар да, кайчан аны алмашалар, кайчан йокларга яталар да, кайчан күзләрен тырнап йокыларыннан сикереп торалар – монысын Аллаһы Тәгалә белән үзләре генә беләләр.

Без, ул чактагы атлы замананың күбәчүмәләләре аша сикереп-атлап, эскерт башларына үрмәләгән малай-шалай, Биктимер абзыебыз күзгә чалынган саен, борыныбыз белән кош тоткандай шатланып, аны куып җитәбез һәм үзебез хикәятне бар нечкәлекләре белән белмәсәк тә, «Лапаты не яблыкы килә!», «Лапаты не яблыкы килә!» дип такмаклый-такмаклый сырып алабыз да, әле генә сөрелгән җир буйлап селәүчен чүпләгән кара каргалар сыман артыннан озата барабыз. Бу минутта ул баштан аяк безнең карамакта. Кабарынкы бит алмасындагы чокыры, ямьшек борыны, маңгаена ишелеп төшкән тирле чәч учмасы, шулай ук кабарынкы, бераз салынып торган иреннәренә кадәр безнеке. Олы кешегә болай тота-каба бәйләнүгә, икенче берәү булса, үпкәләр, куркытыр өчен, янәшә-тирәсеннән тал-таяк эзләп селтәнергә дә күп сорамас иде. Ә ул – юк, хикмәтнең хикмәте – эндәшми-нитми, үзегездән олы кешене ник котыртасыз, дип тә үрсәләнми, үртәлми, куркытмый-әркетми, киресенчә, йөзләре көзге кебек ачылып, яктырып китә. Әнә, башкаларга кирәк булу куанычын шулай эчтән йотып алган да, «Әйе, шундый «лапаты» булырга насыйп иткәч, туганкайларым, нихәл итәем, лапаты булып калдым инде», дигәндәй, елмаеп атлавын дәвам итә...

Мин сөрелгән кара җирне юкка гына телгә алмаганмын икән шул. Биктимер абзыебызның өс киеме, әгәр аны кием дип атарга мөмкин булса, тач шул җир сыман каешланып, хром сыман ялтырап тора. Чем-кара, отыры да кара. Ә үзе... әйтерсең, шахтасыннан чыкканда, миннән монысы да калмасын, дигәндәй, өстәп дегет белән юынган. Күзләре генә җемелдәп тора. Әмма!.. Биктимер абзабызның йөзе һәм кием-салымнары никадәр дегеттәй кара булган саен, чырае шулкадәр дә якты иде. Гүя елмаю өчен генә яратылган. Әйткәнемчә, ачулана белми. Ачулануның нәрсә икәнлеген гомумән дә күз алдына китерә алмый кебек. Кая барса, аны без, малай-шалайның, ихахай-михахае озатып йөри. Озын колак хәбәрләренә ышанган хәлдә, бездән утыз-кырык чакрымда яткан Зәйпә авылы кызы Миңлебикә сылу Биктимергә нәкъ әнә шул ачулана белмәгәне өчен кияүгә чыккан, имеш.

Аннан, галиҗәнап Биктимер кардәшебез башка кешеләрдәгечә гадәти күлмәк-чалбарда да түгел, ә җәен дә кышын да барысы берьюлы эчтән бәйләнеп, кушылып, пычак үткерли торган беләү сыман ялтырап, берьюлы киелә-салына торган бербөтен кием ишарәтендә гомер итә иде: күлмәге чалбарга, чалбар балаклары эчтән тагын бер ниндидер сәер «аяк савыты»на барып тоташканлыгы сизелеп тора. Үзләрен аерым күрү мөмкин булмагач, берсен икенчесеннән аерып алып та булмый. Аяклары шыпылдап кереп утырган шул әкәмәте нәрсә – ботинкамы ул? Солдаттан кайткан кунычлы кирза итекме? Алай дисәң, ул хәрби хезмәттә дә булмаган. Әллә бәрән тиреләреннән тегелгән көяз читекме? Әллә киез итектә, бу яклар теле белән әйтсәк, йон пимадамы? Юк, каян алсын ул мондый алпавытлар байлыгын? Кайберәүләр ул шушы корама киемен, имеш, мунча кергәндә генә сала икән, дип тел чарлый. Дөресен әйткәндә, анысын инде җәмәгате Миңлебикә җиңги генә анык әйтә ала. Берсе икенчесе белән үзара камил тоташкан кием серләрен дә ул гына белә. Биктимеренең чалбар балаклары эченнән кия торган киез катасын аңа нәкъ шушы җиңгәчәй тегеп кидерде бит. Ул аны ревматизмыннан да саклый, җитмәсә, йомшак та, кышын җылы, җәйге челләләрдә тирләтми-пошлыктырмый. Аның уңай сыйфатларын башка бер генә илнең, халыкның, милләтнең, кавемнең, кабиләнең аяк киемендә дә очрата алмассың.

Хикмәтле Биктимер абзый белән гомер итүче Миңлебикә җиңги үзе дә хикмәтле асаба бит әле. Иреннән бер башка диярлек озын, туры гәүдәле ул. Хатын-кызларга хас тән йомрылары, буй-сын түгәрәкләре, калын чәч толымнары белән әллә ни күзгә ташлана алмыйдыр, бәлки. Аның хатын-кыз затыннан булуын колак йомшакларыннан ерак тарафларга елтылдап күренгән алкалары гына раслап тора. Гади алтын алка булмаганга шундый алар. Бәлки чын алтын да түгелдер. Биктимере алтын дигәч, аның чынлап та шулай булуына Миңлебикәсе дә ышанган. Ышанырлык та шул. Ике еллаган тана хакына төшереп, Биктимере Карамалы базарыннан алып кайтты бит аларны. Тагын да шунысы, менә ничәмә-ничә ел инде бергә яшәсәләр дә, әлегә ни сәбәпледер балалары булмаган кебек, ачуланышканнары да юк. Нишләптер авырга узмый ул. Әллә шул авыр күтәргәнгә узмыймы? Тукта, аның күтәргәне шулай авырмыни? Авыл кешесе өчен нәрсә инде ул ун кила-бер пот йөк? Әмма Миңлебикә йөрәк тамырындагы өметен өзми: аның бик тә бала табасы, нәселен-өммәтен ишәйтәсе килә. Ул шуңа ышана да. Кояш баткан, икәүләшеп йокларга ауган, Биктимере белән түшәк уртаклашкан саен, эчтән генә бәби тели ул. Әмма бәби дигән бөек бәрәкәт әле һаман да кыңгырау кыңгырдатмый. Бу хакта кальбендә өлгереп килгән үпкәсен иренә сиздергәне юк әлегә. Куркып та куя: каян белергә, кемнән әле ул: ирдәнме? Хатыннанмы?

Дөрес, аның хатын-кыз халкына хас булганча, «җитешсез сыйфатларны» хәттин ашкан күләмдә таба алган Миңлебикәнең ире белән бик тә сүзгә килеп, аны утлы табада кыздырып алырга теләгән чаклары була. Хатын-кыз өлешенә төшкән газаплы ләззәт– рәхәтләнеп әрләшеп-талашып алудан читтә яшисе килми аның. Барыбер хатын-кыз исәбендә каласы килә. Юк, кызмый Биктимере. Аптырагач, үртәп, «Лапаты не яблыкы!» турында сөйлә әле, дип тә карый. Юк, сөйләми ул хатынына теге хикәятне. Теле ачылмый. Елмая гына. Башкаларга да сөйләми. Күрше авылдан Днипрәгистә үзе белән бергә булган Фазыл алып кайтып тараткан бит ул сәер кушаматны. Шул бер чүп мәзәк аны гомерлеккә «лапатылы» иткән бит. Юк, Биктимердән барыбер сөйләтәчәк ул ошбу «чүп мәзәкне». Бер түшәктә йоклап, шуны да булдырмагач. Сәгате җитәр!..

Әмма әлегә Биктимернең ачуын китерү мөмкин түгел. Ю-у-ук!.. Күпме генә тырышып карамады – булмый тек булмый. Кузгалмый, трахтыры шикелле, дырылдатып кызмый-кыздырттырмый Биктимер. Әллә инде чынлап та моторының магнитасы чыланган?

Ачуланышуга ирешү мәсьәләсендә ул гореф-гадәтебездә борынгыдан сакланып килгән кайнана-килен табигатеннән чыгып, җиңел генә кайнанасы Мәрзия ярдәмгә килер дип уйлаган иде. Әмма анысыннан да фәтва булмады. Әйтешеп, бер-берең белән өзгәләшеп китәр өчен, сәбәпләр кычкырып яткан урында да, шул сәбәпләрнең үзләрен юкка чыгара. Пышт итә дә сүндерә. Кайнаналар арасында сирәк хәл: кемгә диген – киленгә! – йомшак, тәмле телле, менә гажәп! Орылмый-сугылмый, тегенди-мондый гайрәтле сүзне күңеленә сеңдереп, баса да куя. Бар белгәне – җәен бәләкәй арба, кышын – бәләкәй чана. Арба-чананың саплары аның үз төкрегеннән шомарган.

Әйтерсең дегет белән юынгандай кап-кара улы Биктимер тешле трахтыры белән кара туфракка кадалып, өенә кайтып та кермичә көне-төне «Күмәк көч» колхозын алга сөйрәсә, Мәрзия абыстай үзләреннән тыш ятим-ятимә авылдашларына утынын-печәнен ташышып, барча авылны алга өстери. Менә кайда ул трахтыр! Сугыштан соң йөз егерме йортның җитмешендә ирсез калган хатыннар, ятим балаларның һәркайсына алмашлап җитешә, диярсең. Куркыныч елларда да намазын ташламаган өчен, Мәрзия түтине авыл халкы, яратып, «Абыстай» дип йөртә.

Гел генә җиргә иелеп йөк тартудан булса кирәк, аның гәүдәсе бераз чүгеп, аркасына чак кына сизелерлек итеп орысы калыккан. Юк, Аллага шөкер, болай карауга гәүдәсенең бар әгъзалары үз урынында төгәл.

Буй-сыны да сынмаган-ватылмаган, аркасындагы кечкенә бөкресен халык ничектер игътибарга да алмый, гүя ул бар халык байлыгы – табигатьтән килгән бер гарип камиллек: абыстайның аркасы киләчәккә таба авыр йөк сөйрәгәнгә күрә генә шулай гел алга өндәгән өндәү билгесеннән тамагы мәңге туймас сорау билгесенә әверелеп, гомерлеккә катып калган, диярсең...

(Дәвамы киләсе санда).

Ялчыгол – олуг гыйлем иясе

Казанда 2009 елда Дамир Гарифуллинның “Чырагы нур сибә бүген дә...” дигән китабын “Сүз” нәшриятының баш мөхәррире Шаһинур Мостафин кулыма биреп: “Син Тукай белән Зәйтүнәнең “Мәңгелек мәхәббәтен” язган кеше буларак белеп тор, бөек шагыйребезнең иң беренче укыган китабы сезнең як шәхесе – Таҗетдин Ялчыголныкы”, диде. “Ул да булса “Рисаләи Газизә” – тарихи китап!”, дип өстәп куйды. Аңа рәхмәтләр укып, хәтерне яңартып, Габдулла Тукайның бәләкәй чакта бер китабы булып, “Исемдә калганнар” әсәрендә язылганча: “Кырлайда чакта тик “Газизә” вә “Сөбател гаҗизин”нәр укыган...” дигән җирен һәм әлеге китапның иҗатчысы Таҗетдин Ялчыгол икәнен теркәп куйган идем дәфтәремә. Ятим Тукайның Газизә исеменә аеруча ярату хисләре шул ук әсәрендә, асрауга алынгач: “Әни булганы Газизә исемле иде”, – дип язганы һәм бердәнбер апасы Троицкидагы Газизә белән бәйле булгандыр, дип тә уйлап куйган идем. Бәхетемә, кулыма 2014 елда чыккан Таҗетдин Ялчыголның “Рисаләи Газизә” әсәре килеп иреште һәм күп нәрсәләр ачыкланды – бу китап XIX гасыр азагында да (Апушка да) киң мәгълүматлы гыйльмия әсбабе булган. Әсәр Таҗетдиннең үсмер кызы Газизәгә атап язылган бит. Монда күп жанрлы иҗат: әкият, бәян, кыйсса, мөнәҗәт, бәет, хикәятләр – тәрбияви чимал. Китапның төп өлеше XVII гасырда яшәгән төрки шагыйрь Суфи Аллаһиярның “Сөбател гаҗизин” (“Гаҗизләрнең ныклыгы”) исемле әсәренә язылган Ялчыголның шәрехләүләреннән тора. Таҗетдиннең үзенең дә шактый гына шигырьләре, хикәятләре бирелә.

Язылышы буенча заман таләпләренә тәңгәл китереп, әлеге китап фәнни яктан да, әдәби караштан да галим Хатыйп Миңнегулов тарафыннан зур игътибар белән хәзерләнгән. Ике гасыр элек кулланылган гарәпчә график язмаларны бүгенге татар телендә аңлатмалар биреп укучыга җиткерү – бик зур хезмәт! Аның әлеге басмага 33 битлек кереш сүзе – аерым фәнни җәүһәр. Казанда “Хозур” нәшриятында 492 битлек китапны хәзерләп өч мең тираж белән бастыру һәм халыкка тарату – бу инде изге эшне оештыручы Таҗетдин Ялчыголның әлеге замандагы варисы Әсгать Сәфәровның күркәм гамәле.

Әлбәттә, элегрәк тә очратканым бар иде Ялчыголның хезмәтләрен. Аларны фәнни дөньяга чыгаруда күп көч салган, Идел–Урал халыкларының шәҗәрәләре белгече академик Раил Кузеев белән 1990 елларда Башкортстанның 17 районын урап чыккан идек. Минем Баулыда урта белем алганны шәйләгәч: “Сезнең районда бик зур шәҗәрәләргә тап булдык”, дип Сәлмән фарсыдан Хәбибуллага кадәрле язылган ядкәр дә кертелгән китабын бүләк итте. Бу җыентык өлешчә үземә “Безнең кавем – утыз буын” исемле Нурислам Хәбипов нәселе турында китап чыгарырга этәргеч булды. Ә инде Сәлмән шәҗәрәсенең гарәпчә язмалы сурәтен миңа 2009 елда Анкарада Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесе рәисе Күксал Топтан бүләк итте. Менә кай тарафларга барып җитә ул “Шәҗәрәләр” исемле тылсымлы язмалар! Ә инде сүзебез Таҗетдин язып калдырган һәм үзенең нәселен дә шуңа тоташтырган Әйлеләр (Айлы) шәҗәрәсенә күчкәч, мөхтәрәм Раил Кузеев: “Ялчыгол – безнең яклар кавемнәренең тарихын язып калдырган XVIII–XIX гасырларның олуг шәхесе”, дип әйтеп куйды.

Әйлеләр шәҗәрәсен төзеп Таҗетдин мулла менә нинди сүзләр яза: “Без бөтен тырышлыгыбызны куеп, сезгә инша яздык, Адәм галәйһиссәләмнән башлап, үзебезнең тарафларга кадәр. Сез дә, безнең кебек, тырышлыклар күрсәтегез”. Әлеге Әйлеләр шәҗәрәсен ул улларына васыятьнамә итеп язып, 461 юллык тарихи әсәр калдыра. Бу васыятен аның улы Баһаветдин 1812 елда үзенең дәфтәренә күчергәне мәгълүм һәм шул язмадан тарихка кереп китә.

Ялчыголның әлеге язмасында бик күп мәгълүмат тупланган: Адәм чорыннан Болгар дәүләте төзелү вакытына хәтле дәверләр шәхесләре; Мөхәммәт пәйгамбәрнең өч дәвамчысы Болгар җиренә килеп Ислам динен таратучылар булуы турында; шагыйрь Кол Гали тормышы һәм кыскача гына үзенең мәҗмугаи хәлен тасвирлап китә.

Төбәкчеләр кулланышында киң таралган “Адәмнән Юрматы бийгә” һәм аннан соң авыллар һәм аймакларга” дигән күп буынлы шәҗәрәдә Т.Ялчыголның иң беренче гыйлемле хезмәтләреннән “Таварихы Болгарийә” дигән әсәре кулланыла. Анда дөньяда билгеле Адәмнән Мөхәммәт пәйгамбәргә хәтле 54 буынлы шәҗәрәне кулланып, тагын үзенең эзләнүләре белән, Ялчыголлар нәселенә барып чыга торган 86 буынны барлый һәм язып куя: “Мулла Таҗетдин – әфәнде “Рисаләи Газизә”не иҗат итүче” дип. Тагын әлеге шәҗәрәләргә Таҗетдин мулла Шабан ханнан Насырханга дигән, 923 кешене үз эченә алган нәсел агачын өстәп яза. Нәкъ шушы Юрматылар буыннарын барлавында күрәбез – Алмалы ханның (Алмалы солтан дип тә йөртелә) Юрматы би дигән улы туа. Юрматының бер улы Юрми би була. Тагын бер Юрматылар шәҗәрәсендә аның икенче улы Азнай – староста дип әйтелә. Болар инде безнең якта XVI гасыр уртасында эз калдырган шәхесләр. Менә шундый тарих чоңгылларына кереп чумарлык хатирәләрне барлаган Т.Ялчыгол үзенең әсәрләрендә.

Аның тормыш юлы җентекләп тикшерелмәгән әле. Әсәрләре кайчан басылуы билгеле: иҗатчыга бик газиз “Газизәсе” үзе вафат булгач кына, 1847 елда башта Санкт-Петербургта, аннан соң 1850 елдан башлап Казанда берничә мәртәбә бастырылып чыгарыла һәм тарихи, дини гыйлем үзләштерүчеләрнең яраткан китабы була.

Ялчыгол XVIII гасыр ахырында Әстерханда, Дагыстанда яши, Истанбулда гыйлем эстәп кайта. Соңрак Казан, Оренбург губерналары авылларында укыта. Аның иҗатыннан тагын “Фава иде Бәхавийә” исемле әсәре дә билгеле. Күпчелек китаплары тарихны, әдәбиятны, халык медицинасын шәрехләүгә һәм кешеләргә куллану максаты белән сугарылган. Ул 1838 елда Зәй буендагы Имәнлебаш авылында авырулар дәвалап йөргәндә вафат була. Туган җире билгеле түгел иде. Күптән түгел Ялчыголның тормышын, иҗатын өйрәнүче Д.Гарифуллин безгә Таҗетдиннең Азнакай ягында Чалпы авылында тууы турында мәгълүмат җиткерде һәм язмаларын бирде. Дамир ага архив документларында 1820 елның 13 августында Минзәләдә земство суды тәкъдиме буенча Т.Ялчыголның җавапка тартылып сорау алыну кәгазьләрен таба. Аны өяздә мөселманнарны чукындыруга каршы торганы өчен һәм чукынганнарны ислам диненә кире кайтырга өндәп йөрүдә гаепләргә тырышалар. Әлбәттә, мәчетләрне җимерүгә, мәхәлләләрне таркатуга каршы Ялчыголдай гыйлемле, диндар шәхесләр генә көрәшә ала.

Шул судта үзенең Таҗетдин исемен, Якшыгол улы икәнен, 57 яшьтә булуын һәм Бөгелмә өязе Чалпы авылында тууын әйтә. Хәзрәт эшнең четерекле икәнен истә тотып, судта дөрес мәгълүмат бирергә имза куйгач, төгәл яшен әйткәндер, дип фаразлыйк. Шулай итеп Таҗетдин Ялчыгол 1763 елда Чалпы авылында туган дип исәплибез.

Әтисе Ялчыгол (Яхшыгол) Мәмбәтколны юлда чирләп китеп, Мамадыш өязенең Урта Сөн авылында җирләгәч, Таҗетдин бу салада өч ел мәдрәсәдә укыта. Тагын биш дистә елдан артык гомерен Зәй буйларында Җирекле (Зирекле, Каенлы), Кызыл Чапчак карьясендә, Мәлем авылында үткәреп ислам динен индерүче, чукындыруга каршы көрәшүче, абызлар хәрәкәтен җитәкләүчегә әверелә. Мөселман җанлы абыз “саклаучы да, яклаучы да” булып, руханиларның укымышлы шәхесе дәрәҗәсендә тарихка кереп кала.

Зәй районында Таҗетдин Ялчыголның мирасын мәңгеләштерүдә күп эшләр башкарыла. Киләсе 2023 елда якташыбызның тууына 260 ел булу уңаеннан туган ягы Азнакайда да лаеклы чаралар ниятләштерелер дигән өметтә калыйк. Тарихи мирас киләчәк буыннарга да барып ирешсен иде.

Мирсәй ГАРИФ.

Әмирхан ага хаты

1990 елларда Сирин иҗаты белән кызыксына башлагач, минем алга аның турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат табу бурычы килеп басты. Чөнки, репрессияләнгән шагыйрь буларак, аның иҗаты хәзерге әдәби кулланылыштан бөтенләй төшеп калган булып чыкты. Аны өйрәнүче дә булмаган, әсәрләре дә, 1959 елда ук чыккан кечкенә генә 54 битле китабын санамаганда, матбугатта басылмаган, иҗаты турында мәкаләләр дә язылмаган. Мәсәлән, алты томлык “Татар әдәбияты тарихы”ның 4нче томында (1989), 1930 еллар поэзиясе турындагы мәкаләдә аның исеме берничә урында гына башка шагыйрьләр исемнәре белән рәттән искә алынып китә, ә иҗатына да, тормыш юлына да тукталынмый. Шуңа күрә мин, өлкән яшьтәге язучыларга мөрәҗәгать итеп, алардан Сирин турында сораша башладым. 1990 елның 26 гыйнварында безнең Чаллы педагогика институтында үзенең сөрген тормышы турында “Колыма хикәяләре” дигән китап чыгарган Ибраһим ага Сәлахов белән очрашу кичәсе булды. Очрашу төгәлләнгәч, аның янына барып: “Сез Сирин дигән шагыйрьне белә идегезме?” – дип сорадым. Ул: “Сиринне яхшы белә идем. Иң алдынгы, иң хөрмәтле шагыйрь иде. Соңгы язмышын белмим”, – дип җавап бирде.

Шундый ук сорау язып, мин Әмирхан ага Еникигә дә хат юлладым. Ул миңа менә болай дип җавап бирде.

“Әнвәр туган!

Хатыгызны күптән алсам да, моңарчы җавап язарга форсат табалмадым. Ике бәйрәм арасында Уфага да барып кайттым. Сез инде мине кичерегез!

Сирин иҗатын җыярга һәм өйрәнергә керешүегез бик кирәкле, күркәм эш. Татар поэзиясендә аның берәүнекенә дә охшамаган үз урыны бар. Шәхес буларак та ул бик күпләрдән аерылып тора иде.

Билгеле, без якын танышлар идек. Егерменче елларның урталарыннан алып, утызынчы елларның башына кадәр әдәбият дөньясында бергә аралашып йөрдек. Мәрхүм шагыйрь минем хәтеремдә хәзер дә әле ачык саклана. Ләкин мин аның шәхси тормышын аз беләм, чөнки безгә бу җәһәттән аралашырга туры килмәде. Шулай да мин шагыйрь Сирин турында белгәннәремне кыскача бер истәлек итеп яза алыр идем. Тик кайчанрак – хәзергә өзеп кенә әйтә алмыйм. Бөтен эш минем сәламәтлеккә һәм вакыт җиткерүгә бәйләнеп тора. Ләкин Сезнең үтенечне мин ничек тә истә тотарга тырышачакмын. Бәлки, үти дә алырмын, Ходай кушса!

Хәзергә әйтәсе килгәнем шул. Башлаган эшегездә зур уңышлар телим. Соң булса да уң булсын!

Хөрмәт һәм сәлам белән: Әмирхан Еники. 15 / V – 93 ел.”

Әмма, кызганыч, сәламәтлеге какшапмы, Әмирхан ага Сирин турындагы истәлекләрен яза алмады. Әгәр язса, безнең Сирин шәхесен күзаллавыбызга зур өлеш кертсән булыр иде. Ә аның бу хаты минем архивта иң күренекле урында саклана.

Әнвәр ШӘРИПОВ,
филология фәннәре докторы.

«МИН БУШЛЫК

Һөнәри рәссам, керамика остасы Надия Миңнәхмәтова Чаллы шәһәрендә туган. Әлеге талант иясе бүген Татарстанда яшәмәсә дә, күңеле түрендә саклanган милли хисләре белән һәрчак горурлана. «Татар мәдәниятен һәм татар бизәкләрен бик яратам», – ди иҗатчы. Хәзер ул Ленинград өлкәсендәге Стрельна бистәсендә яшәп иҗат итә.

Керамика өлкәсендә чын оста булып, уңышка ирешә алучылар күп түгел. Моның өчен зур тырышлык сорала. Надия ханымның тормышы да шуны раслый.

Иҗатчы бу хакта болай искә ала: «Татарстанда туып-үстем. Әнием Рузия– икътисадчы, ә әтием Рәшит... мин аны бик хәтерләмим дә, чөнки әти-әниемнең гаиләсе мин бик кечкенә чакта ук таркалган. Татар мәктәбендә укытучылар булып эшләгән әбием һәм бабам гаиләсендә үстем. Дәү әнием Сәкинә – математика, ә дәү әтием Нурулла физика дәресен укытты. Кукмарада малларыбыз, тавыклар, бакча... бары да бар иде. Калкулыклары, киң басулары, Норма елгасы да булган Кукмара бик истә калды. Балачагымда татар халык көйләре, классик көйләребез, Салих Сәйдәшев иҗаты, милли җырларыбыз күп булды – барысы да күңел түрендә саклана! Мин шушы кече ватанымның җырларын җырлап кинәнәм. Бүген әнием Санкт-Петербургта гомер итә. Ә без гаиләбез белән шул Кукмара якларын хәтерләткән Стрельнада яшибез.

Сынлы сәнгать хакында мәгълүматларны бөртекләп кенә җыярлык еллар иде мин үскән чор. Туганнарыбыз арасыннан Ленинградка баручылар табылды һәм алар Эрмитаж хакында, иллюстрацияле, кечкенә китапчык алып кайтты. Аны һәр көн караштырып, рәсемнәр кырына бишле билгеләре тезә идем... Әбием дә, бабам да һәр көн дәфтәрләргә билге куя иде бит... Безнең тирәдә үзле балчык та бар иде, мин аннан ниләрдер әвәләп тә карадым әле. 1988 елда әнием белән Түбән Камага киттек. Мине баштарак чаңгычылар, нәфис гимнастика секцияләренә йөрттеләр. Ә минем рәссам буласым килә иде. Ниһаять, сынлы сәнгать мәктәбендә укый башладым! Рәссамлык җиңде, ләкин мәктәптәге әдәбият укытучыларым әдәбиятка мәхәббәт уятты һәм мин Казан дәүләт университетының филология факультетына укырга керергә булдым. Читтән торып укыдым һәм Түбән Камадагы мәктәпләрнең берсендә рәссам-бизәүче булып эшләдем. Бервакыт балалар өчен оештырылган керамика дәресләрен карарга туры килде. Бары да шуннан башланды! Әлеге укытучы мине тагын бер керамика остасы янына алып барды һәм аның киштәләрендәге вазаларны күреп сокландым. Университеттагы уку тәртибе бик күңелсез булып тоелды. Шул остадан: «Керамика сәнгатенә кайда укып була?» – дип сорадым. Ул үзе Көнгердә белем алган икән, мин дә шул каланы сайладым. Кыскасы, Урал, Пермь яклары мине дә үзенә тартты».

Надия Көнгер сынлы сәнгать-сәнәгать лицеенда укый. Уку еллары – аның өчен иң бәхетле чак, чөнки нәкъ шул чорда булачак керамика остасы андагы остаханәдә үзле балчыктан көне-төне эшләнмәләр ясарга өйрәнә. Ә укытучы-остазы Рәисә Игнатьевна аның татар кызларына хас тырышлыгына сокланып, остаханә ачкычын Надиягә ышанып тапшыра. Остаханәдәге мичтән чыккан хезмәтләрен күреп, аның белән бергәләп шатлана. Студент кыз тагын чиләк-чиләк үзле балчык ташып, янә яңа әйберләр ясый.

«Иҗат кешеләре еш кына үз уйларында була... Мин дә шундый инсан идем. «Эчке Монголия»м бар иде, мин шунда яшәдем. Ә анда, уй-фикерләремдәге монгол далаларында – киңлек тә, хөрлек тә, иркенлек тә, барысы да булды, – дип искә ала Н.Миңнәхмәтова. – Лицей мине рухландырды! Шул чакта бинабызда кайчандыр шушы уку йортын тәмамлап, Европада эшләп кайткан керамика остасы Мацумаро Хан да иҗат белән шөгыльләнде. Ә мин аны читтән генә күзәтеп тордым. Аның иҗаты миңа алга таба да укырга кирәклеген төшендерде».

Әнисенең эштән кыскартылуы сәбәпле, Надиягә сувенирлар ясап сатарга да туры килгән ул елларда. Алар Пермь галереяларында сатылган. Аннары инде Санкт-Петербургтагы А.Л.Штиглиц исемендәге сынлы сәнгать-сәнәгать академиясенең әзерлек курсында укыганда да, студент кыз каладагы бер остаханәдә керамика әйберләре ясаган, академиядә укыганда да сувенирлар ясап сатуын дәвам иткән.

«Уку тәмамланыр алдыннан, перспектива күрмәдем. Кайда эшләргә?.. Бу хакта хәтта укытучыларыбыз да белмәде, – ди әңгәмәдәшем. – Янә сувенир ясаргамы?! Ә ни өчен академия тәмамладым соң? Мондый уйлар бик еш җәфалады. Хәтта Император фарфор заводына эшкә урнашыргамы икән әллә, дигән чагым да булды. Ләкин ул заводтагы «крепостной» рәссамнар үзләре дә моңа шат түгел иде. Мин тынчу атмосферада, ап-ак фарфор өслеккә генә рәсем ясап утыра алачак иҗатчы түгел идем. Инде күптән төсле эшләнмәләр иҗат итәргә күнеккән идем. Әлеге теләк-ниятем барып чыкмады, ә бу яхшыга гына булган. Антон белән бергә укыдык без. Ирем белән бергәләп Ленинград өлкәсенең Мандроги авылында эшли башладым. Шушы чорда башкаларны савыт-саба ясарга өйрәттем, осталык дәресләрен күп үткәрергә туры килде. Бу безнең вазифабызга керә иде. Дәресләрне һәр көн саен үткәрә торгач, талчыктым, эчке халәтемә нидер булды, күңелемдә нидер сынды. Мин хәзер осталык дәресләре бирмим. Әлеге туйдырган халәткә кире кайта алмыйм, арыдым. Гомумән, осталык дәресе дигән сүзләрне ишетсәм, калтырый башлыйм... Аннары үземдә педагоглык сәләте булуын да тоймыйм».

Иҗатчылар гаиләсендә бүген берсеннән-берсе кечкенә өч кыз бала үсә. Үз йортлары булу, ишекне ачып чыгуга ук җирне тою, берничә адым ераклыктагы гына остаханәне барлау, мәктәптә укый башлаган кызларының дәресләрен карашу... Болар барысы да Надия ханым җаваплылыгында. Әле буш вакыт табып, берничә сәгать булса да иҗат итәргә дә кирәк. Чөнки ул шунсыз тора алмый. Бу аның өчен сулыш алу белән бер!

Н.Миңнәхмәтова үзле балчыктан вазалар, кошлар, борычлар, боланнар, песиләр, чәчәкләр һәм үсемлекләр әвәләп ясый. Зәвыклы картиналарда, катлаулы бизәкле келәмнәрдә яисә матур чигешләрдә яшеренгән уй-фикерләргә, шифрланган тәҗрибәләргә яисә төрле хиссиятле хезмәтләргә охшаш булган, диварга элеп куярлык интерьер әсәрләре дә иҗат итә. «Шифрлау – яраткан шөгылем! Мин, ахрысы, символистлар армиясе сафыннандыр!» – ди ул.

Останың үзенчәлекле тоткычлы каһвә чынаякларына игътибар итик әле. Тоткычлар кызыл диңгез мәрҗәннәре формасында! Кайсыбер савыт-сабага елгалар буеннан җыелган кечкенә агач ботакларын да беркеткән ул. Аның «Төнге күктәге йолдызлар» хезмәте дә Күк йөзе илаһилыгын үзенчә искә төшерүеннән. «Йолдызлар, минем өчен, күк җисемнәре генә түгел, алар – инсаннарның хыяллары, максатка ирешүләре,

ЯРАТМЫЙМ!»

мәхәббәт символлары... Һәр кешенең дә аны алга таба өндәүче, шомлы дәверләрдә дә аңа юл күрсәтүче бер йолдызы була! Ул аңа һәрчак өмет өсти, хыялларын искә төшерә. Шуңа күрә йолдызларны мин еш сурәтлим», – ди иҗатчы.

Оста күн читекләргә хас бизәкләрне дә үз итә. Ул аларны иң чын һәм дә иң аутентик татар орнаментлары дип саный һәм исламга кадәрге (төрки) элементлар өстәлмәгән тарихыбыз кыйпылчыкларына тиңли. «Минемчә, бар төр «кучкар мөгезе» – безгә Себер буенча монгол аяк киемнәренә иярен килгән. Бу – безнең тарихыбызның бер өлеше, ә ул, миңа калса, безнең сынлы сәнгатебезне башкаларныкы белән тигезләгән исламлаштыруга караганда күпкә якын. Моннан тыш миңа җәннәт бакчалары темасы да ошый. Чөнки ул – ислам сәнгатендәге төп мотив!»

– Ә менә кузаклы борыч темасы, ул сезнең иҗатта ничек туды?

– Мин ишек өстенә шәмаил куелган авыл өендә үстем бит! Аларны ул елларда хәзрәтләр генә укый ала иде. Гади халык шәмаилләрне начарлыктан саклаучы язмалар дип кабул итте. Гарәп хәрефләре минем тарафымнан очлы, озынайтылган, динамик җисемнәр булып кабул ителә һәм пычак белән кылычларга охшап тора иде. Шушы «кылычлар» исә миңа борычларны хәтерләтте. Менә Аллаһ сүзен алсак... Әлиф хәрефе, әйтерсең хәнҗәр яисә кылыч, аннары аның белән өскә таба селтәп җибәрү – куркып калган кош күккә күтәрелгәндәй... Кайбер сүзләр минем өчен очар кошлар булып тоелды, ә икенчеләре – сыгылма үрмә үсемлекләрне, кайсылары өйләрне хәтерләтте... Балачагымда үзем танымаган шушындый матур һәм сихри язмаларга карап утыру кызык иде миңа. «Гаҗәеп, дип уйлый идем, ничек кешеләр бер-берсе белән шулай аңлашырга ният кылган икән?!.» Шуңадыр да, үсеп житкәч тә келәмнәргә, чигешләргә, күлмәк бизәмнәренә яшерелгән хәрефләрне һәм тамгаларны эзли башладым. Бер фикерләвемчә, бары да гади генә тоелды... Кузаклы борыч символы ул сюзане дип аталган чигештә гаҗәеп популяр бит. Бу мотив үзенең яндырып алу сәләте аркасында пәриләрне куркытырлык могҗизаи көчкә ия. Ул үз формасы, мәгънәсе буенча да миңа якын. Борыч аша утны сурәтләп була. Ул ялкын теленең туктап калган хәрәкәтенә тартым.

– Әйдә, иҗат идеяләрегезгә тукталыйк. Сез керамик диванығызның Казанда арт-объект буларак куелуын телисез дип беләм?

– Бераз гына аңлатыйм: әйтик, Казандагы «түбәтәй» дип йөртелгән милли бизәкле бина минем өчен куәтле илһам, нур чыганагы булып тора. Балачагымда беренче тапкыр күргәннән бирле – ул онытылмаслык хатирә һәм аңымда матурлык төшенчәсен формалаштырган бер символ. Менә күп еллар узгач, керамикачы буларак, шушы иҗади идеямне үземчә башкарып чыктым. Әлеге теләк-идеям шуннан гыйбарәт: бу – милли аппликацияләр белән капланган, елга ярына яисә берәр тыныч паркка куелырлык керамик диван. Мин Казанның бизәкле күнен бик яратам, ул – татарларда сакланып калган иң матур, иң аутентик визуаль сәнгать төрләренең берсе. Ләкин Казанда традицион читек орнаменты булган репликалы архитектура объектын бер-икене генә очратып була. Шул «Түбәтәй» белән Г.Камал театры бинасы гынадыр, мөгаен. Шәһәр мохитен шушындый милли бизәкле объектлар белән тулыландыру туристлар, Казан кунаклары өчен дә кызыклы булыр иде. Яраткан шәһәремне керамика арт-объекты белән бизисем килә! Әйе, бу Хива да, Бохара да түгел. Ләкин шул яклардагы матурлыкның бер кыйпылчыгын гына булса да бирегә өстисе иде! Бу диван әлеге һөнәрчелегебезне популярлаштыру да, татар башкаласына бер үзенчәлек өстәү дә булыр иде.

– Сез үз эшләнмәләрегезгә нокталы-сызыклы бизәкләрне дә күп өстисез.

– Чөнки әлеге алым ислам сәнгатенең бар төрләрендә дә диярлек кулланыла. Бу бит – «бушлыктан курку». Көнбатыш әдәбияты ислам мәдәниятенә хас бар иҗат эшләнмәләрен дә буш фон калдырмыйча, орнаментлар белән тутыруны шулай дип атый. Савыт-сабалардан алып архитектура корылмалары эчләрендә дә бит зур һәм кечкенә чәчәкләр, яфраклар, сабаклар, геометрик бизәмнәр бар... Табигать бушлыкны яратмый. Мөселман сәнгатендә мондый тулылык Аллаһы Тәгаләнең һәрдаим, өзлексез рәвештә иҗатта булуы белән тәңгәл. Шулай ук бушлыкны караңгылыкка һәм күп нәрсәләргә ышанмаучанлыкка тиңләштерү дә бар бит әле. Ислам – ул орнаментларны могҗизаи рәвештә мәгънәләштереп, аларны визуаль идентификацияләү өчен мөһим чара итеп сайлап алган мәдәниятләрнең берсе дә. Геометрик бизәкләр абсолют космос төзелеше идеяләрен аңлатса, үсемлекле бизәмнәр исә җәннәт белән бәйле ассоциацияләр тудыра. Мин инде күптәннән шундый «бушлыктан курку»га ия. Бушлык һавалы атмосферага бай булса да, анда барыбер ялкаулык, үз йөзең булмау сиземләнә...

Менә «Сабырлык касәсе» дип аталган тагын бер хезмәтем... Беркөн урманда йөргәндә «эльфлар касәсе» дип аталган гөмбәләрне очраттым. Кеп-кечкенә, алсу төстәге касәләр... Яңгыр явып узганга күрә, аларның һәрберсе су белән тулы иде. Шулчак мин: «Әгәр дә һәр касәдәге суны җыйсаң, хәйран су заты җыелачак икән бит», – дип уйландым. Бу бит – Ана образына юнәлдерүче этәргеч. Әни кеше төрле вакыйгаларга да аз-азлап, әмма көннәр, айлар, еллар буе сабыр итә. Мин шундый касәләрне әвәләргә булдым, соңрак күргәзмәләрдә дә бу теманың күпләргә таныш һәм якын булуына төшендем.

– Балчык эшләнмәләрегезне чыныктыру кыенмы?

– Төрле чыныктыру ысулларын, электрлы мичләрне дә кулландым, «раку» ысулын да... Агач ягып чыныктырырлык мичкә дә куйгаладым. Соңгысы – озак процесс булса да, эшләнмәләрне төрле төсләргә кертә, шул сәбәпле алар интерьерга килешер микән, дигән уйлар тумый. Менә бу эшләнмәләрем ипи төсендә булып чыкты, алар теләсә кайсы мохиткә дә яраклы.

– Киләчәктә сезне нинди эшләр көтә?

– Иҗади планнарымны бер дәфтәргә язып барам. Лаеклы ялга чыккач, күләмле сыннар ясап, аларны паркларга, сулыклар янына урнаштырыр идем! Керамик эшләнмәләр бик популяр. Аларны үзәк күргәзмәләргә, җитди галереяларга да куялар. Сыйфатлы эшләнмәләрне зур гына акчага да сатып була. Тик мин андый юлдан китә алырмынмы, фараз итү кыен. Әлегә эшләремне йорт интерьерлары өчен алалар. Кеше сыннары ясамыйм, боланнар иҗат итәм.

Бакчамны бик яратам, анда чәчәкләр үстерер, җимеш агачларын күбәйтер идем. Планетада үз җир кисәгең булу – ул зур шатлык! Аннары тауларны да яратам, аларга сәфәр кыласым килә. Тик мине, кая гына китсәм дә, ике-өч көннән Ватаным сагындыра. Мин шушы туфракта гына яши алам, мин – шушы җир агачы!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
23 сентябрь
№37, 2022

Байбаклар

Азнакай районы республиканың көньяк-көнбатышында урнашкан. Халкы 60 меңнән артык. Шуның 43 меңгә якыны – шәһәрдә, 17 мең ярымы авылларда яши. Халыкның 85 проценты – татарлар, калганы – төрле милләттән.

Азнакай – кара алтын төбәге. Аның территориясенә Ромашкино нефть катламының көнбатыш өлеше туры килә.

Район мәйданы буенча республикада 5 нче урында тора. Район үзәге булган Азнакай шәһәре Казаннан 376 чакрымда.

Төбәк үзенең Чатыр тавы (диңгез өслегеннән 321,7 метр), сөйкемле байбаклары һәм, әлбәттә инде, талантлы ул-кызлары белән татар дөньясына билгеле. Бу төбәктән язучылар Мәхмүт Хәсәнов, Марсель Гали, артистлар Н.Ихсанова, Ә.Шакиров, җырчылар З.Фәрхетдинова, Р.Галиев һ.б.лар чыккан.

● Чатыр тау җыеныннан күренеш.

Чатыр тау җыены

Азнакай турында сөйләгәндә иң әүвәл хәтергә Чатыр тау фольклор җыены килеп төшә. Бу җәйдә әлеге чара 12 нче тапкыр үтте. Башта табигатьнең гүзәл һәйкәле булган тауга районның үз мәдәният коллективлары җыелып бәйрәм оештырса, 2015 елдан җыен халыкара дәрәҗәдәге рухи бәйрәмгә әверелә. Җыенның максаты – гореф-гадәтләребезне, борынгы халык җырларын һәм биюләрен саклап калу, кардәш төрки халыкларны аралаштыру. Быел анда Татарстан, Башкортстан, Оренбург, Самара, Мәскәүдән 38 иҗат төркеме катнашты. Җыен «Чатыр тау җиле» дип аталган театральләштерелгән тамаша белән башланды. Төрки халыкларның көнкүрешен чагылдырган «Тарих аланы», «Чәк-чәк аланы», «Сөлге аланы», «Балачак аланы», «Халыклар дуслыгы» урамнары оештырылган иде. Биредә төрле милләт вәкилләре үз милли йолаларын, уен коралларын, бизәнү һәм көнкүреш әйберләрен, милли ризыкларын һәм милли җыр-биюләрен тәкъдим итте. Чатыр тау җыены үзенең ирекле рухы, табигать кочагында, тауда узуы белән үк гаҗәеп аурага ия. Аның ерак үткәннәребезне халкыбызга кайтару, тарихыбызны барлау, милли мәдәниятебезнең тамырларын сафландыруда файдасы бәхәссез. Һәр елдагыча, быелгы җыенга да язучылар, сәнгать әһелләре кунакка кайткан иде. Район хакиме Марсель әфәнде Шәйдуллин: «Чатыр тау җыены – безнең горурлыгыбыз ул», – диде.

Атказанган «Җанашым»

Җыенга илнең фольклор төркемнәрен җыя алган Азнакайның үзендә дә әнҗе бөртеге кебек коллективлар эшләп тора. «Җанашым» фольклор ансамбле – шуларның берсе. Коллектив район мәдәният йортында 2006 елда оештырыла, аның алыштыргысыз җитәкчесе – Гөлфия Әхмәтҗанова. Ансамбльгә йөрүчеләр барысы да яхшы җырлый, баян, тальян, скрипка, кубыз, курайда уйный. «Җанашым» артистлары татар халык җырларын башкара, милли йолаларны, уеннарны, биюләрне сәхнәдән күрсәтә. Азнакай артистлары республиканың күп сәхнәләрендә чыгыш ясарга өлгергән, Россия буйлап та милли сәнгатебезне күрсәтеп шактый юллар үткәннәр. 2017 елда ансамбльгә “Россия Федерациясенең атказанган халык иҗаты коллективы” исеме бирелгән.

Аксакал театр

Азнакайның үз халык театры да бар. Ул 1941 елда драма түгәрәге булып оеша, сугыш елларында да эшчәнлеген туктатмый. Авылларга йөреп, спектакль күрсәтәләр. 1951 елда театрга җитәкче булып Әлмәт театрыннан профессиональ артист Касыйм Еникиев килә. 1965 елда иҗади уңышлары өчен драмтүгәрәк Халык театры исеменә лаек була. Коллектив бүген Еникиев исемен йөртә. Касыйм Еникиев җитәкчелегендә Азнакай артистлары 40лап спектакль куялар.

2015 елдан Халык театрын Гөлсинә Җамалиева җитәкли. Коллективка яшьләр килә, «Кыю кызлар»ны куялар да, «Идел-йорт» фестивалендә 3 нче урынны алып кайталар. Соңрак «Урман эчләрендә урман» спектакле белән (Т. Миңнуллин) шул ук бәйгедә 2 нче урынны алалар. 2019 елда коллектив Татарстан хөкүмәтенең грантын ота. Үткән ел театр үзенең 80 еллыгын билгеләп үтте. Шуңа багышлап «Ханума» спектаклен куйганнар. Ике йөз меңлек костюмнар гына тектерелгән, яктырту җиһазлары сатып алынган. Премьера уңышлы үтә, бу тамаша белән «Идел-йорт» фестивалендә чыгыш ясап, инде 1 урынны алалар, 100 мең сумлык сертификатка ия булалар. Артистлар хәзер дә тик ятмый: М.Гыйләҗевнең «Ничек миллионер булырга?» әсәрен кую белән мәшгульләр.

●«Азнакай курчаклары»ның әнкәсе Галина Герк.

Атаклы уенчыклар

Азнакай бренды дәрәҗәсенә күтәрелгән «Актүбә уенчыгы»н ишетмәгән кеше юктыр. 1992 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Илсояр Сәләхованың җиңел кулы белән барлыкка килә ул. Балчыктан ясалучы уенчыкларның темасы: татар халкының борынгы көнкүреше, бәйрәмнәре, фольклор каһарманнары. «Актүбә уенчыгы»н хәзер Россиядә генә түгел, АКШ, Бөекбритания, Төркия һ.б. илләрдә дә очратырга була. Күптән түгел Мисырдагы бер нефть компаниясенең офисында очрашу вакытында азнакайлылар «Актүбә уенчыгы»н танып алган. Уенчыкларның берсе хәтта АКШның элеккеге президенты Билл Клинтонга да барып җитә, Ак Йорттан рәхмәт хаты да җибәрәләр.

Районда уенчыкларны яраталар, шулай булмаса, икенче бер бренд – «Азнакай курчаклары» канат ныгыта алмас иде. Ул 2012 елда оештырыла. Җан өреп җибәрүче әнкәсе – Галина Герк. Эшчәнлекләренең юнәлеше – кулдан эшләнгән милли курчаклар җитештерү, чигүле милли эшләнмәләр (түбәтәй, калфак, букчалар) әзерләү. Галина ханымның әтисе алман милләтеннән булса да, әнисе Мөнҗиядән аңа халкыбызга, рухиятенә тирән мәхәббәт күчкән һәм ул хисләр курчакларында да чагыла. «Актүбә уенчыгы»на да, «Азнакай курчаклары»на да хас уртак бер сыйфат: алар чын мәгънәсендә затлы, зәвыклы, өстәвенә, күңел җылысы кушып ясала. Шуңа күрә дә аларны дөньяның теләсә кайсы почмагында теләсә кемгә горурлык белән бүләк итәргә була. Әлеге ике бренд уенчыклары «Татарстанның иң яхшы товарлары» конкурсында күп тапкырлар лауреат булуын да искәртү урынлыдыр.

Азнакай таланты

Шәһәрнең туган якны өйрәнү музее белән танышканда да, үзе бер музей кебек санаторийны карап йөргәндә дә бер авторның беркемнекенә дә охшамаган искитмәле үзенчәлекле эшләренә тап булдык. Гаҗәеп бизәлештәге сандыклар, төрле сыннар, савыт-сабалардан ниндидер сер бөркелеп тора сыман. Боларны Азнакайның үз рәссамы Руслан Латыйпов ясый икән. Руслан Казанда сәнгать училищесын

●«Актүбә уенчыгы» шедеврлары.

иле Азнакай

тәмамлаган, Чаллыда һәм Казанда берничә күргәзмәсе дә үткән. Картиналар язудан тыш, ул сынчылык белән дә шөгыльләнә, Чаллы шәһәрен бизәп торган сыннар арасында ул иҗат иткәннәре дә бар. Күз явыбызны алган теге сыннарны исә ул полимер бауны эпоксид сумалада чылатып ясый икән. Сумала сеңдергән бауга ул форма бирә һәм сын шул формада ката. Әлеге техника белән 10 еллап шөгыльләнә, һәрбер эш нибары бер нөсхәдә иҗат ителә. Чатыр тау каршындагы Көрәшчеләр сыннарын да Руслан иҗат иткән. Рәссамның хәләл җефете Гөлнара да үзе кебек үк сәнгать кешесе – рәссам. Берничә ел элек Казандагы «Эрмитаж» үзәгендә аларның уртак күргәзмәләре дә үткән.

● Азнакай халык театры.

Киләчәк шәһәре Актүбә

Актүбә – шәһәр тибындагы бистә, анда 9 меңнән артык халык яши. Соңгы тапкыр без монда 20 еллап элек булган идек. Хәзер Актүбә танымаслык булып үзгәреп, заманчалашып маташа. Монда «Татнефть» идеясе һәм финанслары хисабына калдыксыз эшләүче, үз-үзен тулысынча энергия белән тәэмин итүче экологик инновацион хуҗалык төзиләр. Хәзер бистәне җылылык белән тәэмин итү, яктырту өчен 5 МВт энергия кирәк. Тиздән бу энергияне… сыер фермалары бирә башлаячак. Фермалар 11 мең баш малга исәпләнгән. Сыерларның табигый калдыкларыннан бүленеп чыккан метан газы эшкәртелеп, электроэнергия барлыкка китерәчәк. Тиреснең калдыклары корытыла, киптерелә, алардан торф чүмәкләре, ашламалар һ.б. ясалачак.

Бистәдә берничә яңа завод та төзелгән. Әйтик, пиролиз заводында агач калдыклары эшкәртеләчәк. Монда эшләп чыгарылган ягулык киләчәктә нефтькә алтернатива булыр дип көтелә. Агач калдыкларыннан биоойл һәм биочар ясала. Беренчесе – дегет кебек сыеклыктагы масса. Биочардан исә брикетлар ясала, сүз төтенсез яна торган ягулык турында бара. Аларны котельныйлар, теплицаларны җылыту өчен кулланып була.

Бистәнең барлык көнкүреш калдыклары да шул рәвешчә заводта эшкәртеләчәк. Бүген халыкны чүпне төрләргә бүлеп җыярга күнектерү бара. Бу, беренчедән, чүп полигоны төзү проблемасын хәл итә, икенчедән, кешеләргә чүпне чыгарган өчен түлисе булмый.

Заводларның тагын берсендә җылылык саклаучы материаллар җитештерелә. Махсус басуларда җитен, киндер, бескантус үстерелә, әлеге үсемлек массасы заводта чимал итеп кулланыла. Алардан кирпеч кебек блоклар ясала, аларны төзелештә, биналарны җылытуда кулланачаклар. Завод инде үз продукциясен сата да башлаган. Шундый ук заводларның икенчесендә үсемлекләрдәге целлюлоза эшкәртеләчәк. Әлеге завод та инде әзер, эшкә кешеләр алынган, якын көннәрдә эшләтеп җибәрәчәкләр. Бистәнең ике йөзләп кешесе яңа заводларда эшле булган. Бу заводлар – әлегә пилот проектлар гына, әгәр алар яхшы нәтиҗәләр күрсәтсә, зур заводлар төзү каралган.

«Татнефть» программасы буенча, бистәдәге йортларны яңача сипләү дә башланган. Комаров урамында урнашкан шундый ике йортны күреп үттек. Йортлар башта пластиктан арындырыла, тулысынча табигый материаллар белән сипләнә. Тәрәзәләргә махсус сыекча белән эшкәртелгән агач рамнар куела, балконнар витраж тәрәзәләр белән эшләнә. Йорт түбәләренә кояш батареялары урнаштырылган. Алар йортны тулысынча җылытырга җитә. Түбәдән аккан яңгыр, кар сулары махсус куышлыкка җыела һәм йорт тирәсендәге яшел зонаны сугару өчен кулланыла. Йорт тирәсендә утыргычлар куела, велосипед юллары ясала. Фатирларда энергия саклаучы колонкалар тора. Суның җылылыгын үзе көйләүче сенсор краннар куелган. Фатирдагы җылылыкны да һәркем үзенчә көйли ала һәм күпме куллана, шуның кадәр түли. Йортларда яшәүчеләр бу заманча ремонт өчен бер тиен дә түләми, барлык чыгымнарны кара алтынчылар каплый.

Бистәнең икенче санлы мәктәбе яныннан узабыз. Монда клонлаштыру лабораториясе урнашкан. «Татнефть»нең барлыгы 8 шундый лабораториясе бар, 3 се – Азнакайда, калганнары Әлмәттә. Әлеге лабораториядә агач үсентеләре клонлаштыралар. Питомниктан монда бер үсенте китерәләр. Ул – гөмбәчекләрсез, вирусларсыз махсус үстерелгән бәләкәй агач. Лабораториядә шундый бер үсентенең 3 клонын ясыйлар. Клоннарны биомассага утырталар, күпмедер вакыт үскәч, һәрберсен тагын клонлап, янә икешәр агач алалар. Бераз үскәч, аларны теплицага күчерәләр һәм метр ярымгача җиткерәләр. Аннары алар даими урынга утыртыла. Клонлаштырылган агачлар бернинди чирләргә дә бирешми, череми. Әйтик, усак агачына зур агач булып җитешү өчен 50 ел кирәк, ә клонланган агач 25 елда үсеп



● Руслан Латыйповның иҗат җимешләре.

җитә. 2нче мәктәп укучылары лабораториядә 128 мең шундый үсенте клонлаган, алар барысы да нефть районнары урманнарына, кырларына утыртылган.

Бистәнең канализация, су торбалары да тулысынча алыштырылачак, мәктәпләр тәртипкә китереләчәк, алар янында министадионнар төзеп куелачак. Гомумән, Азнакайда спортка игътибар зур. Актүбә урамнарына да хәзер «Челси» командасында уйнаучы якташ кызлары Алсу Абдуллинаның зур портретларын элеп куйганнар.

Шәһәр тибындагы бистәнең хакиме Александр Севастьянов – үзе дә Актүбәдә туып-үскән кеше, гомере буе нефть системасында эшләгән. Бистәнең заманча киләчәк шәһәренә әйләнәчәге турында ул рухланып сөйләп, яңа заводларны, фермаларны күрсәтеп йөрде, кызыклы экскурсия үткәрде. Туган җиребезгә кара алтыннан күпмедер бәрәкәт, файда калуын күреп канәгатьләнү кичердек. Нефть кайчан да булса бетәр, ә төзеп калдырылган заводлар, яңа технологияләр җөмһүриятебез өчен эшләвен дәвам итәр.

Эльмира СИРАҖИ.

● «Җанашым» фольклор ансамбле.

Гашыйклар урамы

Гашыйклар урамы Иске Кормаш авылында туган, шунда яшьлекләре үткән авылдашлар өчен очрашу, кавышу урамы булды. Халык телендә аны үз итеп Гыйшык урамы, дип йөртәләр. Бу урам бик чиста, тыныч, аулак урын булган, тезелеп үскән зур-зур өянкеләр матурлык кына түгел, серлелек тә өстәгән. Гашыйк парлар шунда очрашкан, мәхәббәт аңлашкан, өянкеләр төбендә вәгъдәләр куешкан. Хәзер инде бу урам бераз үзгәрде. Өянкеләре дә киселде, күп өйләрдә утлар да сүнде... Ләкин тәрәзәләрдә, ихаталарда җанлылык булмаса да, йөрәктә, күңелдә яшәгән яшьлек хатирәләре сүнми, сүрелми шул...

Иске Кормаш авылында үткән «Гыйшык урамы серләре» бәйрәме шул хакта сөйли дә инде. Авылда яшәүче һәм читтән авылын сагынып кайтучы өлкән буын да бик рәхәтләнеп яшьлек хатирәләре белән уртаклашты.

Гыйшык урамы яшь парларның кавышу урамы гына түгел икән әле. Ә иҗатчылар, күренекле шәхесләр урамы да! Авылыбызның ак әбисе булган Тәгъзимә Мөхәммәтдинова шушы урамда яшәгән. Ул – өч китап авторы. Теләкәй, Яңа Балтач авылларының тарихларын китап итеп чыгарган, композитор Илгиз Закиров белән берлектә безгә «Кормашым» җырын бүләк иткән һәм башка композиторлар белән дә бергә эшләгән шагыйрәбез дә. Авыл гимнына әверелгән «Кормашым» җырының даны бик еракларга таралган.

Ике китап авторы, авылыбызда яңа мәктәп төзүдә башлап йөргән, балалар тәрбияләүгә һәм белем бирүгә зур өлеш керткән, Татарстанның атказанган укытучысы Линиф абый Каһиров, аның тормыш иптәше Лена апа Мәхмүтова, колхозны ундүрт ел җитәкләгән Салахов Фазылҗан абый, күп еллар агроном булып эшләгән, «Почет билгесе» ордены кавалеры Галиев Заман абый, Татарстанның атказанган элемтә хезмәткәре – Шәйхетдинов Мөхәммәтислам абый, Татарстанның атказанган зоотехнигы Галимов Әбелкаес абый – барысы да шушы урам кешеләре.

Бәйрәмгә Гыйшык урамында яшәүчеләр бик әзерләнгән. Урамны уңган хуҗабикәләрнең кул эшләре – чиккән сөлге-кульяулыклар, матур гөлләр, картиналар бизәсә, өстәлдә гөрләп самовар кайнап утыра, ә табын уртасындагы хуш исле бәлешнең тәме еракларга таралган! Бәйрәм уен-көлке, җыр-бию белән бик матур итеп үрелеп барды. Урам тутырып авылыбыз гармунчыларының гармун тартып уйнавы да бөтен кунакларның күңеленә хуш килгәндер!

Әйе, урам бәйрәме хәзер күп кенә авылларның традициясенә әверелеп бара. Анда авылдашлар, якыннар, күптән очрашмаган дус-танышлар очраша. Ә иң мөһиме – халык беразга гына булса да яшьлегенә кайта: матур хатирәләрен барлый, уйлана, сагына...

Гөлсәрия НӘГЫЙМОВА.
Актаныш районы
Иске Кормаш авылы.

Репрессияләр

(Дәвамы. Башы 35-36 нчы саннарда).

Шундый ук язмышка дучар ителгән һәм ачы тормыш сынавы үткән дүрт татар хәрби разведчигы – генерал-майор Минзакир Әпсәләмов, полковниклар Хөсәен Мәүлитов, Һади Маликов һәм Миргазыян Крыймов ирешкән үрләр дә күпләр өчен сабак, олы үрнәк булырлык. Башка милләтләр тарихында күрелмәгән хәл: 1924 елның июненнән алып 1935 елның ноябренә кадәрге чорда Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабының разведка бүлеге белән нәкъ менә шулар җитәкчелек итә. Каһарман милләттәшләребезнең һәркайсысына багышлап аерым әсәр язарлык һәм Якуб Чанышев белән бергә, һәркайсының исемнәрен Казан урамнарына кушарлык. Тик әлегә Татар иле башкаласында Хөсәен Мәүлитов исемендәге урам гына бар.

Саба районының Югары Утар авылында туып-үскән һәм ике дистә ел гомерен хәрби разведкага багышлаган Минзакир Әпсәләм улы 1919-1921 елларда РККАның Хәрби академиясендә укый. Төркиядә хәрби разведка буенча, эшчәнлек алып бара, 1927 елның ноябреннән 1931 елның ноябренә чаклы Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабында разведка бүлеге башлыгы. 1933-1937 елларда Персиядә (1935 елдан – Иран) хәрби атташе һәм хәрби разведка резиденты. 1938-1940 елларда полковник М.Әпсәләмов үзе тәмамлаган М.Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә өлкән укытучы, махсус факультетның 2 нче курс һәм разведка кафедрасы башлыклары вазифаларын башкара. Шул чорда “махсус бурыч үтәү өчен” чит илләрдә командировкаларда булуы мәгълүм. 1939 елда комбриг чинына үрләтелгән милләттәшебез совет-фин сугышында катнаша: 1940 елның гыйнвар – март айларында Төньяк-Көнбатыш фронт штабында – Разведка бүлеге башлыгы (бу өлкәдә шундый югары үргә ирешкән хәрби җитәкче татарларда башка юк). Шул орышта Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән комбриг Минзакир Әпсәләмов июнь аеннан – генерал-майор чинында. Сентябрь аеннан – Кызыл Армия Генштабының Югары махсус мәктәбендә разведка кафедрасы башлыгы һәм бер үк вакытта совет-фин сугышы нәтиҗәләрен өйрәнү комиссиясендә. Бөек Ватан сугышы башлангач, Төньяк-Көнбатыш һәм Көньяк фронтларын берләштергән һәм Башкомандующие С.Буденный булган Көньяк-Көнбатыш стратегик юнәлеше гаскәрләре штабында әлегәчә ачыкланмаган махсус бурыч үтәве хәрби энциклопедияләр битләрендә даими яктыртылып килә.

Әлеге серле бурычтан соң, Минзакир Әпсәләмовны хәрби разведкадан читләштерәләр һәм Кызыл Армиягә күчерәләр. Ягъни ул сугыш башланган чордагы серле бурыч үтәвеннән соң, ни сәбәпледер, җәбергә дучар була. Генерал Урал һәм Көньяк Урал хәрби округларында укчы бригадалар белән командалык итә. 1943 елның февраленнән – фронтта: 18 нче укчы дивизия, 31 һәм 131 нче укчы корпуслар белән командалык итеп үзен хәрби данга күмә. Ленин, дүрт Кызыл Байрак, I дәрәҗә Богдан Хмельницкий, II дәрәҗә Суворов орденнары белән бүләкләнә, әмма, ни өчендер, генерал-лейтенант званиесе бирелми.

● Хөсәен Мәүлитов.

Ә менә Чистай каласында туган хәрби разведка полковнигы Хөсәен Баһаутдин улы Мәүлитовның гомере гаять дәрәҗәдә аяныч рәвештә өзелә. Гражданнар сугышында 1 нче аерым Идел буе Татар укчы бригадада полк командиры вазифасын башкарганда ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән, Кызыл Армиянең хәрби разведкасына төп нигезне салган, системасын оештырган РККАның Хәрби разведка идарәсе башлыгы Ян Берзинның уң кулы саналган һәм комбриг званиесенә тәкъдим ителгән милләттәшебез – каһәрле һәм канлы репрессияләр корбаны. 1935 елның маеннан Кавказ арты хәрби округы штабының разведка бүлеге башлыгы вазифасына үрләтелгән полковник Мәүлитовны (шундый дәрәҗәгә ирешкән бердәнбер татар вәкиле) 1937 елның 31 июлендә кулга алалар һәм 30 октябрьдә атып үтерәләр. Хәрби разведкада тагын да югарырак үрләр яулаячагы шик уятмаган милләт баласы турында Казан педагогы Роман Гузенфельдның “Казанские ведомости“ газетасында язган мәкаләсе кызыклы: “Хөсәен Мәүлитов. Һәрвакыт җыйнак, таза гәүдәле, ихтыяр көче ташып торган бу кеше безнең хәрби разведканың горурлыгы булыр иде. Әмма ул һәлакәтле 1937 елдагы һәм аннан соң дәвам иткән Сталин терроры корбанына әйләнә... Хәрби разведкадагы сәләтле һәм үрнәк офицерларның берсе, озакламый хәрби званиесе күтәрелүен көткән полковник Хөсәен Мәүлитов Разведка идарәсе җитәкчесе Берзинның уң кулы була”.

Татарстанның Кама Тамагы районы Кече Кариле авылы егете, совет дипломаты, хәрби разведка полковнигы, шулай ук, комбриг званиесенә тәкъдим ителгән Һади Кәрим улы Маликов та шул котсыз еллар өермәсенә эләгә. Мәскәүдә 2012 елда нәшер ителгән “Хәрби разведка энциклопедиясе” хезмәте авторлары аның “Румын фронтында Беренче бөтендөнья сугышында катнашуы”н раслый (500 бит). Тарих фәннәре докторы Яков Гришин белән тарихчы-архивчы Сәйфетдин Мәндинең “Гасырлар авазы” журналында 2010 елда дөнья күргән мәкаләсендә дә кызыклы мәгълүматлар җитәрлек: “Һади Маликовны 1915 елның декабрендә Казандагы 94 нче запас пехота полкының 7 нче ротасына ирекле хәрби буларак кабул итәләр. Аннары, 24 нче запас пехота полкында рядовой булып хезмәт итә һәм 1917 елның декабрендә 2 нче Казан прапорщиклар мәктәбен тәмамлый”.

Прапорщик чины алып чыкканнан соң яшь офицерның Симферополь каласындагы – 24 нче һәм Бессарабиядагы өяз шәһәре Оргеевта урнашкан 5 нче запас полкларында хезмәтен дәвам итүе мәгълүм. Хәрби разведка турында гаять мөһим хезмәт язган авторлар патша армиясендә прапорщик чинында хезмәт итүче булдыклы милләт баласының, командиры полковник Евгений Галактионович Якунин булган 56 нче Житомир полкында рота командиры вазифасын башкаруын да искәртеп үтә. Шул чорда ук, илдә яңа хакимият урнаштыру максаты куйган большевиклар ягына баскан Һади Маликовның Гражданнар сугышында акларга каршы көрәшүе табигый. Кискен сыналыш елларында ул Татар-башкорт җыелма батальонында хәрби комиссар, Хәрби һәм диңгез эшләре Халык комиссариаты каршындагы Үзәк мөселман комиссариатында хәрби бүлек секретаре, Казан ныгытылган район башлыгының разведка буенча ярдәмчесе һәм 2 нче аерым Татар укчылар бригадасында штаб башлыгы вазифаларын башкара.

Ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән командир 1918-1924 елларда РККАның Хәрби академиясендә укый. Укуының озаккарак сузылуы вакыт-вакыт чит илләрдә махсус бурычлар үтәве белән бәйле. Ягъни бу чорда ул укуын беразга өзеп, дипломатик һәм разведка эшләрендә чарлана. Мәгълүм булганча, 1921 елда Россия белән Төркия арасында дуслык һәм туганлык турындагы килешүгә кул куела. Шуның нәтиҗәсе буларак оештырылган совет вәкаләтле вәкиллеге составында хәрби атташе ярдәмчесе сыйфатында Һ.Маликов та кертелә. РККА хәрби разведкасының беренче җитәкчесе һәм Россиянең Төркиядәге вәкаләтле вәкиле С.И.Аралов совет дипломатларының, шулар исәбеннән Һ.Маликов белән аның хатыны Рабига ханымның эшчәнлекләренә югары бәя бирә. Аерата ирле-хатынлы Маликовлар төрек телен һәм илен яхшы белүләре белән башкалардан

дәһшәте

Һади Маликов.

бик нык аерылып тора. Тарих фәннәре кандидаты Марат Мөлеков раслаганча, "Рабига ханым төрек хатыннарының күңелләренә юл таба белә. Төрек хатыннары аңа ихтирам һәм зур ышаныч белән карый. Маликовларның шәхси архивында сирәк очрый торган бер фоторәсем – Мостафа Кемал-пашаның дипломатлар белән җәйге дачада төшкән рәсеме саклана. Аның белән янәшәдә Һ.Маликовның хатыны Рабига ханым утыра".

Академияне уңышлы тәмамлаганнан соң Һ.Маликов 1924-1927 елларда Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабында разведка бүлеге башлыгы вазифасында хезмәт итә, аннары өч ел ярымнан артыграк Персиядә хәрби атташе булып тора. Хәрби чыганакларда разведка эшенә кулы ятып торган Һади Кәрим улы оештырган агентура челтәре белән Персиядә бер тапкыр да уңышсызлыклар һәм кételмәгән хәлләр булмавы турында ассызыклануын искәртү дә мөһим. Туган илгә әйләнеп кайткач, ул чактагы тәртип буенча, академиядә алган теоретик белемнәрен практика белән ныгыту максатыннан Кызыл Армиягә юллама алган милләттәшебезнең теләген исәпкә алып, аны туган ягына, Казанга кайтаралар. Бирегә ул 1 нче татар укчы полкы (соңыннан 190 нчы укчы полк итеп үзгәртелә) белән командалык итә, бер үк вакытта комиссар вазифаларын башкара. Марат Мөлеков ассызыклаганча, "Яңа командир-комиссар үз дигәнендә нык торып, тынгы белми эшли. Кызылармеецларның хәрби хәзерлек дәрәҗәсе күтәрелә. Полкка Идел буе хәрби округының ул чактагы башлыгы Б.М.Шапошниковның рәхмәте белдерелә. Бөтенроссия старостасы М.Калинин һәм композитор Салих Сәйдәшев бу полкның почетлы кызылармеецлары була. Үзенең маршын, хәзерге көндә Совет Армиясе маршы дип йөртелә торган атаклы маршны, Сәйдәшев махсус рәвештә 1 нче татар укчы полкына атап яза".

Күренекле хәрби разведчик 1934 елдан Кытайның Шинҗаң (Синьцзянь) провинциясе губернаторы һәм андагы гаскәрләрнең башкомандующие вазифаларындагы генерал Шен Шицайның баш хәрби киңәшчесе сыйфатында аеруча җаваплы бурыч үти. 1936 елның 17 гыйнварыннан хезмәтен полковник званиесендә дәвам иттерәчәк милләттәшебезнең әлеге үтә мөһим һәм серле хөкүмәт чарасын башкарып чыгу турында җитди чыганакларда бик тәфсилләп бәян ителә. "Империя ГРУ" китабының 2 нче томында (авторлары – А.Колпакиди белән Д.Прохоров) Шинҗаңга комбриг Маликов җитәкчелегендә Разведупрдан (ГРУ) киңәшчеләр төркеме җибәрелүе тәфсилләп бәян ителә. "Икенче бөтендөнья сугышы: кайчан башланды һәм кайчан тәмамланды" дигән хезмәт авторлары (А.Паршев һәм В.Степанков) 1934 елның апрель азакларында Шинҗаңнан совет гаскәрләрен чыгарулары һәм җирле губернаторның үз киңәшчесе, танылган разведчик Һ.Маликов җитәкчелегендәге киңәшчеләр төркеме генә калдырулары турында яза.

Тарих фәннәре докторы Я.Гришин белән тарихчы-архивчы С.Мәнди "гасырлар авазы" журналы өчен бергәләп язган хезмәттән тагын бер өземтә:

"1934 елның апрелендә РККАның Разведка идарәсе башлыгы Я.Берзин Һ.Маликовка Кытайда, Шинҗаңда җаваплы бурыч үтәү бурычы куя. Әңгәмә барышында Берзин Маликовка нинди шартларда эшләргә туры киләчәген җентекләп бәян итә… Совет киңәшчеләре төркеменә Һ. Маликов җитәкчелек итә. Ул Көнбатыш Кытайдагы (Шинҗаң провинциясе) гаскәрләрнең башкомандующие Шен Шицайның беренче баш киңәшчесе сыйфатында юлга чыга. Аның белән И.Ф.Куц, П.С.Рыбалко, В.Т.Обухов, М.М.Шәйморатов кебек командир-инструкторлар була.

Төркем Кытайга 1934 елның 9 апрелендә китә. Дубан белән очрашкан вакытта сүз совет белгечләренең эшчәнлеге турында бара. Маликов искә ала: "Инструкторларны билгеләүнең элекке тәртибе Берзин күрсәтмәләренә тулысынча диярлек туры килә иде. Мин Шинҗаңда булган беренче елымда инструкторларны тиешле урыннарга куеп чыгуда фәкать кайбер әһәмиятле булмаган үзгәрешләр генә керттем. Мисал өчен, әйтик, минем белән килгән инструкторларның икесе (Рыбалко һәм Куц) фронтта эшләде, өченчесе (Обухов) фронтның тылында хезмәт күрсәтте, дүртенчесе (Шәйморатов) – яңа техника белән тәэмин ителгән таркау подразделениеләрдән оешкан уку полкында". Авторлар Маликов бәян иткәннәрне Россия Федераль иминлек хезмәтенең Үзәк архивыннан (ЦА ФСБ РФ, д. 27516, т. III.) алуын ассызыклый.

1937 елның июнендә, "контрреволюцион троцкийчылар" оешмасында катнашу гаебе тагылып, төгәлрәге, 1923 елда Троцкийны яклап тавыш бирүен сәбәп итеп, Һади Маликов НКВД тарафыннан кулга алына. Төгәл 9 елдан азат итәләр, әмма 1949 елның гыйнварында кабат төрмәгә ябалар. Фәкать Сталин үлгәч кенә, 1954 елның 5 июнендә полковник Маликовны азат итү турында документ дөнья күрә. Ирекә чыкканнан соң Һади Кәрим улы хатыны Рабига һәм кызы Зөлфия белән Мәскәүдә яши. Якын дустына әйләнгән генерал Якуб Чанышев белән еш кына Казанга кайтулары, төрле очрашуларда катнашулары татар матбугаты битләрендә теркәлеп калган. Аерата шунысын ассызыклау мөһим: хәрби разведка полковнигы Һ.Маликов Кызыл мәйдандагы мавзолейдан Сталинның гәүдәсен чыгаргачы ул якка әйләнеп тә карамый. Бу турыда күп китаплар авторы, танылган журналист Хәмзә Бәдретдинов үзенең 2006 елда дөнья күргән "Гүзәл Кама Тамагы – табигать хәзинәсе" китабында раслый.

Ул чордагы репрессияләрнең нинди гаделсезлекләргә китерүен раслаучы янә бер өстәмә китереп үтик. 1934 елда өлкән киңәшче Һ.Маликов җитәкчелегендә Кытайга барган разведчикларның барысы да хәрби өлкәдә зур уңышларга ирешә. 1935 елдан полковник ромблары йөрткән Павел Рыбалкога 1940 елның 20 февралендә – комбриг, 4 июнендә – генерал-майор һәм 1943 елның 18 гыйнварында - генерал-лейтенант, 30 декабрендә генерал-полковник званиеләре бирелә. Бөек Ватан сугышында ул 5 нче танк, 3 нче танк һәм 57 нче армия командующийлары вазифаларын били. 1943 елның маеннан сугыш тәмамланганчы – яңадан оешкан 3 нче гвардия танк армиясе командующие. Яуда үзен булдыклы һәм тәвәккәл хәрби җитәкче итеп таныткан Павел Семенович 2 тапкыр Алтын Йолдыз белән бүләкләнә, сугыштан соң – бронетанк гаскәрләре маршалы.

1935 елның 16 декабрендә полковник чины алган Виктор Тимофеевич Обухов тагын дүрт елдан комбриг була, 1940 елның 4 июненнән – генерал-майор. Сугыш башланганда 26 нчы танк дивизиясе белән командалык иткән тәҗрибәле хәрби җитәкче 1943 елның мартыннан – 4 нче танк армиясе командующие урынбасары, май аеннан – 3 нче гвардия механикалаштырылган корпус командиры. Шул елның 5 ноябрендә генерал-лейтенант чинына үрләтелгән В.Обухов 1944 елның июлендә Алтын Йолдыз белән бүләкләнә. 1955 елдан – танк гаскәрләре генерал-полковнигы. Полковник Иван Федорович Куц 1941 елның июленнән – 56 нчы, августыннан 62 нче кавалерия дивизияләре белән командалык итә. Тагын ике елдан генерал-майор званиесенә үрләтелгән И.Куц 2 нче гвардия кавалерия корпусы командиры урынбасары вазифасына билгеләнә. 1944 елдан алып сугыш тәмамланганчы – шул корпус командиры.

(Дәвамы киләсе санда).

Рәис ЗАРИПОВ.

Айга карама кырыН

Халык медицинасы чаралары белән дәваланууга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

24 сентябрь (шимбә). ***Сәфәр аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,3.02 сәгатьтә калка, 17.41 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.05 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, караңгы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Иммунитетны ныгыту

1 лимон һәм 1 баш сарымсакны кыргычта кырып яки иттарткычтан чыгарып, кайнатып суытылган 600 мл суга салалар, бүлмә температурасында 2-4 көн тәнәтеп, сөзәләр. Көз, кыш һәм яз көн саен ач карынга 50 шәр мл эчәләр.

25 сентябрь (якшәмбе). ***Сәфәр аеның 29 нчы көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 4.23 сәгатьтә калка, 17.49 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 12.02 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Солы сихәте

Солы төнәтмәсе кул калтырауны баса һәм хәтта тулысынча дәвалый ала. 9 аш кашыгы солыны 3 литр суга салып, сүрән утта 1 сәгать пешерәләр. Төнгелеккә җылы итеп урап калдыралар, иртән сөзәләр. Көн буена эчеп бетерәләр. Тулысынча сихәтләнү өчен, озак дәваланырга кирәк булачак. Әлеге төнәтмә Паркинсон авыруы булганда да булыша.

26 сентябрь (дүшәмбе). ***Сәфәр аеның 30 нчы көне.1,2 нче Ай тәүлекләре. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 5.45 сәгатьтә калка, 17.56 сәгатьтә бата. 00 сәгать 54 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 11.57 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

27 сентябрь (сишәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 7.08 сәгатьтә калка, 18.04 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.53 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Ютәлдән – скипидар

Чистартылган скипидарның берничә тамчысын кечкенә генә кәстрүлдә кайнап торган суга тамызалар. Зур җылы шәл

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

белән капланып, авыз белән шушы парны сулыйлар. Аннан соң түренеп йокларга ятарга кирәк. Әгәр бер тапкырдан соң ук ютәл бетмәсә, берничә кич шулай дәваланалар.

28 сентябрь (чәршәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 2 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,8.34 сәгатьтә калка, 18.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.48 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Керән яфрагы

Остеохондроз интектергәндә, муенга керән яфрагын аскы ягы белән куеп, өстеннән йон шарф яки яулык урыйлар, бигрәк тә төнлә шундый компресс белән йоклау файдалы. Остеохондроз көчәйгәндә авыртуны басар өчен, үги ана яфрагы үләне чәчәкләрен сабагы белән җыеп, нашатырь спиртына салалар, караңгы урында 1 ай төнәтәләр, сөзеп, авырткан урынга сөртәләр (әмма ышкырга ярамый!) Сызлау басыла.

29 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 3 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,10.04 сәгатьтә калка, 18.25 сәгатьтә бата. 1нче фаза. Көн озынлыгы 11.43 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына җиткезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп туплануын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

Диатездан – кишер согы

Кишерне юып, кыргычта кыралар, марля аша согын сыгалар (яки сок сыга торган җайланма аша чыгаралар) да, тәндәге диатез тапларына сөртәләр. 2 сәгатьтән соң ук нәтиҗә күренә башлый. Көненә 3-4 тапкыр сөрткәндә, 2 көннән соң диатез бетә. Кишер согы тиредәге аллергиягә бәйле теләсә нинди тапларны дәвалый ала.

30 сентябрь (җомга). ***Рабигул әүвәл аеның 4 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 11.37 сәгатьтә калка, 18.44 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.39 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур. Теш алдырырга ярамый.

Яшел помидор салаты

5 кг яшел помидор, 1әр кг суган, татлы борыч һәм кишер, 250 г үсемлек мае, 250 мл 9% серкә, 100 г шикәр кирәк. Барлык яшелчәләрне турап, зур савытка салып болгаталар. Май, серкә һәм шикәрне кайнатып чыгарып, яшелчәләр өстенә салалар, сүрән утта 30 минут пешерәләр. Стериль банкаларга бүлеп, тимер капкач белән ябалар.

Йөрәгебез – иман урыны

Хәзерге вакытта без күбрәк үзебезнең тышкы кыяфәтебезгә игътибар бирәбез. Тәнне чыныктырабыз, ашатабыз, эчертәбез, матур киемнәр киртәбез, өй төзибез, машина алабыз һәм башкалар.

Пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә сезнең төс-кыяфәтләрегезгә һәм мал-мөлкәтләрегезгә карамый, ләкин Ул сезнең калеб-күңелләрегезгә һәм кылган эшләрегезгә карый», – дигән.

Аллаһы Тәгалә әйткән: «(Хәерле юлда сарыф ителсә дә), Бер малның да, (шәфәгать итә алырлык дәрәҗәдә булган) уларның да (беркемгә) файда бирмәгән көнне. Мәгәр (көферлек һәм монафикълык кебек хасталыклардан тәмам котылып), керсез күңел белән Аллаһка килүче булмаса гына». («Шагыйрьләр», 88-89нчы аятьләр).

Безнең йөрәгебез – ул иман урыны. Шуның өчен иман телдә, колакта, язуда гына түгел, ә йөрәктә булырга тиеш. Кеше мәет булгач, аның кабеؘренә Мөнкәр белән Нәкир исемле фәрештәләр килеп, сорау алачак. Ул кеше тел һәм акыл белән сөйли алмас, ә йөрәк белән җавап кайтарыр.

Мөхәммәд галәйһис-сәләм әйткән: «Дөреслектә, тәндә бер ит кисәге бар, ул сәламәт булса бөтен тән сәламәт була, ул авырса, бөтен тән чирләр. Дөреслектә, ул әгъза – йөрәк».

Без тәнне чиста тотабыз, фатирыбызны тузансыурткыч белән ялт итәбез, киемнәребезне кер юу машинасында пакьлибез, машинаны да махсус җиргә алып барып юабыз. Безнең йөрәгебез дә пакьләүгә мохтаҗ. Йөрәккә дүрт юл тоташа: күзләр, колаклар, тел һәм уй. Шушы дүрт әгъзаны хәрәм нәрсәләрдән сакларга кирәк. Берсеннән булса да йөрәккә хәрәм керсә, йөрәк карала башлый. Күз алдына бассейнны китерик. Аңа дүрт краннан су килә. Берсеннән булса да пычрак су керсә, бөтен бассейндагы су шакшыга әйләнәчәк. Ә йөрәгебезгә барган юлларны ничек чиста тотарга була? Аллаһ бар иткән дөньяга карап фикерләргә, Коръән китабын укырга, колаклар белән вәгазь тыңларга, тел белән Раббыбызны даими истә тотарга кирәк.

Шулай ук, кайчан кеше гөнаһларны кылып, аның йөрәге каралык белән капланса, алар тышка чыгып, тәндә авыру барлыкка китерә. Рәсүл Әкрәм галәйһис-сәләм әйткән: «Кеше гөнаһ кылгач, аның йөрәгендә кара нокта барлыкка килә. Әгәр ул тәүбә итмәсә, ул кара нокта шунда кала. Ә инде тагын гөнаһ кылуны дәвам итсә, аның бөтен йөрәге каралык белән капланыр».

Кешеләрнең тормышына карасаң, бөтенесе дә бар шикелле, ләкин аларның йөрәкләрендә тынычсызлык һәм булганына ризасызлык күренә.

Кодси хәдистә Аллаһы Тәгалә әйткән: «Я, Адәм баласы, Миңа гыйбадәт кылу өчен вакытны тап! Мин синең йөрәгеңнән тынычсызлыкны алырмын һәм фәкыйрьлектән имин кылырмын. Әгәр шулай эшләмәсәң, синең йөрәгеңне борчулар белән тутырырмын һәм син фәкыйрьлектә калачаксың!»

Бу хәдистән чыгып, шуны аңларга була. Йөрәкләребез фәкать Аллаһка гыйбадәт кылу, Аны һәрвакыт истә тоту белән генә тынычланыр. Мисал итеп, кайнаган сулы савытка, бераз салкын су өстәсәк, ул кайнаудан туктар. Шулай ук, бу дөнья артыннан куган вакытта, аны бер мизгел эчендә читкә куеп, намаз үтәүгә, Коръән укуга, зикер кылуга йөрәгебезне юнәлтсәк, безгә шундый рәхәтлек, җиңеллек киләчәк.

Раббыбыз әйтте: «Күңелләр Аллаһны зикер итү белән тынычланмыймы?» («әр-Рәгыд» сүрәсе, 28нче аять).

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тимер суда ничек күгәрсә, йөрәкләрегез дә шулай тутыга!» – дигән. Берсе: «Я, Рәсүлуллаһ, Йөрәкне ничек пакьләргә була?» – дип сорый. Пәйгамбәр галәйһис-сәләм: «Үлемне еш искә алу һәм Коръәнне уку белән!» – дип җавап бирә.

Аллаһы Тәгалә әйткән: «Юк! (Бу бозык бәндәнең сүзе һич дөрес түгел!) Кылган (начар) нәрсәләре (һәм рәттән эшләгән гөнаһлары) аларның йөрәкләрен (мәгънәви бер) тутык белән каплаган» («әл-Мутаффифин» сүрәсе, 14 нче аять).

Безнең бу дөньяда яшәвебезнең максаты – ул йөрәгебезне пакьлектә, чисталыкта тоту. Без якты дөньяга чиста йөрәк белән килдек, шулай ук ахирәткә күчкәндә, Аллаһы Тәгалә каршына басканда да, пакь йөрәк белән барырга тиешбез.

Ни өчен сәхабәләргә безгә караганда дин тоту җиңел булган? Чөнки аларның йөрәгендә дин, ә кулында дөнья булган. Ә безнең киресенчә - йөрәгебездә – дөнья, ә кулыбызда дин тора. Шуның өчен дин тоту безгә авыр булып тоела. Кич белән берәү юлда барганда, бер ташка сөртенеп егыла. Сүгенеп, аны кулына алып, читкә ыргыта. Ә инде көндез ул ташны бриллиант рәвешендә юлда очраткан булса, аны кулына алып, кесәсенә салып, өенә алып кайткан булыр иде. Кара йөрәккә дин яктысы кермәс. Йөрәк пакь булганда гына, диннең кыйммәте ачык була.

Рәсүл Әкрәм галәйһис-сәләм: «Кыямәт көне алдыннан, дин тоту янган күмер кисәге кебек булыр. Тотсаң пешерер, җибәрсәң сүнәр», – дип әйткән. Минем хатын, минем балалар, минем өем, минем машинам, минем эшем, дип сөйләргә яратабыз. Ә кешегә тагын «Минем динем!» дип гадәткә кертеп, яратып әйтергә өйрәнергә кирәк. Без хатын, балалар, эш өчен ничек җаваплы булсак, дин өчен дә барыбыз җаваплы.

Бал хакында, аның файдасы, тәме турында никадәр сөйләсәк тә, ашамыйча торып, боларны белеп булмый. Шулай ук суга кермичә торып, йөзәргә өйрәнә алмыйбыз. Моннан чыгып, шуны аңлыйбыз, динне аңлар өчен, аның белән яшәргә кирәк.

Йөрәк – ул тәндәге патша кебек. Патша кешеләргә әмер кылып эшләткән шикелле, йөрәк тә тән әгъзалары белән идарә итә. Йөрәк кара булса, аның теленнән начар сүзләр чыга, күзләре яман әйберләргә карый, уй белән оятсызлык хакында хыяллана, колаклар әшәкелекне тыңлый. Ә йөрәкне каралыктан ничек пакьләргә? Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһис-сәләм шундый дога кылган: «Аллаһүммә мусаррифәл кулүб сарриф кулүбәнә галә тагәтик (Йөрәкләребезне юнәлдерүче, йә Аллаһ, Синең буйсынуыңа безнең йөрәкләребезне юнәлт). Йә мукаллибәл кулүб сәббит калбии галә диник (Йә йөрәгебезнең халәтен үзгәртүче, Синең динеңә йөрәгемне нык кыл)».

Аллаһы Тәгалә безгә шуны аңларга, йөрәгебезне пакьләр өчен тырышлык куярга, тормышыбызга динне кертергә һәм балаларыбызга да аны җиткерергә насыйп әйләсен. Әмин.

Ибраһим хәзрәт **ШАҺИМӘРДӘНОВ.**
dumrt.ru

Намаз начар гадәтләрне төзәтә

«Мөэминнәр» сүрәсенең беренче аятендә үк Аллаһы Тәгалә: «Намазларын бирелеп, курку белән укыган мөэминнәр генә, кыямәт көнендә газаптан котылып, җәннәткә керерләр», – ди. Намаз укыган кешенең башында төрле уйлар булмаска, аның фикерләре чуалмаска тиеш. Намазны вакытында укырга тырышырга кирәк. Калган намазларны каза кылу ахыр чиктә генә башкарыла торган гамәл. Ул кабул булмаска да мөмкин. Моннан тыш, кайберәүләр: «Намаз укыр идем, догаларын белмим», – ди. Мондый кешеләрне берничек тә аклап булмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз укырга теләсәгез, догаларын белмисез икән, «сөбханалла», «әлхәмделилла», «Аллаһу әкбәр!» дип, тәсбих сүзләре белән намаз укып чыгыгыз», – ди. Икенче берәүләр: «Мин намазга баскач, гөнаһ эшләсәм, намазым дөрес булырмы?» – дип килә. Гөнаһсыз кеше юк. Ләкин Аллаһы Тәгалә: «Хакыйкатьтә намаз фәхеш һәм бозык гамәлләрдән тыя, кешене чистарта», – ди. Кешене тыеп кына туры юлга кертеп булмый, аның эчендә изгелек салырга кирәк. Намаз укыган саен, кешенең күңеленә оят керә, ул гөнаһ кылырга ояла, курка башлый. Нәтиҗәдә, гөнаһ гамәлдән арына. Дөрес итеп укылган намаз кешенең гаепле, зәгыйфь якларын, начар гадәтләрен төзәтми калмый.

Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә һәр кешегә биш сорау бирәчәк. Иң беренче: «Намазың бармы, юкмы?» – диячәк. Намаз укыган кешеләргә тагын дүрт сорау биреләчәк: «Яшьлегеңне нәрсәдә үткәрдең?», «Гомереңне нәрсәгә багышладың?», «Кайдан мал алдың һәм кая куйдың?», «Үзләштергән һөнәреңне нинди юлда кулландың?» Мөселман кешесе буларак без тормышта беренче чиратта намазны торгызырга бурычлы. Намаз – хакыйкатьтә Аллаһы Тәгаләне тану дигән сүз. Аллаһы Тәгалә кушкач, бөтен фәрештәләр сәҗдә кылганда, иблис баш тарткан. Шуңа күрә иблискә якын кешеләр сәҗдә кыла алмый, ул алар белән идарә итә. Адәм баласы, фәрештәләр кебек үк, Аллаһы Тәгалә каршында сәҗдә кылырга тиеш. Шул чагында гына ул Аллаһы Тәгаләнең колы булып санала. Аллаһы Тәгалә: «Булдыра алганча Аллаһтан куркыгыз», – ди. Аягызда басып тора алмыйсыз икән, намазны утырып укыгыз. Утырып укырга мөмкинлек булмаса, ятып укыгыз. Ятып та укый алмасагыз, керфек, бармак белән укыгыз.

Каләмдәшнең яңа китабы

Соңгы еллар прозабыз турында сүз кузгалса, Рафис Корбан иҗатын искә алмый мөмкин түгел. Ул бигрәк тә күренекле шәхесләребез булган М.Җәлил һәм аның көрәштәшләре, чын халыкчан профессиональ музыкага нигез салган С.Сәйдәшев һәм аның даирәсенең тормышын яңача ача һәм бәяли торган әсәрләре белән үткәннәребезне дөресрәк аңларга ярдәм итте. Нәсел-нәсәбе белән үзенең туган авылына килеп тоташучы разведчик Исхак Әхмәровның исемен халкыбызга кайтаруга тырышлык куйды. Без Бөек Ватан сугышында олы батырлыклар күрсәткән ир-егетләребез белән хаклы рәвештә горурланабыз. Шулай да тулаем ил өчен әһәмияте гаять зур булган, дөньяны колачлаган сугыш хәрәкәтләренең кискен борылыш алуына китергән әлеге татар егетенең кылган гамәлләре аерым бер каһарманлык. Ул әле үзенә бәрабәр бәяне алмый калмас.

Моннан бер ел элек Р. Корбанны шәхесләребезне халкыбызга яңача ачып килгән каләменнән «Каргыш» дип исемләнгән повесте төште. Әдәби журналыбыз аны шунда ук укучыларга җиткерде. Алай гына да түгел, быел ул «Казан утлары» китапханәсе сериясендә кесә китабы форматында да «Тәүбә көне» исеме белән дөнья күрде. «Татмедиа» кайнар эздән аны тәкъдим итү чарасын үткәрде. Иң мөһиме – китапка карата кызыксыну артты.

Әдәбиятны күзәтеп баручылар хәтерлидер, җитмешенче елларда Азат Әхмәдуллин «Ничек сурәтләргә сине, замандаш» дигән китап бастырды. Заман кешесен (героен түгел) гәүдәләндерү мөһим мәсьәлә булып чыкты. Тормышыбыз үзе мантыйкка сыймаган хәл-әхвәлләр белән тулы булган кебек, чынбарлыктан этәргеч алып тудырылучы әдәби дөнья да еш кына без таянырга гадәтләнгән кыйммәтләрне санга сугып бетерми. Р. Корбанның бу әсәрендә дә мондый хәлләр бик тә гыйбрәтле итеп чагылдырылган.

Үзәккә Ислам Ибләминов дигән яше алтмышка якынлашкан ир-ат образы куелган. Чынында бу исем аңа әрәм дә кебек. Ата-анасы исемне балага зур өметләр баглап кушканнардыр. Үз гомерендә, төрле рәвешләргә керә-керә, ул чынлыкта ислам таләпләренә туры килми торган гамәлләр белән көн итүче бәндәгә әверелгән. Туксанынчы елларга ул инде чын-чыннан коммунизм төзүче булып килеп җиткән. Дөрес, күмәк хуҗалык җитәкчесе булып эшләгән этисе аны авыл хуҗалыгы белгече итеп күрәсе килгән. Фирканең башлангыч буынында гына эш итсә дә, әнисенең йогынтысы көчләрәк булган, күрәсең, малай укырга университетның фәнни коммунизм (!) белгечлеге бирә торган бүлегенә кергән. Укыганда ук комсомол эше алып баручы булып танылган Исламны, укуын тәмам иткәч, бер райкомолга секретарь итеп тәгаенләгәннәр. Әнисеннән аңа юкны бар итеп сөйли белү осталыгы да күчкән. Шуңа күрә малай эшендә үскәннән-үсә бара. Әгәр дә хакимияткә тамгалы Горбачев килеп илне бутамаса, белгечлеге буенча төзүче Ельцин «җитлеккән» социализмны җимерәм дип әллә ниләр кыланмаса, Ислам дигән бу тәти егет коммунизм юлыннан барасы да барасы икән. Әмма, эшләр болайга киткәч, каучук заводы директоры булган кайнатасының сүзен тыңлап, ул кече предприятие ачып җибәрә. Кулында төшемле эше булган кешеләр ярым бушка прихватизация белән байлык туплаган елларда Исламның да бүресе улый, зур гына милек иясенә әйләнә. Укучы әсәрнең беренче битләрендә очрашканда ук күрә: ул инде тәненә хәрәм симезлек җыйган, йөрәген йон баскан, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен аера алмау хәленә килгән азгын иргә әверелгән.

Ул бер көнне гаиләсе белән табигать кочагына чыгарга ниятләгән, бу хакта хатынына вәгъдә дә биргән. Әмма сөяркәләренең берсе – Регина дигәне шалтыратуы була, ул инде, бөтенесенә кул селтәп, диңгездәй Куйбышев су саклагычының комлы ярына китеп тә бара. Гаилә алдындагы җаваплылык хисе аның өчен бөтенләй юкка чыга. Чит илдә эшләнгән миллионнарча сумлык машинасында андый очраклар өчен әче-төчедән, кабымлык ишеләрдән барысы да бар. Машина йөрткән кеше исерткечне дә авызына китерергә тиеш түгел иде. Әмма бу таләп аңа карамый. Исереклектән тагын да каны кайнап, комда аунап алгач, кызулык белән суга кереп китә, алдына-артына карамыйча, колач салуын белә. Нәтиҗәдә, бер ярдан икенчесенә кадәр кырык чакрым булган су чолганышында калып, чын мәгънәсендә адаша. Машинасы калган ярның кайсы якта икәнен чамаламас хәлгә килә. Ниһаять, аяклары җиргә тия. Әмма иртә шатлана, бу нибары су уртасындагы кечкенә генә, кешесез утрау икән. Ислам үзенең никадәр аяныч хәлгә тап булганын аңлый. Бу вакытта ул бер кабым икмәк өчен дә берни кызганмас иде. Калтыранып утыра торгач, мәрткә киткәндәй, йокыга да тала.

Бу урында дин әһелләребезнең вәгазьләре урынлы. Алар әйтә: кеше Раббыбыз каршына дөньялыктагы бөтен нәрсәсен калдырып китә. Зиннәтле йортларын да, сандык-сандык акчаларын да, кием-салымнарын да, алтын-көмешләрен дә ала алмый. Кабергә аның белән бары гамәлләре генә бара.

Ислам да бу очракта нәкъ шундый хәлдә. Янында машинасы да, шәһәрдәге коттеджлары да, бернәрсәсе дә юк. Аңа үз-үзенә, яшәү рәвешенә, кылган гамәлләренә, кешеләр белән булган мөнәсәбәтләренә бәя бирү сәгате суга. Монда үз-үзен алдау мөмкинлеге юк, күңел дөньясына ясалма бизәкләр өстәп, үткәннәрен дә матур итеп күрсәтә алмый. Ничек бар – шулай гына. Барчасын күңеленнән үткәреп җентекләгәч, аның бер дә юанырлык гамәлләре юк икән ич! Күпме гаделсезлек, икейөзлелек, алдау-йолдау белән яшәгән икән! Пай җирләре өчен фураж өмет иткән авыл халкының өлешен үз кесәсенә салу; шәхси хуҗалыклардан сөт җыйдырып та акчасын кысып калу; исәпкә кертелмәгән җирләрне үзләштереп, кесәсен калынайту; авылга мәчет салдырам дип вәгъдә биреп тә, шәһәргә кайткач, әйткән сүзен оныту; нык авырып киткән кыз баланы хастаханәгә илтергә машинасын кызгану, тиз арада ярдәм күрсәтелмәгәч, бичараның харап булуы... Кылган хилафлыкларының исәбенә чыкмалы түгел! Бу гамәлләре өчен күпме кешенең каргышын, рәнҗүен җыйган...

Аллаһының игелекле сыйфатлары күп дип өйрәтә Изге китабыбыз. Шуларның берсе – аның рәхимлелеге. Бу бәндәнең күңеленнән үз-үзенә шулай тәфтишләү ясавын, моңарчы булган хәлләренә үкенүен күргәчтер (бу мәхлук шушы шартларда Раббыбызга кичерү сорап махсус ялвара да белми), Исламга әлеге хәленнән котылу мөмкинлеге тудырыла – утрауга очраклы рәвештә балыкчылар килеп чыгуы аның исән калуына юл ача.

Шунысы аяныч, Ислам яшәеше, әхлаксызлыгы белән ялгыз түгел. Ул үзедәй бозык бәндәләр чолганышында яши. Андыйларга күз кайдан һәм ничек майлы калҗа эләктерү өчен генә кирәк. Әнә, суда йөзеп югалуы була, аңа ияргән Регина бу урыннан тәпиен ялтырату ягын карый. Машинаның хуҗасыз калуын чамалаган Җора дигән башкисәр әшнәләре ярдәмендә көне-сәгате белән аны үзләре генә белгән таба алмаслык урынга илттереп тә куя. Мондый эшнең гөнаһ булуы әлеге ачкүзләрнең уена да керми. Аларның зиһене җинаять өчен табыш алу, җае туры килгәндә күбрәк каерып калу ягын кайгыртырга гына көйләнгән.

Утрауга килеп чыккан балыкчыларның өлкәне Кәримулла да акча өчен җан кыюга ук барып җитәргә мөмкин. Ярый әле Шамил исемле яшьрәк юлдашы кешелеклелеген җуеп өлгермәгән икән. Әгәр Кәримулла йогынтысында дәвамлырак йөрсә, ул да шундый булып әверелүен сизми дә калачак. Мондый җинаятьче өлкәннәрнең яшәү рәвешләре белән яшьләргә тискәре йогынты ясау мисалларын без әсәрдә тагын күрәбез. Әнә Исламның үз улы да моның гыйбрәтле мисалы. Ул этисенең бу төндә дә өйгә кунарга кайтмау хәбәренә артык гаҗәпләнми, икенче ягына борылып, йоклавын дәвам итә. Чөнки атаның хәрәмме-түгелме – теләсә нинди ысул ярдәмендә акча табу, чит хатыннар белән кайнашу гаме белән генә яшәвен яхшы белә. Бүген генә түгел, гомере буе шулай. Кая китсен, кайтыр, ашаган җиренә мал да кайта. Чыннан да, ашау өчен генә яшәгән Ислам кебекләрнең маллардан нинди аермасы бар? Повестьның соңгы битен ябып куйгач, шундый нәтиҗә ясау бик урынлы.

Р.Корбанның бу әсәре тар мәйданда мөһим мәсьәләләр күтәрелүе белән әһәмиятле. Замандашыбыз, аның кешеләренә рәссамнарча карап, үзен борчыган нәрсәләр турында укучыларны да уйландыра алган каләмдәшебезгә афәрин дияргә генә кала.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Телне күпме «үстерергә» була инде?

Дөньядагы иң алдынгы 14 тел арасында татар теленең 11 нче урында булуы турында язылган иде. 2017 елда, Йошкар-Ола каласында әйтелгән сүзләрдән соң, 309 нчы дип аталган мәрхәмәтсез закон чыгарылып, мәктәпләрдә милли уку компоненты тыелгач, балаларга үз ана телендә уку мөмкинчелеге бетерелде. БДИны рус телендә генә тапшыру рөхсәте сәбәпле, балалар ана телендә укудан баш тартырга мәҗбүр ителде. Татар авылларындагы мәктәпләрдә дә балалар ана телендә укудан мәхрүм ителеп, балалар бакчалары да рус теллегә әйләнеп бетү халәтендә калды. Шул вакытлардан башлап, Татар телен «үстерү»гә багышланган төрледән-төрле чаралар үткәрүләр башланды. Телне саклау һәм үстерүгә багышланган гамәлләрнең «Телне саклау һәм үстерү стратегиясе» дигәненең дә телне саклауда бер катнашы булмаганын күреп тордык.

Телне саклау һәм үстерү комиссиясенә өметләнеп карасак та, бу комиссиянең телне саклау вәкаләте булмаганы аңлашылды. Алай гына да түгел, татар теле республикада яшәүче башка милләтләрнең телләре белән бер дәрәҗәдә калдырылуы турында сүзләр булды.

Әле тагын, Россиядә 2022-2032 елларда «Төп халыклар телләренең халыкара 10 еллыгын» үткәрү турындагы карарга туры китереп, Татарстанда республика программасы буенча оештыру комитеты булдырылуы турында билгеле булды. Бу программа буенча да, мәктәпләрдә милли мәгариф уку системасын кайтару күз алдында тотылмаганда, ул комитетның да телне саклауда бернинди катнашы булмавы күренеп тора.

2021 ел Татарстанда «Татар телен саклау һәм халыклар дуслыгы елы» дип игълан ителгән иде. Бу елда, татар телен саклау буенча 9 меңгә якын чара үткәрелүе турында әйтелде. Күреп торабыз, телебезнең сакланып калуына багышлап үткәрелгән меңәрләгән төрле чараларның берсе дә телне саклап калу өчен түгел кебек күренә. Аны саклауның юлы бер генә – мәктәпләрдә элеккеге милли мәгариф уку системасы кайтарып, югары уку йортларында татар телендә укулар торгызу.

Илдә мөһим эшләр башкарылганда, кайнар нокталарга кешеләр кирәк булганда, иң элек милли республикаларның кешеләре кирәк булуын да онытмасак иде.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.

Кыяр – валюта

Кешелек дөньясында кыярны инде 4,5 мең ел буе кулланалар. Кайбер урыннарда ул хәзер дә бик кыйммәтле яшелчә санала. Мәсәлән, Тын океан утрауларында абориgеннар кыярны банан яфрагына төреп җиргә күмә һәм шул рәвешле ачлык яки шторм вакытына запас ясый. Кияүнең җиргә күмелгән кыяры никадәр күбрәк булса, ул кәләшләр өчен шулкадәр кызыктыргычрак була, байга санала. Фиджи утравында кияү үзенең кыяр запасын күрсәтмичә кәләшнең әти-әнисе никахка ризалык бирми.

("Fishki.net").

Хикмәтле тау

Таиландның төньягындагы Уттарадит провинциясендәге могҗизалы тау җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне үзеннән-үзе үстерә һәм ел буена бөтен бер район халкын тәэмин итә. Җирле халык аны Ашарга яраклы тау дип йөртә. Тау итәгендә берничә авыл урнашкан. Калкулык тулысынча җиләк-җимеш агачлары һәм куакларына төренгән, гади чирәм урынына исә яшелчәләр һәм укроп, петрушка, рәйхан кебек тәмләткеч үләннәр үсә. Беренче карашка тау хуҗасыз бакчаны хәтерләтә. Әмма андагы һәр агач һәм куак ел әйләнәсе җимеш бирә. Җиләк-җимешләрне һәм яшелчәләрне беркем дә утыртмый-чәчми, ашламый, алар үзеннән-үзе мул уңыш бирә. Галимнәр әлеге юмарт тауны кат-кат тикшерсә дә, аның серенә төшенә алмаган, бары тик бер генә нәрсәне ачыклаган: тау бары тик үзенә генә хас сортлы җимеш һәм яшелчә үстерә, алар башка беркайда да очрамый.

("Вокруг света").

Чөгендер – допинг

Галимнәр кызыл чөгендернең куәтле допинг булуын ачыклаган. Чөгендер согы тәҗрибәдә катнашучыларның чыдамлыгын 16 процентка арттырган. 6 көн буе яртышар литр сок эчкәннән соң, алар велоэргометр педален күпкә тизрәк әйләндерә башлаган, ә кан басымнары күтәрелмәгән. Чөгендер организмдагы азот окисен арттыра. Ничек итепме? Чөгендердәге нитрат авыздагы бактерияләр ярдәмендә нитритка әйләнә, әлеге матдә канга суыртылып кирә һәм тылсымлы азот молекуласына әверелә. Азот молекуласы организмның кислородка булган ихтыяҗын киметә. Чөгендер спортчыларга гына түгел, йөрәк-кан тамырлары һәм сулыш системасы авырулары булганнарга, матдәләр алмашы бозылганнарга һәм өлкән яшьтәге кешеләргә дә искиткеч файдалы.

("Лента.ру").

Май да кирәк

Ачтан үлмәс һәм сәламәтлекне дә саклап калыр өчен, кешегә көненә күпме ризык ашарга кирәк? Икмәк һәм су белән генә тукланып яшәргә ярыймы? Әлеге сорауларга шактый кешене борчый. Ипи-су белән генә яшәп була, әмма сәламәтлекне саклап калып булмый – әлеге ризыклар гына организмны кирәкле аксым, витамин, май кислоталары һәм башка файдалы матдәләр белән тәэмин итә алмый. Исән-сау гомер сөрер өчен, минималь рацион 1500 килокалориядән ким булмаска тиеш. Бу нормадагы 2000-2200 килокалориядән 30-40 процентка кимрәк һәм гомерне озайта торган төп факторлардан берсе. Дөрес, мондый туклану дәртләндерми. Әгәр 1500 килокалорияле рационның 50 шәр граммы аксым һәм майлардан, 200 граммы углеводлардан торса, бик шәп. Углеводлар икмәк һәм ботка белән түгел, яшелчә-җиләк-җимеш сыйфатында керергә тиеш, бу ашыйсыны да китерми, файдалырак та. Майлар да төрле булырга тиеш – балыкныкы да, терлекнеке дә, әмма күбрәк өлеше үсемлек мае булса, яхшырак.

("The Local").

Мыраужан – Штирлицка алмаш

Кайчандыр архивлар ачылгач, салкын сугыш чорының таң калдыргыч серләре җәмәгатьчелеккә мәгълүм булды. Шулардан берсе – Үзәк разведка идарәсенең "Акустик китти" проекты – яшеренеп тыңлап торучы үзйөрешле җайланма сыйфатында мәчеләрне куллануны күздә тоткан. Хәтта бер мәченең тән тиресенә кирәкле схемалар һәм туену элементлары да кертелгән, антенна ролен исә хайванның койрыгы үтәргә тиеш булган. Күп өметләр багласалар да, шпион песи хуҗаларына эш күрсәтә алмый калган. Киборг-мәчене машинадан сынау мәйданына төшерүләре булган, аны шундук такси таптаган да киткән. 5 ел вакыт, 15 миллион доллар акча түгелгән проект уңышсыз дип табылган һәм бөтенләй ябылган.

("The Times").

Спорт бәйлелеккә китерә

Америка галимнәре гаҗәпләндергеч тикшеренү үткәргән. Спорт күнегүләре белән кирәгеннән артык мавыгу героинга бәйлелеккә охшаган физик бәйлелек китереп чыгара ала икән. Көн саен спорт залына йөрергә күнеккән кеше, физик күнегүләр ясарга вакыт таба алмаса, наркоман кебек үк интегә. Эш шунда: физик күнегүләр вакытында баш миендә "ләззәт гормоны" – эндорфин эшләнеп чыга, ул бик шәп анальгетик та булып санала. Спорт белән шөгыльләнү гел файдага кебек югыйсә: тән дә сәламәт, буй-сын да сылу-зифа, кәеф тә шәп. Әмма алай түгел икән шул. Кеше күбрәк йөгергән-сикергән-йөзгән саен, аның организмы да шулкадәр тизрәк туза һәм гомере дә кыскара, дип уйлый тикшеренү авторлары.

("USA Today").

Искиткеч ихтыяр иясе

XX гасыр азагында тулысынча параличланган бер кеше яшәгән. Аның аягы да, кулы да, авызы да хәрәкәтләнмәгән. Әмма, шуңа да карамастан, ул бестселлерга әйләнгән китап язып бастырган. Ничек итепме? Жан-Доминик Боби 1995 елның 8 декабренә кадәр сау-сәламәт кеше булган һәм ELLE журналында баш мөхәррир булып эшләгән. 43 яшендә, 20 көн комада ятканнан соң инсульт тулысынча хәрәкәтсез калдыргач, Жан бары тик бер генә нәрсә эшли алган – сул күзен кыскалаган. Шулай итеп 140 битлек китап язган: ярдәмчесе махсус алфавиттагы хәрефләрне салмак кына әйтеп барган, кирәклесен ишеткәч, Жан күзен кыскан. Ул язган китап буенча 2007 елда "Скафандр һәм күбәләк" дигән фильм да төшерелгән. Скафандр – ул инсульт кичерүченең тәне, күбәләк исә – җаны: хәрәкәтсез тәнгә бикләнгән тере җан. Иң кызганычы шул: китабы чыгып 2 көн үтүгә үк Жан-Доминик үпкә ялкынсынуыннан җан тәслим кылган.

("Le Figaro").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

26 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 12+
10.00, 23.30 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.40 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
17.00 «Татарлар». 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00, 20.00, 0.45 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башвактыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05, 18.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Әхәт Гаффар турында телеочерк. 6+
15.30, 0.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.15, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЛАНЦЕТ». 12+
10.30, 15.30 «Мечтатели». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КУРЬЕРСКИЙ ОСОБОЙ ВАЖНОСТИ». 16+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «СУЧЬЯ ВОЙНА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Николай Урванцев.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15, 17.20 «Забытое ремесло».
8.40 «Рассекреченная история».
9.10, 16.35 «БАЯЗЕТ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Ритмы джаза. Московские джазовые ансамбли».
12.20 Цвет времени. Владимир Татлин.
12.35 «МОЙ НЕЖНО ЛЮБИМЫЙ ДЕТЕКТИВ».
14.05 90 лет со дня рождения Владимира Войновича. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 Цвет времени. Иван Крамской. «Портрет неизвестной».
17.35 Легендарные дуэты. Галина Вишневская и Мстислав Ростропович.
18.35 «Как римляне изменили Галлию».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 К 85-летию со дня рождения Георгия Рерберга. Острова.
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «СПРУТ-2».
23.10 Цвет времени. Карандаш.
23.20 Кто мы? «Философский пароход».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
21.45 «СТАЯ». 16+

Сишәмбе

27 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 15.15 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Төймә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
17.00 Хоккей. «Салават Юлаев» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Родная земля». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 «Кискен җилгә ак җилкән». Фирая Әкбәрова турында телеочерк. 6+
19.15, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СУЧЬЯ ВОЙНА». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КУРЬЕРСКИЙ ОСОБОЙ ВАЖНОСТИ». 16+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 Лето Господне. Воздвижение Креста Господня.
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Как римляне изменили Галлию».
8.40 «Рассекреченная история».
9.10, 16.35 «БАЯЗЕТ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 К 100-летию Российского джаза. XX век. «Играем джаз!.. Фестиваль в Тбилиси».
12.05 «Франция. Замок Шамбор».
12.30, 22.15 «СПРУТ-2».
13.30 «Игра в бисер» «Петр Чаадаев. «Философическое письмо».
14.15 «Сергей Лукьянов».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.25 «Плавск. Дворец для любимой».
17.55 Легендарные дуэты. Евгений Нестеренко и Владимир Крайнев.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
23.10 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
23.20 Кто мы? «Философский пароход».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
21.45 «СТАЯ». 16+

Чәршәмбе

28 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00 Документальный фильм. 12+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Лена Шагыйрьҗан турында телеочерк. 6+
19.15, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СУЧЬЯ ВОЙНА». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЦАРЕВНА ЛЯГУШКИНА». 12+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Закрыв глаза, остаться воином...» Жизнь и смерть Дарьи Дугиной. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.35 «Как римляне изменили Галлию».
8.40 «Рассекреченная история».
9.10, 16.35 «БАЯЗЕТ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «С песней по жизни. Леонид Утёсов».
12.15 Дороги старых мастеров. «Береста-берёста».
12.30, 22.15 «СПРУТ-2».
13.35 «Плавск. Дворец для любимой».
14.05 85 лет со дня рождения Георгия Рерберга. Острова.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.20 «Забытое ремесло».
17.35 Легендарные дуэты. Галина Писаренко и Святослав Рихтер.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Власть факта. «Золото и доллары: история Бреттон-Вудской системы».
21.25 Дневники конкурса «Учитель года».
23.20 Кто мы? «Философский пароход».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
21.45 «СТАЯ». 16+

Пәнҗешәмбе

29 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 15.30 «БИЧАРАКАЙ». 12+
10.00, 0.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
17.00 Хоккей. «Автомобилист» - «Ак Барс». 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00 «Соотечественники». 12+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 «Җилдергән җитез жилләрдә». Илдар Хәйруллин турында телеочерк. 6+
19.15, 20.00, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СУЧЬЯ ВОЙНА». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЦАРЕВНА ЛЯГУШКИНА». 12+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».

9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Как римляне изменили Галлию».
8.40 «Рассекреченная история».
9.10, 16.35 «БАЯЗЕТ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 К 100-летию Российского джаза. XX век. «Концерт Джаз-оркестра под управлением Олега Лундстрема в Доме кино».
12.30, 22.15 «СПРУТ-2».
13.35 Абсолютный слух.
14.15 «Неугомонный. Михаил Кольцов».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Бизон из Зарайска».
15.45 «2 Верник 2». Аида Гарифуллина и Макар Хлебников.
17.20 Большие и маленькие.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Илья Бояшов. «Морос, или Путешествие к озеру».
20.35 К 95-летию Юрия Каюрова. «Театральная летопись».
21.30 «Энигма. Василий Бархатов».
23.20 Кто мы? «Философский пароход».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
21.45 «СТАЯ». 16+

Җомга

30 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Кырыс җиллә дала гөле». Гөлсем Исәнгулова турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Фәйзи Биккинин турында телеочерк. 6+
19.15 «Туган җир». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «СУЧЬЯ ВОЙНА». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ОПАСНЫЕ СЕКРЕТЫ». 16+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
20.00 «СМЕРТЕЛЬНЫЙ НОМЕР». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.45 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Колонна для Императора».
8.20 Дороги старых мастеров. «Лоскутный театр».
8.40 «Рассекреченная история».
9.10, 16.20 «БАЯЗЕТ».
10.15 Спектакль «Семейное счастье».
11.25 «Театральная летопись». Юрий Каюров.
12.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
12.30 «СПРУТ-2».
13.35 «Забытое ремесло».
13.50 Открытая книга. Илья Бояшов. «Морос, или Путешествие к озеру».
14.15 Власть факта. «Золото и доллары: история Бреттон-Вудской системы».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Василий Бархатов».
17.10 Александр Титов, Адам Гуцериев и Санкт-Петербургский государственный академический симфонический оркестр.
18.20 «Царская ложа».
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 «Первые в мире».
20.00 «ПРОДЛИСЬ, ПРОДЛИСЬ, ОЧАРОВАНЬЕ...»
21.25 Дневники конкурса «Учитель года».
22.15 К 65-летию Александра Митрошенкова. Линия жизни.
23.30 «МАГАЗИННЫЕ ВОРИШКИ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
21.45 «СТАЯ». 16+
23.55 «Своя правда». 16+

Шимбә

1 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Спектакль «Гелҗамал». 12+
16.00 «Яратам». Гөлнара Габидуллина. 6+
17.00 «Җырлыйк әле!» 6+
18.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Амур». 6+
20.30 «Адымнар». 12+
21.00 «Халкым минем...» 12+
21.30 Новости в субботу. 12+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.20 «ТАМОЖНЯ ДАЁТ ДОБРО». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Фәйзи Биккинин турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Париж егете Әлфәнис». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 12+
22.35 Спектакль «Сөяркә». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Россия. Вне зоны доступа». 12+
8.45 «ПАРФЮМЕРША 2». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МИСТЕР ЧЕРЧ». 16+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «НОВЫЙ ЧЕЛОВЕК». 16+
18.00 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОПЕРАЦИЯ «КОЛИБРИ». 16+
22.50 «ХИМИК». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
8.40 «Мечталлион». 12+
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Амурский тигр. Хозяин тайги». 16+
13.10 «ЗДРАВСТВУЙ И ПРОЩАЙ». 16+
15.00 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ». 12+
16.50 «Олег Ефремов. Ему можно было простить все». 12+
18.20 «Непобедимый Донбасс». 16+
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.30 «Мой друг Жванецкий». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «БОМБА». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВСТРЕЧНАЯ ПОЛОСА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Приключения волшебного глобуса, или Проделки ведьмы».
8.10 «ДЕНИСКИНЫ РАССКАЗЫ».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00 Неизвестные маршруты России. «Тверская область. От Твери до Торопца».
10.45 «НЕМУХИНСКИЕ МУЗЫКАНТЫ».
11.50 Земля людей. «Калмыки. Линия горизонта».
12.20 «Эрмитаж».
12.50 Черные дыры. Белые пятна.
13.30 «Великие мифы. Одиссея».
14.00 «Возвращение сокола».
14.40 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.30 «Новые люди Переславля и окрестностей».
16.15 «Владимиру Федосееву - 90». Юбилейная программа в Концертном зале «Зарядье».
17.45 Искатели. «Исчезнувший сервиз Фаберже».
18.35 «Куда идёт джаз?»
19.25 «Хроники смутного времени».
20.05 «ТРИ ТОПОЛЯ НА ПЛЮЩИХЕ».
21.20 «Три тополя на Плющихе». Опустела без тебя земля».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
5.10 «Спето в СССР». 12+
5.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 «Шоу Аватар». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+
23.55 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

2 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 16+
6.00 «Гармунлы сәяхәт». Айзат Мәрдәновның иҗат кичәсе. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар. 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 «Бәхет язым». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+
14.30 «Дусларыма җырларым». Вәис Бәйрәмов. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ВЕК АДАЛИН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Күрәсем килгән иде». 12+
9.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп әйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Килә ява, килә ява». 12+
15.30 «Гомер язы» Резеда Шәрәфиеваның юбилей концерты. 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Казан» бию ансамбле концерты. 6+
23.10 «Шаян хәлләр». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Без химии». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «НОВЫЙ ЧЕЛОВЕК». 16+
11.00 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «Операция «Колибри» (kat16+)
14.50 «Прокуроры 6. Ростовские амазонки. Двухсерийные убийцы». 16+
15.45 «ПАРФЮМЕРША 2». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МИСТЕР ЧЕРЧ». 16+
23.00 «УКРЫТИЕ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.10, 6.10 «ЗДРАВСТВУЙ И ПРОЩАЙ». 16+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.35 «УБОЙНАЯ СИЛА». 16+
16.45 «Левчик и Вовчик. Полвека дружбы». 16+
18.45 «Голос 60+».
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 «ArtMasters». Церемония награждения в Большом театре. 12+

«РОССИЯ»
5.30 «РАБОТА НАД ОШИБКАМИ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 Праздничный концерт.
13.40 «БОМБА». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Маугли».
8.15 «ТРИ ТОПОЛЯ НА ПЛЮЩИХЕ».
9.30 «Обыкновенный концерт».
10.00 Диалоги о животных.
10.45 Большие и маленькие.
12.50 «Либретто». Й. Байер. «Фея кукол».
13.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Евгений Боткин.
13.35 «Игра в бисер» «Поэзия Роберта Рождественского».
14.15 «Элементы» с Александром Боровским».
14.50 «КРАСАВЧИК АНТОНИО».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.45 Передача знаний.
18.35 75 лет Леониду Серебренникову. «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ВРЕМЯ ОТДЫХА С СУББОТЫ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА».
21.35 Гала-концерт К 100-летию Российского джаза.

«НТВ»
5.10 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер!» 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Узган елның 18 ноябренә каршы төн уртасында Чистайда үз йорты белән яшәүче Илнарның тәрәзәсен шакыйлар һәм 16-17 яшьләрендәге бер егет аңа мунчасы ягыннан төтен чыгуын әйтеп шом сала, ләкин хуҗа аның койма артындагы Владимир Паздников өе ягыннан килүен ачыклый, хатынына янгынчыларга хәбәр итәргә һәм балаларны алып, икенче яктагы күршеләргә керергә куша. Илнар хуҗа Владимир һәм ярты ел чамасы аның янында көн күрүче дусты Виктор Мальгинның ялкын ялмап алган өйдә икәнен чамалый, әмма, әйтүенчә, коткару мөмкинлеге булмый, чөнки ишек-тәрәзәләрдән төтен, ут ургый, хәтта кызып кысылган тимер капка да ачылмый. Шул рәвешле, коткаручыларны көтәргә туры килә.

Ялкыннар явызлыкны яшерә алмый

Алар исә янгынны тиз җиңә, ләкин бүрәнә йорт, кирпеч янкорма – кухня яраксыз хәлгә килеп өлгергән була инде. Бусы иң хәтәре булмый әле. Янгынчылар, җыелып өлгергән күрше-күләннән хәрабәләрдә кешеләр булу мөмкинлеген ишетеп, эзләү эшләренә тотына. Тиздән йортның аеруча нык янган арткы өлешендәге көл-күмер арасында бер мәет, түр бүлмәдәге диванда чалкан яткан икенчесе табыла. Йорт хуҗасының абыйсы Александр Паздников аларның беренчесе – энесе Владимир, икенчесе В. Мальгин икәнен әйтеп бирә.

Ирләр искә, тәтенгә тончыгып, янып-пешеп үлгән диган фараз бик тиз кире кагыла. Суд-медицина эксперты шактый көйгән мәетләрнең икесендә дә, кубрәк баш тирәсендә тупас авыр әйбер белән ясалган дистәләрчә җәрәхәт булуын, аларның янгынга кадәр үк җан биргәен белдерә. Бу инде ике кеше үтерелгән, җинаять эзләрен юк итү өчен өйгә ут төртелгән диган сүз була. Мәрхүмнәр даирәсендәге кешеләр иләк аша үткәрелә башлый.

1975 елгы Паздников яшь чагында сау-сәламәт була, 90 нчы елларда Чистай милициясендә дә эшләп ала. Соңрак, күрәсең, бәрелү-сугылулар аркасында, башына зыян килү нәтиҗәсендә чирли, психиатрия сырхауханәсендә дәвалана башлый, ахыр чиктә инвалид дип табыла, гаиләсе, балалары булмый, шушы төп нигездә ата-анасы белән тора, алар вафат булгач, ялгызы көн күрә, пенсиясе хисабына яши, еш кына күршесе Илнар һәм абыйсы Александр да ярдәм итә. Тәртип ягына килсәк, күндәм, зыянсыз ир өен җирле сәрхушләр дә үз итә, туганнары полиция чакыртып куып чыгарган чаклары булуын да сөйлиләр. А.Паздников әйтүенчә, соңгы ике елда Владимир салмыш килеш күренми башлый, өендә исерекләр дә җыелмый. Химик экспертиза аның канындагы этил спиртының бик аз микъдарда икәнен күрсәтә.

В. Мальгин исә нык салмыш була. Ошбу сикәлтәле язмыш иясе яшьтәше һәм бергә укыган сыйныфташы өенә быелтыр җәй көне килеп оялый, базарда эшләп көн күрә. Беренче хатыны белән аерылыша һәм аралашмый. Әлмәт районында укытучы булып эшләүче кызы соңгы тапкыр дүрт ел чамасы элек очрашуларын һәм күптән түгел генә әтисенең икенче никахтан малае булуын да ишетүен әйтә.

Шикләнердәй затлар арасына шул калада яшәүче 1970 елгы Рүзәл Бакиров та эләгә. Шулай ук ата-анадан калган өйдә үзе генә торучы ир-ат янына полиция икенче көнне иртәнге сәгать 6 да ук килеп керә. Күрәсең, ул чакта оперативниклар аның торагын тикшерү турында уйламыйлар, юкса, фаш иткеч дәлилләр тапкан булырлар иде. Әлеге вакыйгага катнашым юк, дип торган Р. Бакиров эчке эшләр бүлегеннән чыгарып җибәрелә һәм өенә кайту белән төнлә салып ташлаган канга буялган киемнәрен, телевизор, аның кушымтасы (приставка), электр бритвасын чүплеккә ташлый.

Хәер, моның әллә ни йогынтысы булмый. Ике көннән соң, ягъни 20 ноябрьдә Р.Бакиров кабат тоткарлана. Сәбәп аның янган өйдә булуын раслаучы кайбер дәлилләр табылуда гына да түгел, ә бәлки үткән тормышындагы кайбер «сәхифәләр»нең ошбу бәндәдән барысын да көтәргә була диган фикергә этәрүдә.

Рүзәл ике абыйсы белән тулы гаиләдә туып-үсә. Бер апасы кечкенә вакытында ук мунчада ис тиеп үлеп китә. Мәктәпне тәмамлагач, елгачылар училищесында укыса да, аны тәмамлый алмый, әмма хәрби хезмәткә кадәр һәм аннан соң ике-өч ел пароходта эшләп йөри. Аннан соң милициягә урнаша, боксчы буларак, төрле ярышларда катнаша. 1998 елда аннан китә, өйләнеп, Нурлат районында хатыны ягында тора. Бер елдан соң туган малаен күрми. Чөнки шул чордан башлап, түбәнгә, тормыш төбенә таба юл ала.

1999 елда милициядән соң бергә эшләгән хезмәттәшен, үзе әйтмешли, пычак белән чәнчеп үтерергә керешә, бары тик аерып алучылар гына максатына ирешергә мөмкинлек бирмиләр. Моның өчен Нурлат шәһәр суды аны 6 елга ирегеннән мәхрүм итә. Шуннан соң хатыны аның белән рәсми рәвештә аерылыша. 2006 елда Иркутск каласындагы милиция һәм башка хокук саклау органнары хезмәткәрләре тотыла торган колониядә утырып,

Чистайга кайткач та, иректә озак йөри алмый, күп тапкыр кадап, бер танышын һәлак итә һәм 12 елга Пермь якларындагы колониягә озатыла, аннан ел ярымга алданрак чыгарылгач, кеше талап тотыла, тагын ике ел ярымга утыртыла. Шул рәвешле, былтыр март аенда ата-ана йортында ялгызы көн күрә башлый. Ул төрмә юлын таптаган елларда әти-әнисе һәм бер абыйсы 37 яшендә вафат була, Түбән Камада яшәүче тагын бер агайнесе юньсез Рүзәл белән аралашырга теләми. Инде 52 яшендәге абзый шабашкаларга йөреп, тимер-томыр җыеп тапшырып, очын очка ялгап бара.

Икенче тапкыр полициягә алып килгәч тә, аның теле чишелә. Әйтүенә караганда, түләмәгән өчен торагында электр энергиясе булмый. Шул сәбәпле, телефонын, фонарь батареяларын кору өчен, еш кына В. Паздников янына килергә туры килә. Аның белән милициядә эшләгәндә танышалар. 17 ноябрьдә бөндә була ул анда. В. Мальгин базарда эштә, хуҗа үзе генә чак туры килә. Эшен бетереп, чәйләр эчкәч, кунак өенә кайтып китә. Кичкә таба аның янына бер литр самогон тотып, бергә шабашкага йөри торган ике дусты килеп керә. Әлеге шешәне бушаткач, сыра белән дә сыйланып, таралышалар.

Исерек Р. Бакиров төнгә каршы тагын В. Паздников өенә таба тәпили, әйтүенчә, батареялар тагын «утыра». Юлы уңа, өстәлдә сыра да, аракы да тора. В. Мальгин, кухняда озак утырмыйча, залга телевизор карарга кереп китә, телефонына төртелеп утыра, гаҗәп, ләкин өйнең арт ягындагы мәхшәрне сизми Виктор.

Андагы вакыйганы Р. Бакиров үзенә кулайрак рәвештә сөйли, әлбәттә. Хуҗа электрны яндырасың дип ризасызлык белдерә, аның күкрәгенә китереп суга, имеш. Әлбәттә, Бакиров та җавапсыз калмый. Әйтүенә караганда, идәнгә егылган Паздников торып, өстәлдәге пычакны алыр, түр яктан В. Мальгин да чыгар да, икәүләп дөмбәсләрләр дип коты алына. Аннан соң хуҗаның яшь чагында башына сукканнан соң сырхауханәдә ятуларын искә алып, рухи кимчелегенә ишарәли.

Кыскача гына әйткәндә, Бакиров ишегалдына йөгереп чыга да утынлыктан балта алып керә һәм аның түтәсе белән В. Паздниковның башына, эксперт санаганча, барлыгы 21 тапкыр ора. Аның җансыз икәнен белгәч тә, шаһитны юк итәргә керешә, залдагы Викторның да баш тирәсенә 13 тапкыр сугып, исән калу мөмкинлеге калдырмый. Һәм шуннан соң кансызлыгы эзләрен юк итәргә керешә, ике бүлмә идәненә чүпрәк-чапрак, кием-салым өеп, аларга ут төртә. Үзе белән телевизор, приставка, электр бритвасын алып, өенә кайтып китә.

Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Ленара Гыйбадуллина иң алдан аеруча кансызлык белән ике кешене үтерү очрагы буенча җинаять эше кузгата. Аеруча авырлар рәтендәге мондый явызлык өчен законда 20 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган. Аннан соң ут төртеп, чит кеше мөлкәтен юк иткән өчен икенче эш ачыла. Экспертлар 1949 елда салынган агач өй, 1983 елгы кирпеч корылманың калган бәясе нибарысы 258 мең сум дип белдерәләр. Зарар күрүче А.Паздников зыянны каплау мәсьәләсен кузгатып та тормый, чөнки Р.Бакировның беркайчан да түли алмаячагын белә. Өченче эш югарыда санап үтелгән әйберләрне урлау буенча кузгатыла. Аларның бәясе 7 мең сум дип табыла.

Әлеге җинаять эшен Татарстан Югары суды караячак.

Моның кебек фаҗигаләр төрлечә килеп чыкса да, уртак, охшаш яклары күп аларның. Иң әүвәл, аларның, кагыйдә буларак, исереклек аркасында килеп чыгуы күзгә ташлана. Соңгы көннәрдә Татарстан Югары судына шул ук Чистай шәһәрендә булган шундый ук тагын бер җинаять эше тапшырылды.

1985 елгы Артем Гильфантинов та өенә картаймыш кенендә торыр урыны булмаган В. Ларионовны сыендыра. Яшь аралары зур булса да, икесе дә юньләп эшләмичә, эчеп йөрүче ялгыз ирләр алар. Быел 1 февральдә ирләр 1961 елгы шешәдәшләре А. Пенкин тарафыннан үтерелә.

Ул көнне алар өчәүләп Артем йортында сыйлана. Сәрхушләр җыелган җирдә вәзгыять иртәнге якта ук кискенләшә. Гильфантинов бу хакта туганнан туган апасына да хәбәр итә. 40 яшьлек ханым килгәч, лаякыл исерек ирләрнең кайсы кайда йоклап ятуын күрә. Ул килгәч уянган аңкы-миңке хәлдәге кешеләргә әрләшмәскә кушып, кайтып китә. Ләкин энесе тагын берничә тапкыр шалтырата, Пенкинны «пычак яратучы» дип атый, чынлыкта, үзе чакырып китергән кунакны куып чыгарырга ярдәм итүен сорый. Сәгать 4енчедә Надежда тагын килә, ләкин әчтән бикле ишеккә керә алмыйча, полициягә шалтырата, алар тәрәзәдән карап, өйдә аунап яткан ирләрне шәйләп, ярдәм кирәк булырга мөмкин дип ашыгыч ярдәм һәм коткаручыларга хәбәр салалар. Соңгылары ишекне ачып эчкә үткәч, зал бүлмәсендә яткан Артем һәм Виталийга ярдәмнең кирәге юк икәне күренә, чөнки аларның башлыча күкрәкләре тирәсендә бик күп пычак җәрәхәтләре булу ачыклана. Пенкин да, күзләрен йомып, шунда ук ята. Уяткач, ирләр бер-берсенә кададылар, дип мыгырдый ул. Ләкин айный төшкәч, барысын да хәтерләп бетермәсә дә, канлы вакыйганы ярыйсы гына сурәтләп бирә, чынлыкта, гаебен танып сөйли. Бер җөмлә белән әйткәндә, үзара сугыша-бәргәләшә башлагач, өстәлдәге пычакны алып, башта яшьрәк хуҗаның тетмәсен тетеп ташлый, аннан соң өлкәнрәк абзыйны юк итә Пенкин.

Үткән тормышына күз салгач, 1961 елгы абзыйның ерткычлыгына гаҗәпләнергә урын калмый. Ул да 18 яшеннән суд бусагасын таптый башлаган, «разбой» диган явызлык кылып, җиде елга утыртылганы да булган, соңгы дүрт елда гына да биш мәртәбә хөкемгә тартылган, узган елның апрелендә ирекккә чыккан, 1 февральдә ике кеше җанын кыйган кеше. Аңа да 20 елга чаклы иректән мәхрүм итү каралган маддә буенча җавап тотарга туры киләчәк. Әлеге эш, аның соравы буенча, присяжный утырышчылар катнашында каралачак.

Наил ВАХИТОВ.

Хәрефләрдән үрә матурлык

«Мин июнь аенда туганмын. Һәм бу айда туучыларның күбесенең сынлы сәнгатькә, әдәбиятка карата игътибарлы булуын искәртә килэм. Билгеле, кечкенәдән үк рәсемнәр ясадым, – диде Роза Хуҗина елмаеп. – Без башта Казахстанның Актау каласында яшәдек, исемдә, иң беренче рәсемнәремне әтинең паспортына ясаган идем. Әтигә паспортын алыштырырга туры килде. Әтием Рәис һәм әнием Рәшидә рәссамлыкка укырга теләвемә һич тә каршы килмәде, мин аларга моның өчен гомер буе рәхмәтле! Соңрак сеңлем Альбина да дизайнер-модельер һөнәрен сайлады. Гаиләбез 1993 елда Балтачка кайтып төпләнгәч, мин башта Балтач сынлы сәнгать мәктәбен, 2008 елда Н.И.Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесын һәм 2012 елда Чаллы дәүләт педагогика институтын тәмамладым. 15 ел дәвамында дизайнер булып эшлим. Үз эшемне ошатам. Эштән буш вакытларымда каллиграфик әсәрләр иҗат итәм. Аларны сыйфатлы төсле кәгазьләргә акрил буяулар белән ясыйм. Бу иҗат юнәлешенә килүемдә дөньякүләм танылган рәссам-каллиграф Владимир Поповның йогынтысы зур булды. Миңа аның ислам каллиграфиясе юнәлешендәге әсәрләре бер күрүдә үк бик ошады! Үземнең дә шундый иҗатта буласым килде. В.Попов биел яңа, саллы китап нәшер итте. Аның бер китап итеп тупланган каллиграфик хезмәтләренә һәрчак сокланып карыйм!

Бүген үземнең дә ике дистәдән артык каллиграфик эшем бар. Алар инде бихисап күргәзмәләрдә дә экспозицияләнде. Эшләрем Яшел Үзән картина галереясында, Мәскәүдәге Рус дәүләт музеенда да саклана. Кайберләре чит дәүләтләрдә дә бар. Хезмәтләремне күпләр ошата. Әсәрләрең хакында фикер белдерелүе, тамашачыларның аларны күрер өчен күргәзмәләргә килүе илһам алып эшне дәвам итү өчен әһәмияткә ия.

Каллиграфик әсәрләрне иҗат иткәндә, күтәренке кәефтә булам, яңа темалар Коръән китабын ачып, сүрәләр укый башлагач туа. Мондый иҗат төгәл булуны, тыныч күңел халәтен таләп итә. Әлбәттә, киләчәктә хаҗ кылып кайтырга иде дигән теләгем дә бар. Насыйп булса, әлеге теләгем дә тормышка ашмый калмас, иншаллаһ!»

Роза Хуҗинаның каллиграфик хезмәтләре Россиянең төрле калаларында узган күргәзмәләрдә дә катнашты. 2021 елда Алматыда Алтын Урдага 750 ел тулу уңаеннан оештырылган онлайн-күргәзмәгә дә куелды.

Роза әле грим буенча рәссам эшенә дә бик теләп алына. Берничә документаль кинофильм төшергәндә, ул грим салучы рәссам буларак катнашты инде. «Минем өчен бар да шатлык – грим да, кием-салым сайлау да... Бәхет мәгънәсе турында сорасалар, аның бер өлеше иҗатта дияр идем. Бар җыйган гыйлемнәрем дә һөнәри һәм тормыш тәҗрибәмне арттыра бара. Сынлы сәнгать төрләре буенча яңа китапларга да игътибар итәм, тәҗрибәле оста буларак, төрле чараларга чакырылып, осталык дәресләре үткәрәм. Ләкин мондый дәресләр өчен вакыт тар. Бу арада йоннан киез әсәрләр иҗат итүгә өстенлек бирә башладым. Былтыр «Хәзинә» милли сәнгать галереясында, «Шәмаил-арт» фестивале кысаларындагы гарәп каллиграфиясе күргәзмәсенә шундый бер хезмәтем куелган иде, аны да ошатып кабул иттеләр. Быелгы «Шәмаил-арт» фестивале кысаларында ачылган күмәк күргәзмәдә алты каллиграфик әсәрем экспозицияләнә», – дип шатлыгын уртаклашты нәкыш остасы.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012 ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань р/с 40702810600020010312 к/с 30101810000000000805 БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 23.09.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2771

16+